№3 / 2020

# МӘГАРИФ

education

mәğәrif

просвещение

# ТАТАР ТЕЛЕ



Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ**

МӘГАРИФ education
mağarif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

Сентябрь, 2020 ел

№ 3

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09
Адрес издателя:
420097, г.Казань,
Академическая, дом 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода –
1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несет рекламодатель

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе, а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2020 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы редактор:
**Насыйхова Л.Р.**
Әдәби редактор:
**Газизова И.М.**
Бу санны әзерләделәр:
**Фаизова Р.Г.**
Корректор: **Гайнуллина Г.Ф.**
Верстка: **Зөфәрова Д.И.**
*Беренче тышлыкта:*
*М.Вахитов мәктәбе укучылары. Фото мәктәп архивыннан алынды.*

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

**ШӘМСЕТДИНОВА Р.** Укытучыга йөз белән борылып....3

**ФӘТТАХОВ И.** И туган тел, и матур тел... (Яки татар орфографиясе мәсьәләсе турында)....9

**НӘСЫЙХОВА Л.** «Ана теле» чит илдәгеләрне дә татарчага өйрәтә....15

**МӨХИЯРОВА Р.** Соңгы чор матбугатында яңа рус-европа алынмаларын куллану үзенчәлекләре....20

**НИГЪМӘТҖАНОВ И.** Йөзьяшәр мәктәп....25

**ЯРУЛЛИНА А.** Исемнәрнең тартым белән төрләнеше (Татар теле, VI сыйныф)....32

**СМИРНОВА Г.** Татар теле дәресләрендә театр педагогикасын куллану (Мастер-класс)....38

**МИНҺАҖЕВА Р.** Ана телебезне өйрәнүдә – «Шигъри әлифба»....42

**ЗАРИПОВА Х.** Чы/-че – сүз ясаучы кушымчалар (III сыйныфның рус төркемендә татар теле дәресе)....46

**ИСМӘГЫЙЛЕВА Р., БӘДГЫЕВА Э.** «Әбисе белән онык» әсәрендә билгесез үткән заман фигыльләрен күзәтү (Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә корылып төзелгән туган тел дәресенең технологик картасы, IV сыйныф)....52

**ШӘРӘФИЕВА Г., МӨКМИНОВА Ә.** Саннарның халык авыз иҗатында кулланылышы (Дәрестән тыш чара, VI сыйныф)....56

**ВӘГЫЙЗОВА Г.** Сыйфат дәрәҗәләре (VI сыйныф, татар төркеме)....61

**ХӘЙРЕТДИНОВА Г.** Боерык фигыль (Татар мәктәпләренең VI сыйныфында татар теле дәресе)....69

**ҖӘЛӘЛИЕВА Г., НӘГЫЙМОВА Р.** Синоним һәм антоним сүзләр. Миниатюр сочинение (VIII сыйныф)....74

**МАТКУЛОВА Ч.** «Кешенең гомере бер генә, Яхшылык эшләргә ашыгыйк!» (VII-IX сыйныфларда бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе)....78

**ХАФИЗОВА З.** Сүз ул – күңел көзгесе (IX сыйныфта туган тел (татар теле) дәресендә «Сөйләм культурасына куелган таләпләр»не үткәч уздырылган мастер-класс)....82

**ГАЙНУЛЛИНА Л.** «Татарстан – безнең уртак йортыбыз» дип исемләнгән ТАССРның 100 еллыгы, Татарстанның республикасының 30 еллыгына багышланган бәйрәм сценарие....88

**ХӘМИДУЛЛИНА А.** Мәдинә Маликова «Чәчкә балы» әсәре (IX сыйныфның татар төркемендә татар әдәбияты)....91

01



# ТУГАН ТЕЛНЕ УКЫТУДА КАМИЛЛЕККӘ ИРЕШҮ ЮЛЫНДА



**Рәсимә ШӘМСЕТДИНОВА,**

Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре

Җәмгыять укытучыга һәрвакыт югары таләпләр куйган, куя һәм куячак. Башкаларны өйрәтү, укыту өчен, аның башкалардан күбрәк белергә тиешлеге бәхәссез. Чын укытучыга, аеруга туган тел һәм әдәбият укытучысына үз предметын, аны укыту методикасын гына белү аз, ул җәмгыять тормышындагы, мәдәният, сәнгать һ.б. өлкәләрдәге яңалыкларны яхшы белергә тиеш.

«Укытучы үзе укыган, өйрәнгән вакытта гына укыта. Укудан туктауга ул укытучы буларак яшәүдән туктый. Дөнья бер урында гына тормый, ул үсештә, үзгәрештә һәм, билгеле инде, педагогика да даими яңаруга, үзгәрүгә дучар». К.Д.Ушинскийның әлеге сүзләре бүген аеруча актуаль. Укытучы һөнәре даими рәвештә белемнәрне яңартып торуны, заманча нәтиҗәле технологияләрне һәм ысулларны файдалануны таләп итә. Боларның барысына да бары тик өзлексез укыганда, квалификацияне күтәрү юнәлешендә эшләгәндә генә ирешергә мөмкин.

Мәгариф турындагы законның 48 маддәсе 1 бүлегендә педагогик хезмәткәрләрнең төп бурычларының берсе итеп «үзеңнең профессиональ дәрәҗәңне даими күтәрү» таләбе куелган. Дәүләт, укытучының хәзерге җәмгыятьтәге ролен дөрес бәяләп, киләчәк мәктәбен формалаштыруда, педагог хезмәтенең иҗадилыгы өчен уңай шартлар тудыру, яшь буынны нәтиҗәле укыту һәм тәрбияләү юнәлешендә эзлекле адымнар ясый. Шуны максат иткән Укытучы үсешенең дәүләт системасын кертү – ул РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып, гаять зур социаль һәм сәяси әһәмияткә ия проект. Бу система педагогның һөнәри үсешен профстандарт таләпләренә туры китереп планлаштыра һәм педагогик белемне, шул исәптән, педагогик кадрларның өстәмә һөнәри белемнәрен яңартуны күз алдында тота. Шушы максатка яраклы рәвештә безнең Мәгарифне үстерү институтында туган тел һәм әдәбияты укытучыларының квалификациясен күтәрү өстендә эш системалы рәвештә семинарлар, вебинарлар, түгәрәк өстәлләр һ.б. чаралар аша алып барыла. Бу уңыйдан квалификация күтәрү курслары белем бирүнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Курслар аерым бер укытучының да, тулаем мәктәп коллективының да профессиональ осталыгын күтәрүгә йогынты ясый.

2016 елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан республикада квалификация күтәрүнең яңа моделен урнаштыру башланды. Ул конкрет укытучының белем алуга ихтыяҗын адреслы финанслау, конкурентлылыкка сәләтле программалар төзү һәм квалификация күтәрүгә бүлеп бирелгән ресурсларны урынлы файдалануга юнәлдерелгән. Укытучы үсешенең дәүләт системасы рамкаларында укытучының һөнәри компетенциясе дүрт – предмет, методик, психологик-педагогик һәм коммуникатив яклардан чыгып бәяләнә. Менә шуңа күрә квалификация күтәрү курслары программасының үзәгендә әлеге компетенцияләрне үстерү юнәлеше тора. Димәк, квалификация күтәрү системасы педагогның үз эшчәнлеген куелган таләпләр югарылыгыннан тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, төп компетенцияләрен күтәрүне тәэмин итәргә тиеш.

Татарстанда татар теле укытучыларының квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар ярдәмендә татар телен һәм әдәбиятын укыту Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә җавап бирерлек хәлгә китерелде. Яңа гыйльми-педагогик мәктәпләр барлыкка килү, яңа укыту-методик комплектлар төзелү, белем бирү тәҗрибәсе тупланыуы методик карашларның камилләшә баруы турында нәтиҗәләр ясарга җирлек булып тора. Шул ук вакытта бу яңарыш-үзгәреш аерым проблемаларны да ачык итеп күрсәтә. Алар, нигездә, укучыларны уку предметы белән кызыксындару, укыту предметының эчтәлеге белән бәйле проблемалар.

Курсларның программаларын төзегәндә, татар теле һәм әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләрен ачыклау өчен аерым мәктәпләрдә мониторинг үткәрелеп, алар программаның эчтәлегендә чагылыш таба. Алга таба мониторинг нәтиҗәсендә ачыкланган аерым проблемаларга һәм аларның чишелеше булып торырлык моментларга тукталып китәргә телибез

Татар телен туган тел буларак укыту лингвистик компетенция формалаштыруга юнәлдерелгән булырга, уку материалы мөмкин булган күләмдә гадиләштереп, үзләштерерлек, лингвистик материалны укучылар сөйләмнәрендә кулланырлык күләмдә бирү максатыннан чыгып укытылырга тиеш. Әлеге максатка ирешү өчен укучыларның аралашу күнекмәләрен формалаштыру, функциональ грамотлыкка өйрәтүгә юнәлеш тоту, татар телен туган тел буларак укытуга предметара якын килү, компьютер технологияләреннән урынлы һәм грамоталы файдалану, татар теленең татар мәдәнияте һәм тарихы өлкәсендә белем бирә торган башка гуманитар дисциплиналар белән бәйләнешенә игътибарны көчәйтү таләп ителә. Укучыларга татар телен өйрәткәндә, мәгълүмати-аралашу технологияләреннән, дидактик материаллар, электрон сүзлекләр, уен-тренажерлардан, театр эшчәнлегенең төрле формаларыннан файдалануны көчәйтергә һәм киңәйтергә кирәк.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча дәресләрдә укучыларның метапредмет эшчәнлек нәтиҗәләре дә бәяләнергә тиеш. Ә метапредмет күнекмәләрне булдыруның иң тәэсирле һәм нәтиҗәле юлы – ул дәресләрдә яки дәресләрдән соң проект эшчәнлеген оештыру. Дөнья күләмендә алдынгы нәтиҗәләргә ирешкән илләрнең, аерым алганда Сингапур, Финляндиянең мәгариф системасында проект эшчәнлегенә зур урын бирелү шуның турында сөйли.

Проект ысулын куллану шулай ук татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укучылар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә

ярдәм итә, туган тел яки дәүләт теле буларак өйрәтелгән дәресләрдә мотивацияне арттыра, игътибарны җәлеп итәргә һәм аны тотрыклы итәргә булыша. Хәзерге заман баласының мәктәптәге дәресләргә караганда күпкә кызыклырак шөгыльләре бихисап, татар теле укытучысы аларны үз файдасына бора алган очракта зур уңышка ирешәчәк.

Өстәмә профессиональ белем бирү программалары нигезендә укыту институт хезмәткәрләре тарафыннан төзелгән укыту-методик әсбапларга, методик тәкъдимнәргә, методик осталыкны үстерүгә юнәлдерелгән эшлекле рольле уеннарга таянып алып барыла. Курсларга рус телен чит тел буларак укыту, чит телләрне укыту тәҗрибәсенә ия булган укытучы-галимнәр, профессиональ конкурсларның җиңүчеләре чакырыла. Укыту барышында интерактив технологияләрдән дә файдаланабыз. Укытучылар проблемалы лекцияләр, рольле уеннар, педагогик тренингларда аеруча активлаша. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен үткәрелә торган курслар 96 сәгать күләмендә билгеләнеп, гамәли эш формаларына, стажировка үтүгә аеруча игътибар бирелә. Алар Институт белән килешү төзегән белем бирү оешмалары җирлегендә – инновацион мәйданчыкларда үткәрелә. Стажировка мәктәпнең алдынгы укытучылары һәм курсларга килгән укытучыларның тәҗрибә уртаклашуы, ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар карау, консультацияләр алу, документация белән танышу, проект эшләре башкару, аларны яклау кебек эш формалары аша алып барыла.

* * *

Мәгарифне үстерү институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасының милли икенче төп юнәлеше – фәнни-методик эшчәнлек.

Укыту процессына, укытучы эшчәнлегенә фәнни-методик яктан ярдәм итәрлек кулланмалар булу, һичшиксез, укыту сыйфатын күтәрүнең бер шарты булып тора. Билгеле булганча, һәр уку предметының эчтәлеге укытучы төзегән эш программасында чагылыш таба, аны төзү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлегенең аерылгысыз өлеше санала. Шунлыктан Институт хезмәткәрләренең, тәҗрибәле, фикерле укытучылар белән берлектә, татар теле һәм әдәбияты буенча эш программалары төзү буенча методик тәкъдимнәр (V – IX сыйныфлар өчен) туплавы мөһим эш булып тора. Шулай ук туган (татар) тел һәм әдәбиятны укытуның аеруча әһәмиятле мәсьәләләренә караган методик эшкәртмәләр циклы да укытучы өчен файдалы булыр дип уйлыйбыз. Һәр елдагыча, 2020 – 2021 уку елына да татар теле һәм әдәбияты укытудагы мөһим юнәлешләргә багышланган методик тәкъдимнәр эшләнде. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәрдә татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшчәнлеген билгели торган норматив документлар, рус мәктәпләрендә татар телен коммуникатив юнәлештә укыту процессының конкрет мисаллар үрнәгендә төп принциплары, дәрестә үткәрелергә мөмкин эш төрләре, татарча сөйләмгә күнектерүдә нәтиҗәле саналган коммуникатив биремнәр чагылыш тапты. Методик кулланмада мәгълүмати-коммуникатив технологияләргә нигезләнгән яңа буын «Сәлам» укыту-методик комплекты, аның төп принциплары турында кыскача мәгълүмат китерелде

Бүгенге көндә гомуми белем бирү мәктәбен дәрестән тыш эшчәнлектән башка күз алдына китереп булмый. Укыту һәм тәрбия бирү эшендә дәресләрдән тыш

эшчәнлекнең төрле формаларын куллану укучыда татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүгә карата кызыксынуны көчәйтә, аңа коммуникатив компетенцияләрне формалаштыруда, сыйфатлы белем алуда, сәләтләрен үстерүдә, шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә яңа мөмкинлекләр тудыра. Дәрестән тыш эшчәнлекнең гомуми системасында тел һәм әдәбият укытучыларының эшчәнлеге бик мөһим урын алып тора. Бу эшчәнлек укытучыга предмет буенча белемнәрне ныгытырга, предметка карата кызыксыну уятырга, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерергә ярдәм итә, мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә әзерли, укучыларның мәдәни дәрәҗәсен арттыра, эстетик зәвык барлыкка китерә. Дәрестән тыш эшчәнлекнең үзенчәлекләре татар телен туган тел буларак укыту мәсьәләләренә багышланган кулланмада урын алды.

Татар теле буенча төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен биремнәр җыентыгы төп гомуми белем бирү мәктәбе программасын үзләштергән IX сыйныф укучыларына татар теленнән ТДИга әзерләнергә ярдәм итү максатын исәпкә алып төзелде. Хезмәт контроль бәяләү материалларының үрнәк вариантларына таянып башкарылган өстәмә материал формасында тәкъдим ителә. Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма, язма эшне бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтыннан[1] алынды. Җыентыкта 81,82 нче код биремнәренә сигезәр вариант тәкъдим ителә. Күрсәтмә материаллар катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра. Күрсәтмә материаллар чыгарылыш сыйныф дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенә әзерлек осталыгын арттыруга ярдәм итәр дип ышанабыз.

Уку предметын үзләштерүнең предмет нәтиҗәләренә карата таләпләр нигезендә «Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар теле» предметы буенча белемнәрнең контроль үлчәү материаллары» кулланмасында федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында белем бирү оешмаларында белемнәрне тикшерү-бәяләү эшчәнлеген оештыру буенча методик тәкъдимнәр бирелә, рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучыларның татар теленнән белем сыйфатын тикшерү үзенчәлекләре яктыртыла, татар теленнән белем сыйфатын тикшерү биремнәренә үрнәкләр китерелә, тикшерү-бәяләү эшчәнлегенең барлык төрләре, принциплары, үзенчәлекләре чагылдырыла. Арадаш аттестация үткәрүнең тәртибе, ешлыгы, формалары, хокукый нигезе җентекле карала, үрнәкләр китерелә. Шулай ук рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбе рус төркемендә укучыларының татар теленнән белем сыйфаты үзенчәлекләре дә чагылыш тапты.

Бүгенге көндә укытучыларны аттестацияләүнең региональ системасыннан бердәм федераль бәяләү материаллары (предмет һәм методик компетенцияләрне ачыклау) нигезендәге системага күчеш – тормышка ашырылу стадиясендә. Аны сынап карау 2015 елдан башланды һәм 2018 елда ТР сы бу системада беренчеләрдән булып Туган (татар) тел һәм әдәбият (татар әдәбияты) буенча катнашты. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары-

[1] *http://mon.tatarstan.ru/*

ның предмет һәм методика өлкәсендәге компетенцияләрен бәяләү өчен биремнәр кертелгән җыентыкта татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен федераль бәяләү материаллары таләпләренә туры китерелеп төзелгән биремнәр тәкъдим ителә, һәм алар укытучыларга аттестацияләүнең региональ системасына катнашу өчен ярдәмлек булыр дип уйлыйбыз. Мәгарифне үстерү институты сайтында сез башка методик кулланмалар белән дә таныша аласыз.

Укыту-методик комплектларны, укыту әсбапларын, авторлык программаларын төзү, рецензияләү эшенә, институт хезмәткәрләре белән бергә, укытучылар да җәлеп ителде. Мондый күмәк оештырылган фәнни-методик эш укытучыны даими рәвештә үз өстендә эшләргә этәрә.

Татар теле әдәбияты буенча укучыларның һәм укытучыларның белем дәрәҗәләрен бәяләү өчен төзелгән биремнәр, аларны сынап карау, анализлау мәктәптә мониторинг үткәрүдә булган уңай һәм тискәре якларны ачыкларга, аларны бетерү өстендә эшләргә мөмкинлек тудыра.


Институт укытучылары һәм хезмәткәрләре укытучыларны профессиональ конкурсларга («Ел укытучысы», «Авыл укытучысы», «Туган тел» остаханәсе һ.б.) әзерләүдә дә актив катнаша.

Мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытуда уңышларыбыз булган кебек, әле хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләребез дә шактый. Шундыйлардан берсе – укытуда дәвамчанлык һәм укучыларны төркемнәргә бүлү мәсьәләсе. Шуны күздә тотып, Институт хезмәткәрләре тарафыннан татар телен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларыннан башлап, гомуми һәм махсус профессиональ белем бирү оешмаларына кадәр, дәвамчан укытуны максат итеп эшләнгән үрнәк эш программалары һәм беренче сыйныф укучыларын төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр эшләнде.

Безнең Институт татар теле һәм әдәбиятын укыту барышын яңартуны фәнни-методик яктан тәэмин итү үзәге булып торганлыктан, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын методик сертификацияләү проектының операторы итеп билгеләнде. Проектның максаты – В.Н. Мещерякованың авторлык программасы буенча Казан, Яр Чаллы шәһәрләре гомуми белем бирү оешмаларының рус телле төркемнәрендә татар телен чит тел буларак өйрәнү сыйфатын күтәрү. В.Н. Мещерякованың авторлык программасына нигезләнгән семинарлар апрель аенда башланды һәм яңа уку елы дәвамында алып барылачак. Институт базасында яңа буын укыту-методик комплектлары төзү максатыннан үзәк оештырылды, эш төркеме тупланды һәм беренче сыйныфлар өчен дәреслек төзү эше алып барыла.

Галим һәм бөек мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин «Алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да бар һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар» дигән фикерне әйтә. Укытучы өстәле артына баскан кеше һәр укучының, киләчәк буынның, җәмгыятьнең, дәүләтнең язмышы өчен җаваплы. Педагог хезмәтенең нәтиҗәләре нинди булса – безнең иртәгәге көнебез шундый булачак. Һәр кеше һәм тулы бер халык язмышы нинди булачагын билгели торган башка эшчәнлекне күз алдына китереп булмый. Туган тел укытучылары кулында телебез язмышы икәнлеген онытмыйча, үз хезмәтебезне заман таләпләренә туры китерерлек итеп башкарыйк. Бөек мәгърифәтчебез К.Насыйри әйткәнчә: «Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль, төзек кагыйдәле камил тел». Һәр татар баласының күңеленә шушы хакыйкатьне сеңдерү – безнең төп бурычыбыз.

02




# И ТУГАН ТЕЛ, И МАТУР ТЕЛ...

## (Яки татар орфографиясе мәсьәләсе турында)



**Илһам ФӘТТАХОВ,**

филология фәннәре кандидаты

*Мөхтәрәм татар зыялысы, уйланыр өчен сиңа мөрәҗәгать итәм.*

Мәгълүм булганча, татар теле төрки телләр гаиләсенә керә. Бу гаиләгә тагын башкорт, нугай, кырым татар, төрек, үзбәк, каракалпак, кыргыз, казах, уйгур, төрекмән, азәрбайҗан, карачай-балкар, комык, гагауз, караим, хакас, чуваш, якут телләре карый. Хәзерге көндә чуваш, якут телләре гомумтөрки тел нормаларыннан ераклашкан саналалар. Чуваш теле мари теле йогынтысында, ә якут теле эвенк теле тәэсирендә гомумтөрки телдән шактый аерылалар.

Ана телебез, җиһандагы тугандаш төрки телләр белән чагыштырганда, грамматик төзелеше ягыннан камил, аның сүзлек хәзинәсе искиткеч бай. Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) каршындагы «Юнеско» халыкара оешмасы татар телен дөньякүләм 14 тел арасына юкка гына кертмәгән инде.

Татарларга латин графикасына күчәргә Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы үз вакытында рөхсәт биргән булса, татар телендә орфография мәсьәләсе әллә кайчан уңай хәл ителер иде. Кириллицада гарәп алынмаларын *мәгариф, каләм, сәлам, кәгазь* дип язабыз, ә латин хәрефләре белән *mәgәrif, kәlәm, sәlәm, kәgәz* дип язар идек. Бу очракта сингармонизм законы тулысынча саклана.

Сузыкларның бер-берсенә йогынты ясап, үзара охшашланулары сингармонизм дип атала. Сингармонизм төшенчәсе гармония сүзеннән ясалган, ә гармония ярашуны, килешеп яшәүне аңлата. Татарча сүзләр калынлыкта һәм нечкәлектә ярашалар. Сингармонизмның ике төре бар:

1) Рәт гармониясе – татар телендә [а], [о], [у], [ы] сузык авазлары килсә, сүзләр калын әйтеләләр *(борыч, бурыч, авыр, бавыр, карлыган)*; [ә], [и], [ө], [ү], [э] сузык авазлары булса, сүзләр нечкә әйтеләләр *(чигү чиккән, күлмәк кисү, бөрлегән, җиләк)*;

Искәрмәләр алынмаларда *(диван, дивар, дарелфөнүн, имам, мөгаллим)*, кайбер грамматик формаларда *(миңа, сиңа)*, кушма сүзләрдә *(көнчыгыш, көнбатыш, өчпочмак, дүртпочмак)* күзәтелә.

2) Ирен гармониясе – *көлке* [көлкө], *борын* [борон]. Беренче иҗектә килгән ирен сузыклары [ө], [о] икенче иҗектәге [э], [ы] авазларына тәэсир итәләр һәм [э], [ы] авазларын да иренләштерәләр.

Инде рус баласын әйткән дә юк, хәтта татар укучысы да сәлам, сәламәт, сәламәтлек шикелле алынма сүзләрне күп очракта дөрес язмый, мәсәлән, диктант текстында

еш кына сәләм, сәләмәт, сәләмәтлек дип, ягъни ишеткәнчә яза ул. Диктантлар тикшергәндә мондый хата, гадәттә, шактый еш очрый. Хаталануның төп сәбәбе – гарәп-фарсы телләренә сингармонизм законы хас булмау. Шуңа күрә гарәп һәм фарсы алынмаларын язганда, сингармонизмның сакланмавы аркасында, бик күп ялгышлар китә.

Татар тел белеме фәнендә фикеремне раслар өчен төрки телләргә хас булган сингармонизм законына таянам. Мин татар теленә гарәп-фарсыдан кергән сүзләрне дә әйтелгәнчә язу яклы, ягъни байтак алынмаларны сингармонизмга буйсындыру уенда торам. Шул рәвешле, ана телемнең орфография (дөрес язу) кагыйдәләрен камилләштерүгә ирешеп була дип исәплим. Туган телебезнең чисталыгы, сафлыгы өчен, милли йөзен саклап калу өчен сине дә көрәшкә чакырам. Төрек дигән зур, горур милләт тә нәкъ шулай эшли!

Мин татарча сүзләрне төрлечә бутап язуга каршы чыгам, аларны татарчалаштыру идеясен хуплыйм. Бу юнәлештә кемнәргә таянам соң? Атаклы телче-галимнәребез Гыйбад Алпаров, Галимҗан Ибраһимов, Илдар Низамовның фәнни-нәзари хезмәтләренә нигезләнәм, аларның фикерләре белән килешәм.

Бездә әле милләт тәрәккыяте (прогрессы) өчен тирән уйланылган тел сәясәте юк. Татар әдәби теленә бүген реформа кирәк – телебез чистартуны, ревизияне көтә. Зыялы катламга В.И.Ленинның рус теле, Г.Ибраһимовның татар теле чисталыгы өчен борчылып язган мәкаләләре билгеле. 1920-1930 елларда большевиклар рус телен француз, немец һәм инглиз алынмаларыннан арындырсалар, татар теленнән исә гарәп-фарсы сүзләрен төшереп калдырып, аларны рус һәм интернациональ алынмалар белән алыштырдылар. Хәзерге рус һәм татар әдәби телләре яңадан чит сүзләр белән чуарланып бетте. Бу хакта кем чаң сугар?

Исемнәребезне дә дөрес итеп язмыйбыз лабаса! *Габдулламы* яки *Абдулламы*? Мәсәлән: татарча да, русча да Габдулла Тукай дигән язылыш – хак, бер хәрефе дә төшеп калмый.

Абдулла Алиш туган телебездә нигәдер Габдуллага үзгәрми? Ләкин бер фактка бик игътибар итегез әле: балалар язучысы 1935-1941 елларда яшәгән Халыкара (хәзерге Кави Нәҗми) урамындагы инде җимерек хәлдәге яшел буяулы, дүрт катлы 19 нчы йортка куелган истәлек тактасында *Габдулла* Алиш дип язылган! Шул ук өйдә күренекле татар әдипләре Кави Нәҗми, Ибраһим *Газый* (истәлек тактасында Гази диелгән) торганнар. Тагын бер кызыклы факт: «Казан утлары» журналының 2008 елгы сигезенче санында (162-163 б.) И.Газыйның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга язган хаты басылган. Укысагыз, хат ахырында язучының *Газый* (ягъни хәрефләрне авазлар әйтелгәнчә тезгән) дигән имзасын күрерсез.

Фамилияләр *Габдуллин* яисә *Абдуллинмы*? Минемчә, РФ төбәкләрендә, Казахстанда, Урта Азия, Кавказ республикаларында яшәүче мөселман төркиләрнең, шул исәптән татарларның исем-фамилиясен паспортка бераз русчага үзгәртеп язалар. Мәсәлән: тат. *Гали* (Гали бабай, Гали пәкесе, Галишәр Нәваи, диләр) – рус. *Али* (Али баба, Алишер Новаи); тат. *Габдуллин* – рус. *Абдуллин*. Әйтик, 1990 еллар башында Үзбәкстаннан күчеп кайткан милләттәшебез, ТР Президенты каршындагы Торак фондының элекке гендиректоры Мидхәт улы Тәлгат Абдуллин үз фамилиясен татарчага үзгәртмичә яза; тат. *Габдрахман* (мисал өчен Мордовиядә туып үскән татар язучысы Г.Әпсәләмев) – рус. *Абдрахман, Абдурахман* (Абдрахман Абсалямов, диләр. Бу дөресме инде?); *Гаязны Аяз* дип ник кыскартырга? Мәсәлән, мин укыган бер русча мәкаләдә Аяз Исхаки диелгән.

Һаман да Шамил *Усманов* дип язабыз. Янәсе, документларында шулай бит, диләр. Болай әйткәнче, иң элек уйлыйк: бу рәсми кәгазьләрне кем, нинди телдә тутырган соң? Әлбәттә, кызыллар революцион урыс

телендә язган. Россиядә Гражданнар сугышы елларында татарлардан беренче булып бригада комиссары, ягъни генерал дәрәҗәсенә ирешкән данлыклы шәхес Абдулла (Шамил) Хәйрулла улы Усманов (1898 – 1937) туган ягында (Саратов губернасы, Кузнецк өязе), һичшиксез, *Усман* исеме бар, әмма чын татар *Госман*, ди. Әнә мәрхүм академик Миркасыйм Габделәхәт улы (авыр туфрагы җиңел булсын!) туганнан бирле фамилиясен *Госманов* дип язды. Ичмасам, мөхтәрәм тарихчы галимнән үрнәк алыйк, җәмәгать! Данлыклы җырчы *Госман* (Усман түгел!) Әлмиев, элекке Татар өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы *Госманов* (урысча гына Усманов!) дип саф татарча язсак-әйтсәк, иң дөресе шул булыр. Даһи шагыйрь Сәгыйть Рәмиев әйтмешли, сөекле татарыбыз йокыдан уяна алмагач, аның баш миендә торгынлык күзәтелә, күзәнәкләре томаланып бара. Газиз халкым күбрәк урысча фикерләгәч, баш миенең татарча күзәнәкләре дә урыслаша. Урыска охшашлашкан, ягъни ассимиляцияләшкән шактый күп зыялыларыбызның зиһене дә томан эчендә хәзер.

Татарча *исем-фамилия* язганда да ялгышлар бар дип исәплим. Әтиләребезгә хөрмәт йөзеннән, иң дөрес вариант булганга күрә, мантыйк буенча башта әти исеме, аннан соң шәхес исеме, фамилия язылырга тиеш, мәсәлән: *Сөнгатулла улы Мөхәммәт Мәһди(-ев)*. 1917 елга хәтле шулай иде бит *(Мөхәммәтгариф угълы Габдулла Тукай)*.

Рус телендәге китап һәм газета-журналларда С.Рамеев, М.Магдеев, М.Галеев, Р.Валеев, З.Валеева, М.Бареев дип язалар. Болай дөрес түгел! Русча язганда ата-бабайларыбыз исеме үзгәрмәсен: *Рами, Магди, Гали, Вали, Бари* калсын, аларга рус грамматикасының *-ев* кушымчасы гына ялгансын. Бәлки, мин ялгышамдыр. Ялгышсам, мине төзәтегез.

Татар телендә әти исеменә ялгана торган *-ович, -евич, -овна, -евна* яки фамилиягә ияргән *-ов, -ев* рус кушымчаларын сөйләмнән һәм язудан кайчан төшереп калдырырбыз икән? *Улы, кызы* дип рәсми хатларда, котлауларда гына түгел, үзара аралашканда, бер-берең мөрәҗәгать иткәндә кайчан әйтербез? Әллә һаман зиратта мәрхүм-мәрхүмәләрнең кабер ташларына гына карап фәлән улы, фәлән кызы дип укып йөрербезме? Әйтик, мин Татарстанның Дәүләт Советына баргач, «Исәнмесез, Разил Исмәгыйль улы!» дип сәлам бирдем. Ул беренче карашка елмаеп, ләкин аңлап кабул итте. Тагын бер гыйбрәтле мисал китерәм. Олпат остазларымның берсе, мактаулы профессор Хатыйп Миңнегулов, гомумән, үзенә шәкертләренең отчество белән эндәшкәнен яратмый. Аның: «Илһам, миңа Хатыйп абый дип әйт, җаныма рәхәт булып китә», – дип искәрткәне бар. Шуннан соң мин гыйлем иясенә Хатыйп абый дип эндәшә башладым.

Без, зыялылар, *ата-баба* парлы сүзен ятып кулланабыз. Яраткач, нигә *ата-бабай* дип хатасыз язмыйбыз? Бездә *баба* сүзе юк, *бабай* дип сөйләшәбез, югыйсә. Мин моны татарның белемсезлегеннән килә дип саныйм. Урыс халкы Али баба, ди. Ана телебездә бүлек, кисәк мәгънәсен аңлата торган борынгы төрки сүзе баб бар.

Бәлки, мишәр диалектындагы *кыз-хатын* парлы сүзен дә язуда, сөйләмдә актив кулланылышка кертергә инде вакыт җиткәндер, чөнки башта кыз була дигәндәй, аннары гына хатынга әйләнә. Болай әйтсәк, сүз тәртибендә мантыйк саклана түгелме соң? Татар әдәби телендә *хатын-кыз* дибез, биредә логика юк кебек! Хөрмәтле зыялы, моңа синең карашың ничек? нәрсә уйлыйсың? Әдәби телгә һәм сөйләмгә дә кыз-хатын дип кертеп була. Мәсәлән, күренекле әдип, зирәк акыллы остазым Тәлгат Галиуллин үзенең күптән түгел дөнья күргән кабатланмас сюжетлы әдәби әсәрендә – «Казан утлары»ның 7 нче санында басылган «Ана корт» повестендә мишәрчә иркенләп *кыз-хатын* дип яза, мишәр сөйләшендә еш кулланыла торган *мәсле* (ягъни *төсле, шикелле, кебек, сыман, күк*) чагыштыру бәйлеген дә җөмләләренә рәхәтләнеп кертеп җибәрә, тиешле урынга *гелән* (ягъни

гел) сүзен дә ара-тирә куя. Әгәр повестьне укысаң, мишәр диалекты (көнбатыш диалект дип тә атыйлар) татар әдәби телен тагын да баета дигән фикерне син дә раслар-сың дип уйлыйм. Мишәр диалектлары һәм сөйләшләре – татар халкының уртак тел мирасы, алар хәзерге вакытта, совет чорыннан аермалы буларак, татар әдәби тел казанына кирәкле дәрәҗәдә салынып, яхшы итеп кайнатылырга тиешләр. Белгәнебезчә, Советлар заманында, татар әдәби теленең нигезе итеп алынган Казан арты сөйләшеннән аермалы буларак, мишәр диалектына ниндидер тискәре, салкын мөнәсәбәт яшәп килде, татар әдәбиятында да мишәр сөйләшен, гомумән, читкә тибәрү нык сизелде. Бу, әлбәттә, дөрес һәм гуманлы фәнни караш түгел иде!

Урысчадан туры тәрҗемә – калька-тәрҗемә ясап, «Татарстан халык *артисткасы* Венера Ганиева» яки «опера театры *актрисасы*...», диләр. Бу дөресме? Татар телендә кыз-хатын төрләнеше (женский род), гомумән, юк. Шулай булгач, болай әйтү – хата. Туган телебездә иң дөресе – *артист, актёр*.

Милләт зыялыларына уйланыр өчен бер тәкъдим кертәм: Татарстан Фәннәр Академиясенең гуманитар фәннәр бүлегенең гыйльми утырышында татар теле орфографиясе мәсьәләсен уртага салып сөйләшергә, артык бәхәсләшмичә, аек, салкын акыл белән уңай хәл итеп, тормышка ашырырга дигән катгый карар чыгарырга кирәк. Телебезнең алгарышы, киләчәк үсеше өчен кирәк мондый карар!


Әнә татар дөньясын фәнни өйрәнү эшен бик уңышлы оештырган беренче рәис – танылган математик һәм педагог Хисаметдин улы Гаяз Максудов, аның эшен югары нәтиҗә белән дәвам иткән мәшһүр язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Гыйрфан улы Галимҗан Ибраһимов җитәкләгән Гыйльми үзәк (Академүзәк) 1921-1930 елларда ТАССРда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертү өчен никадәр практик эш кылып өлгергән бит! 30 елларда исә сталинчылар шул игелекле гамәлләрне сызып ташлыйлар. 90 еллар башында ельцинчы «демократлар» ярдәмендә милли яңарыш кабатланды. 2000 елларда инде федераль үзәк тарафыннан милли хәрәкәтнең ялкыны бөтенләй сүндерделде. Ә хәзер Татарстандагы дәүләти учреждениеләр, татар фәнни институтлары, милли иҗтимагый-сәяси оешмалар татар телен республикада дәүләт теле итеп яшәтү өчен нәрсә дә булса эшлиләрме?!

...Мөхтәрәм татар зыялысы, синең игътибарга үзем төзегән таблицаны тәкъдим итәм. Уйлан әле, газиз милләттәшем, һәм кәгазьгә уеңны уйдырып сал! Фикерең уртак изге эш өчен бик мөһим. Ана теленең йөзен, камиллеген бергәләп саклыйк!!!

| **Тәртип саны** | **Сингармонизм законы нигезендә әйтелгәнчә язылыш** | **Сингармонизм законы бозылган очраклар** |
|---|---|---|
| | **Татар исемнәре, фамилияләре** | |
| 1 | Әгъзәм, Әгъзәмев | Әгъзам, Әгъзамов |
| 2 | Әдәм | Адәм |
| 3 | Әлмирә | Әлмира, Альмира |
| 4 | Әминев | Әминов |
| 5 | Әпсәләм, Әпсәләмев | Әпсәлам, Әпсәламов |
| 6 | Әхмәтев | Әхмәтов |
| 7 | Әхтәмев | Әхтәмов |
| 8 | Бакый | Баки |
| 9 | Барый | Бари |
| 10 | Бәкер, Бәкерев | Бакир, Бакиров |
| 11 | Бәйрәмев | Бәйрәмов |
| 12 | Бәширев | Бәширов |
| 13 | Вагыйз | Вәгыйз |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | Васыйл, Вәсил | Васил |
| 15 | Гафурый | Гафури |
| 16 | Газый | Гази |
| 17 | Гомәрев | Гомәров |
| 18 | Курсавый | Курсави |
| 19 | Илидә | Илида |
| 20 | Илсүрә | Илсура |
| 21 | Мәрдәнев | Мәрданов |
| 22 | Мәрҗәни | Мәрҗани |
| 23 | Мәүлитев | Мәүлетов |
| 24 | Рәзил | Разил |
| 25 | Рәзин | Разин |
| 26 | Рәиф | Раиф |
| 27 | Рәмил, Рәмилә | Рамил, Рамилә |
| 28 | Садрый Максудый | Садри Максуди |
| 29 | Сәфәрев | Сәфәров |
| 30 | Тәлгәт | Тәлгат, Тәлгать |
| 31 | Урманчы | Урманче |
| 32 | Фарваз | Фәрваз |
| 33 | Фәттәхетдин, Фәттәх, Фәттәхев | Фәттахетдин, Фәттах, Фәттахов |
| 34 | Хатыйп | Хатип |
| 35 | Хәлидә | Халидә |
| 36 | Хәлә | Халә |
| 37 | Хәсәнев | Хәсәнов |
| 38 | Шәймәрдән, Шәймәрдәнев | Шәймәрдан, Шәймәрданов |
| 39 | Ямәш (Йәмәш), Ямәшев (Йәмәшев) | Ямаш, Ямашев |
| | **Аерым сүзләр, атамалар** | |
| 1 | әдәбияте (әдәбиәте) | әдәбияты |
| 2 | әмин | амин |
| 3 | бәрәбәр | бәрабәр |
| 4 | вазгыят | вәзгыять |
| 5 | идәрә | идарә |
| 6 | ишәрә | ишарә |
| 7 | латыйн | латин |
| 8 | лабаса | ләбаса |
| 9 | марый | мари |
| 10 | мантыйкый | мантыйки |
| 11 | мәгълүмәт | мәгълүмат |
| 12 | мәдәнияте (мәдәниәте) | мәдәнияты |
| 13 | мөрәҗәгәт | мөрәҗәгать |
| 14 | мөхит | мохит |
| 15 | мөхтәрият (мөхтәриәт) | мохтәрият |
| 16 | нәшрияте (нәшриәте) | нәшрияты |
| 17 | повестьне, повестенең | повестьны, повестеның |
| 18 | рухый | рухи |
| 19 | сәләм, сәләмәт, сәләмәтлек | сәлам, сәламәт, сәламәтлек |
| 20 | сүрәт | сурәт |
| 21 | Тәүрәт | Тәүрат |
| 22 | хәбәрдәр, хәбәрдәрлек | хәбәрдар, хәбәрдарлык |
| 23 | хәләт – тамыр сүз хәл | халәт |
| 24 | хәлбүки | хәлбуки |
| 25 | хәтирә – тамыр сүз хәтер | хатирә |
| 26 | шәрәб | шәраб |
| 27 | Шәрек | Шәрык(ъ) |

03




# «АНА ТЕЛЕ» ЧИТ ИЛДӘГЕЛӘРНЕ ДӘ ТАТАРЧАГА ӨЙРӘТӘ




**Ландыш НӘСЫЙХОВА**



«Ана теле» онлайн-мәктәбен Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә яхшы беләләр. Проект җитәкчесе Кадрия Сөнгать кызы Фәтхуллова белән туган телебезне өйрәнүчеләр, ирешелгән уңышлар, киләчәккә планнар турында сөйләштек. Бу юлы очрашу интернет киңлекләрендә түгел, ә күзгә-күз очрашып булды, шуңа күрә Кадрия ханымның проект хакында әңгәмә корганда, күзләрендә горурлану катыш канәгатьлек чагылуына үзем шаһит.

Татар теле белән кызыксынучы ватандашларның күпсанлы мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча эшләнгән «Ана теле»ндә бүгенге көнгә 25 мең кеше теркәлгән. Быел укучыларның саны шулай арту аерым оешмаларда очрашулар үткәрү һәм хезмәткәрләрне теркәү белән аңлатыла. Алар арасында «АК БАРС» банкы, «Казан вертолет заводы», «Таттелеком», «Газпром трансгаз Казан» һәм башка эре оешмалар бар. Әлеге мәктәп аша республикада яшәүчеләр генә түгел, чит илләрдәге төрле милләт, төрле һөнәр вәкилләре дә Тукай теле нигезләре белән таныша. Мәсәлән, япон егете Юта Хисиамо кебекләрнең тел өйрәнү теләге белгечлеге белән бәйле, шулай ук укучылар арасында юристлар, хисапчылар, менеджерлар, логистлар, программистлар да бар икән – алар яңа тел аша үзләре өчен тагын бер мәдәният ача. Берничәсе белән якыннанрак танышыйк. «Онлайн мәктәп укучылары арасында шактый кызык-



лы шәхесләр бар, – ди Кадрия Сөнгать кызы. – Мәсәлән, Испаниянең Валенсия шәһәрендә яшәүче Бернард Монот. Гомер буе Франциянең тышкы эшләр министрлыгында эшләгән әлеге әфәнде барлыгы унбер тел белә. Лаеклы ялга чыккач, тагын бер төрки тел өйрәнергә теләгән табар ди бит. Моңа кадәр инде төрек телен үзләштергән Бернард интернет челтәрендә татар телен өйрәтә торган онлайн-мәктәпкә тап була. Берничә елда туплаган белемнәрен эшкә җигеп, ике төрки телне чагыштырып, бераздан ул хәтта сүзлекчәләр дә төзи башлый, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты укытучыларына татар телендә хатлар язып тора икән.

Иваново шәһәрендә яшәүче Елена Зимина да әлеге онлайн-мәктәпкә интернет киңлекләрендә юлыга. Телне өйрәнгәннән соң, ул, Казан белән танышу өчен, башкалабызга килә, университетка кагылып, җанлы аралашу дәресләре алып баручы укытучылары белән очраша.

«Әти-әнием – татарлар. Алар Казаннан. Кызганычка каршы, әти татарча сөйләшмәде, – дип башлый үз хатын Красноярскида яшәүче Александр Алкин. – Әни һәм аның әти-әниләре туган телдә бик яхшы сөйләштеләр. Без һәр җәйне Казанда уздырдык. Тел белми идем, әмма һәрвакыт аны өйрәнергә теләдем. 2018 елның ноябреннән мин татар телен өйрәнә башладым. Башта Литвинов, аннары Сафиуллина дәреслекләре ярдәмендә. Табарга тырыштым сайтлар. «Әйдә-онлайн»ны таптым. Бик яхшы сайт. Мин Красноярск диаспорасына мөрәҗәгать иттем. Анда «Ана теле» онлайн-мәктәбен киңәш иттеләр. Хәзер мин гаиләмдә бераз татарча сөйләшә башладым. Милли бәйрәмнәргә йөри башладык. «Ана теле» сайтында миңа укытучылар белән аралашу ошый. Мондыйны беркайда да таба алмадым. Шулай ук тыңлап аңлау, грамматик күнегүләр. Мин үз уңышларымны күрә башладым. Мин бу сайтка бик сокланам. Рәхмәт, аны эшләүчеләргә һәм укытучыларга хезмәтләре өчен. Минем ике кызым бар. Алар белән мин аз гына татарча сөйләшә башладым. Кайбер сүзләрне яхшы ук аңлыйлар инде» (аның җавабын редакцияләмичә бирү дөрес булыр дип таптым).

Оффлайн мәктәпләрдән аермалы буларак, «Ана теле»ндә ашыктыру, программа артыннан куу юк. Дөньяның теләсә кайсы почмагында яшәүче һәр кеше телне, үз вакытыннан, үз мөмкинлегеннән чыгып, ирекле рәвештә өйрәнә. Дәресләр тулысынча бушлай. «Кемдер 1 ел эчендә ярты курсны гына үтә, икенче елга да дәвам итә. Проектта теркәлгәненә өч ел тулган Бернард, программаны тулысынча тәмамласа да, җанлы аралашу дәресләрен ярата. Телне онытмас өчен, укытучыларыбыз белән даими рәвештә аралашып тора ул», – ди, фикеремне куәтләп, Кадрия Сөнгать кызы.

Онлайн-мәктәпнең төп максаты – татар телен шәхесара һәм мәдәнията-

**Фотода:** Александр Алкин.

ра аралашу чарасы буларак өйрәтү, тел өйрәнүчеләрнең сөйләм осталыгын үстерү. Мәктәптә теркәлгән һәр кеше көндәлек тормышта аңлашу-аралашу күнекмәләренә ия була, шулай ук татар дөньясы турында кызыклы мәгълүмат ала. Программа 9 дәрәҗәдән тора, аларның һәркайсы, үз чиратында, 8 бүлектән (темадан) гыйбарәт. Димәк, татар телен башлап өйрәнүче барлыгы 72 бүлекне үтеп чыгарга тиеш. «Танышу», «Төсләр һәм саннар», «гаиләм», «Һава торышы» кебек темалардан соң «Сәламәтлек», «Эш эзләү» кебек катлаулырак темалар өйрәнелә. Соңгы дәрәҗәдә исә тел өйрәнүләр татар дөньясы, Татарстан казанышлары белән таныша. *https://anatele.ef.com* адресы буенча теркәлгән һәркемгә 288 видеосюжет, 10 меңнән артык аудиофайл, 6 меңгә якын фотосурәт урнаштырылган мәгълүмат базасы ачыла. Болар барысы да татар телен өйрәнүне җайлы итүдә үз ролен башкара. Шуңа өстәп, фонетика, грамматика лабораторияләре дә материалны уңышлы үзләштерүдә әһәмиятле өлеш булып тора. Шул рәвешле, тәкъдим ителгән программаны онлайн үзләштергән укучы да оффлайнда – чынбарлыкта телне куллана, аның ярдәмендә актив аралашуга ирешә ала. Һәр дәрәҗә ахырында бирелгән тестлар укучыларга үзләштергән белемнәрен һәм коммуникатив күнекмәләрен тикшерергә ярдәм итә. Сынауны уңышлы узучылар сертификатка ия булалар. «Тест 50 сораудан тора. Грамматика, лексика, уку, тыңлап аңлау буенча биремнәр. Аны үткәннән соң, ул үзенең шәхси кабинетында сертификат бастырып ала. Юридик хокукка ия түгел, әмма укучыларга җиңүен раслый торган документ булып тора ул. Бүгенге көндә дистант уку чорында да әлеге мәктәп үзенең кирәклеген исбатлады», – Кадрия Сөнгат кызы.

Шулай да мәктәпнең төп казанышы дип җанлы аралашу дәресләрен атый әңгәмәдәшем. Алар кичке вакытта төрле дәрәҗәләр буенча үткәрелә. Компьютер аша тел өйрәнүче укучылар ял көннәреннән тыш көн саен мондый дәрескә керә ала. Аерым онлайн бүлмәдәге дүрт-биш кеше укытучы белән 45 минут дәвамында турыдан-туры аралаша: башкаларны тыңлый, үз сөйләмен төрле күнекмәләр аша баетырга омтыла. «Проектның нәкъ менә шул ягы бик тә мөһим, кыйммәтле, уңышлы. Укучыларыбыз шундый дәресләрне аеруча үз итә, – ди ул. – «Без аралашудагы киртәне җимерә алмыйбыз. Аңламабыз, комачауларбыз, бераз тагын өйрәним әле», – диючеләр дә очрый. Тик бу – ялгыш фикер. Беренче дәрестә өйрәнә башлаганнан соң ук, дәрескә керергә һәм аралашырга кирәк. Һәркем тигез, беркем беркемне тәнкыйтьләми, син хаталы сөйләшәсең дип ачуланмый. Чөнки «Ана теле» – ул мәктәп, ә белем йорты өйрәтергә, күнекмәләр бирергә тиеш. Укытучыларыбызның һәрберсе ягымлы, итагатьле, бик зур тәҗрибәгә ия. Махсус тренинглар үткән укытучылар. Дәрестә аралашу татар телендә барса да, аңлап җиткермәүчеләр өчен мөгаллимнәребез рус һәм инглиз телләрен дә «эшкә җигә». Компьютер аша өйрәнү – бер әйбер, чөнки укучы аның аша күнегүләр эшли, аудиоматериаллар тыңлый. Ләкин алар барысы да яздырылган форматта. Ә җанлы аралашу спонтан рәвештә – дәрескә кергәч тә «исәнмесез» дип башлана. Тел өйрәнүче кеше өчен татарча җөмлә, реплика әйтүе, диалог төзү мөһим. Дәрестә 6 дан артык кеше була алмый. Укытучы алар белән үзе аралаша, үзара аралаштыра. Хәтта кайчак тема-

дан читкә тайпылып та, тормыш хәлләре турында да сөйләшә башлыйлар. Менә шундый чын, җанлы аралашу вакытында һәркем үзенең ни дәрәҗәдә сөйләшә алганын тикшерә ала.

Иң мөһиме – мохит дибез. Чыннан да, татар гаиләләрендә туып үскән булуларына карамастан, үзара туган телдә аралашмаганга күрә, татар сөйләмен ишетү, үзләре сөйләшеп карау бик кызыклы һәм мөһим. Бу җәһәттән Уфада яшәүче философия фәннәре кандидаты, доцент Марина Десяткина фикерләре игътибарга лаек: «Ана теле» онлайн-мәктәбе минем өчен дөньяны яңа яссылыкта ачарга мөмкинлек бирә торган алтын ачкыч булып тора. Укый башлаганнан соң кичергән беренче тәэсирләремне «һәрчак синең белән булган бәйрәм» дип атар идем: кызыклы аудио- һәм видео-диалоглар, «сөйли торган» сүзлек, күптөрле күнегүләр, тәкъдимнәр һәм грамматика нигезләрен аңлату. Авторларның зур уңышы – аудиториянең телне төрле дәрәҗәдә белүен истә тоту. Уфада «Ана теле»н күпләр белә һәм, тел өйрәнгәндә, КФУ галимнәренең тәкъдимнәре берсүзсез кабул ителә».

Авторларга һәр кулланучының фикере кызык. «Кайберәүләр билгеле бер дәрәҗәне үткәч, татарча ипилек-тозлык өйрәндем, хәзер аралаша алам ди. Икенчеләре безнең мәктәптә уку белән беррәттән дәреслекләр, үзөйрәткечләр аша шөгыльләнә башлый. Кемнәрдер хәтта әдәби әсәр укырга күчәләр. Бигрәк тә Ә.Еники хикәяләре, Татарстан китап нәшрияты сайтында урын алган аудиокитаплар зур кызыксыну уята. Бер кат безнең системаны үткәннән соң, яңа чыганаклар ачу, башка әсбаплардан файдалану кызык тоела аларга. Үзара хатларны да татарча алышабыз», – дип өсти Кадрия Сөнгат кызы.

Шунысы да игътбарга лаек: Россиядә башка бер генә милли телнең дә шундый эчтәлекле онлайн-мәктәбе юк. Шул уңайдан проект турында презентация уздырган һәр илдә, төбәктә «Ана теле» зур кызыксыну таба. Мәсәлән, моннан берничә ел элек Кадрия Фәтхуллова берничә хезмәттәше белән Американың Индиана университеты Тюркология үзәге галимнәре белән очрашуга барып кайткан. Анда Татарстан вәкилләре төрки телләрне өйрәнүче галимнәр һәм студентлар алдында татар телен укыту методикасы турында сөйләгәннәр, мастер-класслар, дәресләр үткәргәннәр. «Җыелган утызлап кешене беренче дәрестә үк танышуга-сөйләшүгә тарттык. Шунда ук турыдан-туры Казандагы укытучылар белән аралашу оештырдык. Презентация генә түгел, эшли торган проект икәнлегенә үз күзләре белән күреп ышандылар, – ди, горурланып, җитәкче. – Димәк, система эшли, гади кешеләргә хезмәт итә. Безнең өчен шунысы мөһим».

КФУның «Ана теле» онлайн-мәктәбе үзәгендә 18 кеше эшли. Дәресләр расписаниесен төзү, аларны үткәрү, укучылар белән кире бәйләнеш булдыру, конференцияләрдә аның эшчәнлеген яктырту – һәркемнең үз вазифасы бар. Бу мәктәп узган ел Россиянең Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыгы игълан иткән «Төп сүз» бәйгесендә «Иң яхшы мультимедиа проекты» номинациясендә җиңү яулады. Киләчәктә дә «Ана теле» турында тагын да күбрәк кеше белсен, ана телебезнең матурлыгын башкалар да күрсен, аны өйрәнсен дигән теләктә калабыз.

04

# Соңгы чор матбугатында яңа рус-европа алынмаларын куллану үзенчәлекләре





**Рәзинә МӨХИЯРОВА,**

Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты, филология фәннәре кандидаты

Соңгы чорда татар әдәби телендә урын алган неологизм, ягъни яңа сүзләрнең зур күпчелеген алынма, беренче чиратта Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр тәшкил итә. Чөнки XX йөз ахырыннан илнең иҗтимагый-сәяси һәм икътисадый нигезләрен Көнбатыш үрнәгендә үзгәртеп кора башлау яшәешнең төрле өлкәләренә караган күп чит ил сүзләренең рус теленә һәм аның аша татар теленә үтеп керүенә юл ачты. Җәмгыять тормышындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа күренеш, төшенчә, оешма һ.б.ларга исем биргәндә дә гадәттә чит сүзләргә өстенлек бирелә. Бер үк вакытта Совет хакимияте елларында пассив сүзлеккә күчкән күп кенә рус һәм көнбатыш сүзләре яңа тормыш реалияләренең атамалары булып активлашты (гимназия, губернатор, лицей...). XX йөзнең ахырында Европа телләренә хас булган лексиканың интернациональләшү тенденциясе көчәюе дә хәзерге татар теле лексикасында чит тел сүзләренең күбәюенә китерде. Телдәге үзгәрешләр иң беренче чиратта публицистик стильдә чагылыш таба. Соңгы чор вакытлы матбугатын күзәтү түбәндәгеләрне күрсәтә.

Соңгы елларда рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән, беренче чиратта инглиз теленнән кергән *айпат, айфон, аккаунт, блогер, брифинг, ватсап, волонтер, грант, импичмент, инвестор, индексация, инновация, инстаграм, интернет, ипотека, компьютер, магистр, мониторинг, муниципаль, ноутбук, портал, потфолио, продюсер, риэлтор, сайт, смартфон, спикер, спонсор, файл, хакер* сүзләре бик активлашты. Бу сүзләрнең күбесе яңа коммуникация чаралары өлкәсенә карый, базар мөнәсәбәтләренә, сәясәткә, мәдәнияткә караган алынмалар да байтак: *Узган ел* ***инстаграмдагы аккаунтымны*** *урладылар* (Ш.Ч.). ***Блогерларны*** *хәзерге заманның язучылары дип тә йөртәләр* (Ш.Ч.). *Төрек теле өчен андый программа булуын ишеттек, әмма ачык* ***интернет*** *киңлекләрендә ул юк* (М.җ.). *Болар барысы да* ***ипотека*** *хакын арзанайтырга тиеш* (В.Т.). *Чир килеп чыгуга яңа төр* ***коронавирус*** *(2019-nCoV) сәбәп-*

че (В.Т.). ... *киләчәктә дөньяви юнәлешләр буенча* ***магистрлар*** *әзерләү күздә тотыла* (М.җ.). ... *транспорт бүлеге хезмәткәрләре һәр көнне иртәнге 5 тә* ***мониторинг*** *үткәрәләр* (Ш.Ч.). *Казан мэриясе* ***сайтында*** *хәбәр ителгәнчә, поезд барлыгы 4044 чакрым юл үтәргә тиеш* (В.Т.). ***Смартфонда*** *да,* ***компьютерда*** *да* ***парольләрем*** *бар...*(Ш.Ч.). ***Хакерлар*** *һөҗүме мине дә читләтеп үтмәде* (Ш.Ч.).

Көнбатыш Европа телләреннән безгә административ бүленешне һәм аның җитәкчеләрен атый торган сүзләр дә килеп керде *(префект, префектура, мэр, департамент,муниципалитет һ.б.): Ул Васил Шәйхразиев белән уй-фикерләрен уртаклашты,* ***мэр****ның да тәләктәкдимнәрен тыңлады* (Ш.Ч.).

**Офис** алынмасы элекке әйтелеше уңайсызрак контора, канцелярия сүзләрен алыштырды: *«Мин шул сорауга җавап эзләп, 7 нче комплекста урнашкан* **офиска** *юнәлдем»* (Ш.Ч.).

Банк системасының киңәюенә бәйле рәвештә *депозит, дивидент, инвестор, инвестиция, эмитент, ликвид* кебек сүзләрнең кулланылышы активлашты: *«Чит ил* ***инвестицияләрен*** *кертү сәбәпле, КамАЗда штатлар кыскарту куркынычы бар»* (Ш.Ч.).

Базар мөнәсәбәтләренә турыдантуры карый торган **квота, логистика** кебек сүзләр дә еш очрый: *Илчелек РФ Мәгариф министрлыгы белән берлектә безгә хәзергә 25 урынга* ***квота*** *бирә* (В.Т.). *«Бу, беренче чиратта, аэропортны киңәйтеп, халыкара статуска ирештерү, икенчедән, телефон элемтәсен көчәйтү, өченчедән,* **логистика** *(халыкара складлар, базалар системасы) үзәге булдыру дигән сүз»* (В.Т.). Логистика исеменә татар кушымчасы ялгап, фигыль дә ясала: *Халыкара ислам бизнесы һәм финанслары саммитының бер зур нәтиҗәсе – Казанда хәләл ризыкны* ***логистикалау*** *үзәге төзелү* (В.Т.).

Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр, күбесенчә, русча әйтелгәнчә кабул ителә, аларга бары тик татар кушымчалары гына өстәлә. Мәсәлән: *аккредитацияләү, аттестацияләү, глобальләшү, инвестацияләү, индексацияләү, интеграцияләшү, компьютерлаштыру, ликвидлы средстволар, оптимизацияләштерү, тестлаштыру, унитарлаштыру.*

Европа алынмалары татар теленә барысы да диярлек рус теле аша кергән. Дөрес, арада соңгы елларда еш күрсәтелә торган чит ил телесериаллары аша турыдан-туры татар сөйләм теленә кергән *фазенда* кебек алынмалар да бар. Рус теленә исә яңа алынмалар нигездә инглиз теленнән, аеруча аның америкалы вариантыннан кергән. Татар телендәге неологизмнарның да 70 проценты – инглиз сүзләре: *аудит, бартер, ваучер, дилер, дистрибьютор, инвестор, инфраструктура, лизинг, менеджер, менеджмент, офф-шор, риэлтор, спонсор, тендер, трансфер, холдинг, чартер; диссидент, импичмент, инаугурация, кластер, лобби, пиар, рейтинг, саммит, спикер; брифинг, пресс-релиз, респондент; киллер, рэкет, рэкетир; клип, дискотека, продюссер, хит-парад, шоу; дисплей, компьютер, листинг, монитор, принтер, пейджер, картридж, ксерокс; ралли, бодиболдинг, аэробика; гамбургер, сандвич, киви; зомби, уфология, хилер; дизайн, гламур, имидж, имиджмейкер, кемпинг, шоп, нонсенс, супермаркет; армрестлинг, кикбоксинг; скаут, тинейджер, панк, хиппи* һ.б.

Башка телләрдән кергән алынмалар берәмлекләр белән генә санала:

француз теленнән – *анклав, визажист, дискета, интерпол, кадастр, коллаж, сертификат, сутенер, токсикомания;* немец теленнән – *менталитет, паритет, путч;* итальян теленнән – *мафия, мафиози, пицца;* испанчадан – *хунта, фейхоа.* Кайбер грек-латин тамырлы һәм бер үк вакытта берничә Европа телендә кулланыла торган сүзләрнең кайсы телдән алынганын билгеләү кыен. Мәсәлән, *диаспора* сүзе инглиз телендә дә, немец телендә дә бар, *вампир* француз һәм немец телендә дә кулланыла. Шулай ук *аура, социум* кебек латин тамырлы сүзләр дә күп Европа телләре өчен уртак. Мондый күп телләр өчен уртак сүзләрне интернациональ сүзләр, интерлексемалар дип атыйлар.

Неологизмнар арасында рус теленең үз сүзләре бик аз. Соңгы чорда матбугатта урын алган рус сүзләренә мисал итеп аббревиатуралар *(АО, бомж, ГИБДД, ГКЧП, НЛО, омон һ.б.)* һәм кайбер сүзләрнең гади сөйләм, жаргонга хас булган яңа күчерелмә мәгънәләрен *(братва, крутой, крыша, ломка, частник, челнок)* генә китерергә мөмкин. Яңа төшенчәләрне белдергән рус неологизмнары татар әдәби теленә гадәттә калькалаштырып алына. Интерлексемаларны куллану үзенчәлекләренә килгәндә, язма матбугат, радио, телевидение аша һәрдаим кабатланып тору сәбәпле, интерлексемалар һәм рус сүзләре телгә җиңелрәк кабул ителә, чөнки алар әдәби тел һәм сөйләм теле тарафыннан параллель рәвештә диярлек үзләштерелә. Әмма күп санлы алынмалар халыкның барлык катлаулары тарафыннан берьюлы гына үзләштерелеп бетә алмый, шуңа да, гарәп-фарсы алынмалары кебек үк, кайбер яңа кулланышка кертелгән интерлексемалар матбугат битләрендә еш кына җәя эчендә, сызык аша һәм өтердән соң ‘ягъни’ теркәгече ярдәмендә аңлатмалар белән бирелә. Әмма, гарәп-фарсы алынмаларына караганда, яңа интерлексемаларны аңлатып куллану очраклары күпкә кимрәк, ә рус сүзләрен аңлатмалар белән бирү бик сирәк очрый. Бу мондый алынмаларның гарәп-фарсы сүзләренә караганда халыкка аңлаешлырак булулары турында сөйли. Аңлатма, нигездә, сүзтезмә-тасвирлама рәвешендә була, сирәк очракта гына мәгънәдәш татарча, я башка алынма сүз ярдәмендә бирелә. Матбугатта яңа алынмаларны куллануның түбәндәге төрләрен аерып карарга була:

1) җәя эчендә мәгънә аңлату:

*Үзенең чыгышында М.Шәймиев* ***бартерны (тауар алыштыру)*** *бетерүне яклап чыкты* (Т.я.). ***«Девиант» (җәмгыять өчен куркыныч)*** *тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен ябык төрдәге укыту-тәрбияләү махсус учреждениеләрен бары тик ТР дәүләт идарәсенең республика органнары гына гамәлгә куя ала* (М-ф.). ***«Девальвация» (рубльнең кәгазь чүбенә әйләнүе)*** *белән августта таныштык.* ***Эмиссия (өстәмә акча бастыру)*** *белән безне якын араларда «шатландырырга» җыеналар булса кирәк,* ***инфляция дә (акча очсызлану, бәяләр арту)*** *алардан соң үзен озак көттермәс* (Т.я.). *Илнең көнчыгышында* ***демаркация (төзелгән килешү нигезендә ике территория арасындагы чикне билгеләү)*** *мәсьәләсе уртага салып тикшерелде* (В.Т.). *Сөйләшүләргә әзерлек барышында* ***досье (кирәкле документлар тупланган папка)*** *булдыр* (Я-н.). *Бу, беренче чиратта, ...* ***логистика (халыкара складлар, базалар системасы)*** *үзәге булдыру дигән сүз* (В.Т.). *Әмма байтак кына сөйләшкәннән соң, бу феноменны мин* ***реинкарнация (җанның икенче берәүдә кабатлануы)*** *белән генә аңлата*

*алам, – ди* (Ш.Ч.). *Мәскәү галимнәре күренекле кешеләрнең* ***рейтингларын (популярлык баганасы)*** *төзергә бик яраталар* (Т.я.). *Моны* ***русофобиядән (урысны яратмау хисе*** *– ред.) исергән кеше генә уйлап чыгара ала* (Т.я.). *Менә җиде ел майда һәм сентябрьдә Актаныштa* ***стритбол (урам баскетболы)*** *ярышлары уздырыла* (А.т.). *Үзгәртеп корулар башлангач, заводыбыз ябылды да мин* ***челнок (чит илдән товар ташучы)*** *булып киттем* (В.Т.).

2) җәяләр эчендә мәгънәдәш сүзләр куллану

*Президент һәм Халык мәҗлесенең* ***паритетына (тигезлегенә)*** *дә ирешелде* (Т.я.). *Әгәр дә аерым гражданнар һәм оешмалар үзләренең планлаштырылган чараларын уздырырга телиләр икән, алар иң беренче чиратта җирле үзидарә органнарының* ***санкциясен (рөхсәтен)*** *алырга тиешләр* (Ш.Ч.). *27 июньдә Казанның Киров һәм Совет районнарыннан 35* ***скаут (пионер)*** *һәм 7 вожатый Франциягә сәфәр чыгачак* (Ш.К.).

3) рус-европа алынмасыннан соң сызык аша аныклагыч куллану

***Авизо – акча җибәрү кәгазе*** *– чыннан да банк бланкасында, печате дә урынында* (В.Т.). *Аннары акча түләп, заказ белән кеше үтертүләр дә соңгы елларда бик ишәеп китте, моңарчы без ишетеп тә белмәгән* ***киллерлар – түләүле үтерүчеләр*** *пәйда булды* (К.у.). *Көнчелек-хөсетлеккә һәм үч алуга корылган,* ***киллер-үтерүчеләр...*** *яллауга яки кулга корал алуга кадәр барып җиткән көрәшнең нәтиҗәләре, әлбәттә, бик аянычлы һәм фаҗигале булып чыга* (М.җ.). *Ни генә әйтмәсеннәр, нахакка гаепләнүчеләрне* ***реабилитацияләү – аклау*** *комиссиясенең җитәкчесе итеп Политбюро беркемне дә түгел, ә А.Яковлевны билгеләде* (М.җ.). *Кеше үзе тырышмаса, мондый нәрсәләрдә кемнеңдер* ***имиджы – абруе*** *белән генә берни дә эшли алмыйсың* (М.җ.).

4) алынмадан соң ягъни теркәгече белән аныклау

*Иртәгә менә шулай безнең колакка сәер ишетелгән* ***инаугурация, ягъни ТР Президентының тәхеткә утыру тантанасы*** *булырга тиеш* (Т.я.). ***Паритет, ягъни бертигез җаваплылык,*** *мөгаен, һәрвакыт хәрби термин гына булып калыр* (Т.я.). *КамАЗ АҖнең җиңел автомобильләр чыгару заводында яңа корпус сафка керү уңаеннан* ***презентация, ягъни,*** *безнеңчә,* ***тәкъдим итү*** *уздырылды* (Ш.Ч.).

Күргәнебезчә, яңа интерлексемалар текстта күбрәк төшенчәләрне татарчага тәрҗемәләү, тасвирлап бирү юлы белән аңлатыла, чөнки аларны телдә бер сүз белән генә алыштырырлык синонимнар юк, ә яңа ясалганнары күпчелек халык өчен бик үк аңлаешлы да түгел.

***Шартлы кыскартылмалар:***

*А.к. – «Актаныш таңнары « газетасы*

*В.Т. – «Ватаным Татарстан» газетасы*

*К.у. – «Казан утлары» журналы*

*М.җ. – «Мәдәни җомга» газетасы*

*М-т – «Мәгърифәт» газетасы*

*М-ф. – «Мәгариф» журналы*

*Ө. – «Өмет» газетасы*

*Т.я.– «Татарстан яшьләре» газетасы*

*Ш.Ч. – «Шәһри Чаллы» газетасы*


*Ш.К. – «Шәһри Казан» газетасы*

*Я – «Ялкын» журналы.*

05




# ЙӨЗЬЯШӘР МӘКТӘП



**Ирек НИГЪМӘТИ**



Буа шәһәрендәге бөтен тау ягының бай, шанлы тарихка ия уку йортларының берсе булган Мулланур Вахитов исемендәге гимназия тагын ике елдан үзенең 100 еллыгын каршыларга әзерләнә. Гомер-гомергә татар мохите хөкем сөргән, көчле педагогик составы, үзенчәлекле традицияләре белән танылган, шәһәрдәге башка мәктәпләрдән аермалы буларак, әле дә миллләтебезнең йөзен, рухын балалар йөрәгендә саклап торткан белем учагы ул.

**ЛАЛӘ – УЯНУ БИЛГЕСЕ**

Гимназия – буш урында юктан барлыкка килгән уку йорты түгел. Зәя буеның башкаласы саналган Буа борын-борынгыдан ил-көнгә көчле мәдрәсәләре, укымышлы имам-мөдәррисләре, галим-голямалары белән танылган. Шуңа да бу уку йорты – милләт мәнфәгатьләрен һәрвакыт беренче урынга куйган олуг шәхес, ТАССР Халык Комиссарлары Советы Рәисе Кашшаф Мохтаров эшләгән чорда (1921 – 1924 еллар), 1922 елның 24 июлендә ачылган тәүге татар мәктәпләрнең берсе. Халык Комиссарлары Советының 1921 елның 25 июнендә кабул иткән беренче Декреты да татар теленә, рус теле белән беррәттән, дәүләт статусы бирү турында була. Нәкъ менә шушы елларда татар мәктәпләре челтәре төзелә. Мәктәпләрдә беренче булып татар теле укыту кертелә,

элмә тakталар ике телдә языла, рәсми документлар татар телендә басыла башлый. Гомумән, татар мәгарифен үстерүгә нык игътибар бирелә. Татар телендә югары белем алу мөмкинлеге барлыкка килә. Вузларда татар бүлекләре ачыла, хәзерге ТР Фәннәр академиясенең нигезе – Академик үзәк оештырыла.

Гимназиягә менә шундый уйлар белән аяк бастым. Эчкә узгач та, дивардагы лалә чәчәге формасында ясалган гербыннан да мин аның хәзер дә әнә шул миссияне – туган телебезне һәм милли традицияләрне саклау һәм дәвам иттерүен күрдем.

Гимназия белән инде 6 ел аның бәләкәй генә уңышына да сабый баладай мәмнүн булып, аңа үзенең күңел җылысын биреп, коллективны иҗат бәйгеләренә әйдәп хезмәт куючы фидакарь зат, Татарстанның атказанган мөгаллиме Линар Зинәтуллин җитәкчелек итә. Ленар Бәдретдин улы – «Гаилә һәм мәктәп», «Мәгариф» журналларының да күптәнге якын дусты, укытучыларны, балаларны журналлар чыгаруда кызыклы язмалар белән актив катнашырга эндәүчеләрнең берсе. География укытучысы һәм, гомумән, газиз җиренең яраткан улы буларак, туган ягына багышлап язган «Гасыр кичкән Исәк мәктәбе» (2011), «Буа муниципаль районы географиясе» дәреслек ярдәмлеге (2015), «Буа районында география белеме бирү тарихы: үткәне һәм киләчәге» (2019) исемле китаплар авторы да ул әле. Инде менә сөекле гимназиясенең 100 еллыгына багышланган чираттагы хезмәтен әзерләп ятуын әйтте.

– Кулъязмамны шактый тулыландырасым бар. Моның өчен Казанга барып, архивларда тир түгәргә кирәк әле, – диде ул басылачак китабы турында. Аннан кыскача гына мәктәп тормышы белән таныштырып узды. – Әйтергә генә ансат, йөз еллык тарихны колачлау җиңел түгел. Әмма гимназия үзе дә – сулап торган бер тере организм, үзе сабыйлар хыялыннан торган бер дөнья. Анда барлыгы 360 бала укый. Алар белән янәшә сыйныфларда мөмкинлекләре чикләнгән 42 сабыебыз белем ала. Һәркайсы – шәхес. Укучыларның барысы да шәһәр һәм якын-тирә авыллардан тупланган. Бер балабыз 50 чакрым ераклыктагы авылдан килеп укый хәтта. Алар белән 37 кешелек укытучылар коллективы эшли. Мин аларны бер генә минутка да калдырып китә алмыйм. Мәктәп тыштан тыныч күренсә дә, эчтән кайнап тора. Яңа китабыма өстәмә документлар туплау өчен, ничек тә чираттагы ялымнан файдаланырга һәм кышкы кичләрдә өйдә утырып язарга кирәк, башкача мөмкин түгел.

Гимназиядә Татарстан һәм төбәк тарихын, нәсел шәҗәрәләрен өйрәнүгә игътибар зур. Сыйныфлар арасында туган якка багышланган иң талантлы, иң укылышлы иҗат ителгән шигырь-хикәяләргә, рәсемнәргә, композицияләргә конкурслар игълан ителгән, шуңа күрә дә аның йөз еллык бәйрәмен һәр сабый, һәр укытучы – һәммәбез түземсезләнеп көтә. Аны лаеклы каршылау өчен һәр сыйныф җитәкчесенең, һәр сыйныфның алдына җитди бурычлар куелган. Туган җиренең үткәнен белгән бала туган ягын, ана телен дә ярата, халкы белән дә горурланып яши. Алар баланың шәхес булып үсүе өчен, Тукай әйтмешли, «бик тә кирәкле шәйдер».

## МӘКТӘП МУЗЕЕНДА МИЛЛИ МӘГАРИФ ТАРИХЫ

Шуңа күрә дә, без дә бер гасырлык тарихы булган уку йорты белән танышу

өчен, иң элек аның «Туган якны өйрәнү» музеена юнәлдек. Мәктәпнең иркен, озын, якты коридорларыннан атлаганда, сине ике яклап төрле тарихи вакыйгаларны яктырткан стендлар озата баруына игътибар иттем. «Кара, әгәр теләсәң, таш диварларны да сөйләшергә өйрәтергә мөмкин икән», – дип уйладым эчтән генә. Менә ТАССРның төзелүенә 100 ел тулуга багышланганнары, алар белән янәшәдә Бөек Ватан сугышында Җиңүгә – 75 ел, гимназиянең – 100, Буа шәһәрененең 240 еллыгын яктырткан стендлар тезелеп киткән. Мәктәп тормышына багышланганнарының исәбе-хисабы юк шикелле. Берсенә генә күз салсаң да, тарихның гыйбрәтле сәхифәләре, сине кулларыңнан җитәкләп, үз дөньясына алып кереп китәр төсле.

Музейда безне IX сыйныф укучысы, музей советы әгъзасы Гөлия Хисамова белән тарих, хезмәт укытучысы Рифгать ага Галәтдинов каршы алдылар. Гөлия, бөтен сәләтен салып, иң элек яраткан гимназиясенең 100 еллык тарихы белән таныштырды.

– Уку йортыбыз тарихы 1922 елда ачылган ике баскычлы мөселман мәктәбеннән башлана, – дип сөйләп китте ул. – Оештыру эшләре татар зыялысы Мостафа Насыйровка тапшырыла. Ачылган шәпкә мәктәптә укырга 10 бала килсә, алдагы елда укучылар саны 100 дән арта. Мостафа Галим улы мәктәп белән 1926 елга кадәр җитәкчелек итә. Аннары, 1927 елда мәктәпләрнең гарәп имлясыннан латинга күчәчәге мәгълүм булгач, күп кенә укымышлы милләттәшләребез кебек, Үзбәкстан якларына китеп бара. Мәктәпләрдә үзбәк балаларын укырга-язарга өйрәтә. Озак еллар мәктәп директоры булып эшли. «Үзбәкстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Мәктәбебез хәзергә кадәр Мостафа ага Насыйровның Ташкентта яшәүче оныклары белән элемтәдә тора.

Гөлия Хисамова сөйләгәннәрдән без гимназия турында үзебез өчен бик күп кызыклы мәгълүматлар тупладык. 1927 елның сентябреннән мәктәп директоры булып Ләбиб Гайсин (30 нчы елларда Арча педагогик көллиятен җитәкли) эшли башлагач, уку йорты тугызъеллык итеп үзгәртелә. Мәктәп латин имлясына күчә, башка фәннәр белән рәтеннән, педагогика белән психология фәне керә башлый. Ул чорда укытучы кадрлар җитми. Озакламый чыгарылыш сыйныф укучыларын башлангыч белем бирүче мәктәпләргә укытучылар итеп җибәрә башлыйлар.

XX гасырның 30 нчы еллары СССР халык мәгарифе системасында зур үзгәрешләр алып килә. Илдә мәҗбүри башлангыч белем бирү кертелә. Моңа кадәр бер хәреф танымаган 14 яшькә кадәрге балалар да мәҗбүри рәвештә укырга-язарга өйрәнергә тиеш була. Мәктәпләрдә балалар саны бермә-бер арта. Укыту предметларына нигезләнгән сыйныф системасы кайтарыла. Балада укуы өчен җаваплылык хисе барлыкка килә.

### КЕМ СИН, МУЛЛАНУР ВАХИТОВ?

Гөлия әнә шулай гимназия тарихы белән таныштыруын дәвам итте. Әмма ул: «1934 елда унъеллык урта белем бирү статусы алгач, мәктәпкә Мулланур Вахитов исеме бирелә», – диюгә, әзерлеген сынап карау өчен, аңа юри бер сорау бирәсем килде.

– Аның исемен ни өчен сезнең мәктәпкә биргәннәр соң? Мулланур Вахитов Буада

революцион эш алып бармагандыр бит? – дидем, хәйләкәр генә елмаеп.

Каршыбыздагы Вахитовка багышланган стендта минем сорауның җавабы юк иде, әмма кыз югалып калмады.

– Безнең музейда андый мәгълүматлар юк, – диде ул. – Әмма, белүемчә, Мулланур Вахитов – татар халыкның хәтерендә мәңгегә сеңеп калган каһарман. Аның үлгәннән соңгы язмышы башка һәлак булган көрәштәшләренекенә караганда бик «бәхетле». Татарстанда 1920–1930 елларда төрле «уклончылыкта» гаепләнеп репрессияләнгән уннарча мең танылган сәяси эшлеклеләр арасында яла ягылмый калган берничә генә «изге» исем бар. Шуларның берсе – Мулланур Вахитов. Әгәр дә ул 1918 елның августында Казанны яклаганда исән калса, Сталин палачлары аны да, Мирсәет Солтангалиевне, Кашшаф Мохтаровны харап иткән кебек, һичшиксез, юкка чыгарырлар иде. Мулланур Вахитов революция «аталары» кулыннан түгел, аның дошманнары кулыннан һәлак булды. Ул озак еллар татар халкының совет чоры тарихындагы иң популяр сәяси эшлеклесе, Татарстан өчен гомерен биргән каһарман булып саналды.

Гөлиянең шундый ялкынлы нотыгыннан соң, укучы баланың Россия һәм Татарстан тарихын тирәнтен белүенә сокланып куйдым. Әмма ул моңа исе китми генә, сүзен дәвам иттерде:

– Гимназия гомер-гомергә әлеге исемне югары йөртте. Аның укучылары, кайда укыйсың дип сорасалар, башларын чөеп: «Вахитовта!» –дип кенә җавап бирерләр.

... Шул еллардан алып, база мәктәбе булганга, бирегә Буа төбәгендәге генә түгел, Апас, Тәтеш, Чынлы, Тархан районнары, Ульян өлкәсе авылларындагы җидееллык татар мәктәпләрен тәмамлаган балалар да килә башлый. Укыту системасы да бераз үзгәрешләр кичерә. Балалар белемнәрне I – VII сыйныфларда – татарча, VIII – IX сыйныфларда татар һәм рус телләрендә үзләштерергә керешә.

1939 елда «татар һәм рус халыкларының культурасын якынайту өчен» дигән сәбәп белән, мәктәпләрдә латин хәрефләреннән кириллицага күчү турында карар чыкса да, тулысынча хәзерге кирилица хәрефләре нигезендә уку һәм язу 1941 елда гына башлана. Вахитов мәктәбендә җәен – башлангыч, хәтта җидееллык мәктәп укытучылары өчен аерым фәннәр буенча махсус курслар оештырыла. Ул чорда Казан педагогия училищесы һәм институты да читтән торып укучы студентлар өчен керү имтиханнарын Вахитов мәктәбендә үткәрә башлый. Методик киңәшмәләрнең байтагына Вахитов мәктәбе укытучылары җитәкчелек итә.

### УКЫТУЧЫ, УКУЧЫ КАҺАРМАННАР

Гимназиянең Бөек Ватан сугышы чорын чагылдырган стенды янына җиткәч, тарих укытучысы, моннан 25 ел элек әлеге музейны оештыруда үзе катнашкан хезмәт ветераны Рифгать ага Галәтдиновның йөрәге түзмәде: сүз дилбегәсен үз кулына алып, болай дип сөйләп китте.

– Сугышның беренче көннәреннән үк Һади Ильясов, Хөснулла Гыйльмуллин, Гали Мифтахов, Салих Сайкин, Кәшифә Сабирова кебек бер төркем укытучылар фронтка китә һәм ватан азатлыгы өчен башларын сала. 1941 елда урта мәктәпне тәмамлаган Гата Галиуллин, Фарук Идрисов, Әбрар Измайлов, Гәрәй Зарипов һәм башка күп кенә укучыларыбыз да сугыш кырында һәлак була. Ә менә Котып Гыйз-



зәтуллин, башта – бригада, аннары дивизия командиры буларак зур батырлыклар күрсәтеп, дәүләтебезнең күп кенә сугышчан бүләкләренә лаек була.

1941 елдан иң авыр чорда мәктәпне Галимҗан абый Салихов җитәкли. 1 сентябрьдән уку бары 1-4 нче сыйныфларда гына дәвам иттерелә. РСФСР Мәгариф халык комиссариаты карары нигезендә, урта һәм өлкән сыйныф укучылары укытучылар белән бергә көзге уңышны җыеп алуга җибәрелә. Буа шәһәрендәге күп кенә биналарда эвакуацияләнгән оешмалар, предприятиеләр урнаша, мәктәпнең ике уку корпусы да Буа шәһәр советы карамагына бирелә. Укулар бары бер генә корпуста алып барыла һәм ике сменалы итеп оештырыла. Мәктәптә һәр предмет оборона белән бәйләп укытыла башлый. Сугыш алдыннан мәктәп практикасында булган социалистик ярыш сугыш чорында тагын да зур масштаб белән дәвам итә. Мәктәптә фронттагыларга җылы киемнәр алу өчен 1356 сум акча җыела, шуларның 889 сумын укучылар, 467 сумын укытучылар бирә. Тәрбия эше немец-фашист илбасарларына карата нәфрәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә. Архив материалларына караганда, сугыш чорында мәктәптә барлыгы 357 бала укыган, аларга 16 укытучы белем биргән. Уку шартлары гаять кыен. Укучылар дәреслекләргә, дәфтәрләргә кытлык кичерә. 13 сыйныфка 7 бүлмә туры килгәнлектән, ике сменалы уку дәвам итә, кышын мичкә ягарга утын, бүлмәләргә яктылык җитми. Балалар салкыннан күшегә, әмма дәресләр өзелми. Мәктәпнең 3 гектар мәйдандагы җирендә солы, бодай, тары чәчелә, мәктәп ишегалдына 25 сотый бәрәңге утыртыла. Тормышлары авыр булган 60 балага ашханәдә ашау өчен талон, 18 пар киез итек, Америка Кушма Штатлары җибәргән ярдәмнән 24 бүләк һәм 500 сум акчалата ярдәм таратыла.

## СТЕНДТАГЫ ТАНЫШЛАРЫМ

Үзенең кечкенә генә бүлмәсенә гасыр кадәр гасырны колачларлык тарихи ми-

рас туплаган музейга исем китеп, тын гына ветеран укытучыны тыңлыйм. Үзем һаман уйда. Еллар уза тора. Мулланур Вахитов исемендәге гимназия бүген инде башка мәнфәгатьләр белән яши. Замана ихтыяҗын искә алып, 1970 елдан автодело дәресләре кертә башлап, 2000 нән артык укучы машина йөртү таныклыгы алган. 1992 елда гимназия каршында сәнгать мәктәбе ачылган. Анда шөгыльләнүче балаларның хәзер республика күләмендә уздырылган конкурсларда алдынгы урыннар яулый, андагы «ШкиВ» театр студиясенә йөргән балалар Буа шәһәр драма театры артистлары булып үскәннәр.

Заман укыту-тәрбиягә үз йогынтысын ясамый калмый. Хәзерге шартларда сабыйлар күңелленә кечкенәдән миһербанлылык, шәфкатьлелек шытымнарын салу өчен Белем, Гимназия, Өлкәннәр, Укытучылар көннәре кебек, матур чаралар уздыру гадәткә кергән. Милли гореф-гадәтләребезне искә төшерү һәм саклау йөзеннән, монда  Нәүрүз, Карга боткасы, Җыен кебек борынгы бәйрәмнәрне искә төшергәннәр. Ата-аналар, дәү әниләр, дәү әтиләр көтеп торучы. 8 Март, 23 февраль, 9 Май бәйрәмнәре дә зурлап бәйрәм ителә.

1937 елдан алып 2020 елга кадәр гимназияне 5000 бала тәмамлаган, шуларның 62се – алтын, 107се көмеш медаль белән бүләкләнгән. Гимназиядә белем алган укучыларының күбесе ел саен югары уку йортларына укырга керә, төрле җаваплы тармакларында нәтиҗәле эш алып бара. Татарстанга танылган һәм үзем дә күреп-ишетеп белгән галимнәрнең, сәнгать әһелләре,  тармак җитәкчеләре, күренекле шәхесләрнең заманында шушы гимназиядә укуларын белгәч, күңелдә әлеге уку йортына соклану артканнан арта барды. Мин аларның кайберләрен генә булса да әйтми кала алмыйм. Менә алар: Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Рафаэль Әбүзәров, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе, «Татагропромстрой» АҖнең генераль директоры, «Буа якташлыгы» җәмгыяте президенты Ирек Закиров, профессор, икътисад фәннәре докторы Сәгыйть Хисаметдинов, «Татнефть» ААҖнең Лениногорский филиалы башлыгы, Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре Ринат Хәсәнов. Саный китсәң, бик күп алар.

Кайчандыр газета-журнал редакцияләрендә кул биреп күрешкән, шигырьләрен тантаналы кичәләрдә, шигырь бәйрәмнәрендә тыңлаган, пьесаларын Г.Камал, К.Тинчурин театры сәхнәләрендә тамаша кылган язучы-шагыйрьләрдән, драматурглардан Шәриф Хөсәенов, Барлас Камалов, Әхмәт Рәшит, Данис Хәбибуллин, Равил Рахман, Фирдәвес Дәүбашларның иҗатларын, тормыш юлларын колачлаган стендны күрү күңелдә сөенү хисләре көчәйтеп җибәрде. Баксаң, алар барысы да олы юлга  кайчандыр шушы уку йорты бусагасын атлап чыкканнар икән бит. Гимназия хәзер дә җәмгыятьтә әнә шундый алдынгы карашлы, тирән фикер йөртә белүче олуг шәхесләр тәрбияләүне үзенең төп бурычларының берсе дип саный. Заман һаман хәрәкәттә булуыбызны таләп итә.


*Фотолар мәктәп архивыннан*



06

# ИСЕМНӘРНЕҢ ТАРТЫМ БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ

*(Татар теле, VI сыйныф)*



**Айсылу ЯРУЛЛИНА,**

Казандагы 83 нче лицей-мәгариф үзәгенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** мәктәп турында лексиканы кулланып, исемнәрнең тартым белән төрләнеше темасын кабатлау, ныгыту һәм аны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Шәхескә кагылышлы:** алган белемнәрне гамәлдә куллана, парларда, төркемнәрдә эшли белү, сөйләм телен үстерү.

**Метапредмет:**

*Танып-белү УУГ:*

– уку мәсьәләсе чишелешенең гомуми ысулын формалаштыру;

– үзләштерелгән эчтәлекне һәм чишелешнең гомуми ысулын модельләштерү;

– килеп чыккан нәтиҗәләрне төшенчә итеп формалаштыра белү.

*Коммуникатив УУГ:* укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүе.

*Регулятив УУГ:*

– уку мәсьәләсен кую;

– чишү юлларын билгеләү;

– эффектив булганын сайлап алу, куелган мәсьәләне чишү;

– үз эшенә контроль ясый белү (үзконтроль);

– бәя бирә белү (үзбәя).

**Предмет буенча:** мәктәп турында лексиканы баету, исемнәрнең тартым белән төрләнеше турында алган белемнәрне гомумиләштерү, ныгыту.

**Дәреснең тибы:** алган белем һәм күнекмәләрне камилләштерү, кабатлау дәресе.

**Төп төшенчәләр:** исемнәрнең тартым белән төрләнеше, проблемалы сорау, чагыштыру, чит телләр.

**Предметара бәй-ш:** татар әдәбияты, рус теле, инглиз теле, музыка.

**Эшне оештыру:** фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль.

**Материал:** Татар теле. 6 сыйныф өчен дәреслек, Р.З. Хәйдәрова, З.Р.Нәҗипова. – Казан: Татармультфильм, 2014. – 152 б.

**Чыганаклар:** мәктәп кирәк-яраклары, дәреслек. Компьютер, проектор, экран, портрет, аудиоязма, документ камера.

**Метод, алымнар:** әңгәмә, актив аралашу, катнаш.

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру Мотивлаштыру** | Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыра. | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр, сорауларга җавап бирәләр). | Коммуникатив |
| *1. Исәнләшу:*<br>**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар! Мин сезне күрүемә бик шат.<br>**Укучылар.** Исәнмесез, укытучы апа! Без дә Сезне күрүебезгә бик шат.<br>**Укытучы.** Хәзер инде, бер беребезне сәламлик.<br>**Укучылар.** Исәнме, дустым. *(Бер-берләрен сәламлиләр.)*<br>**Укытучы.** Урыннарга утырабыз. | | | |
| **Фонетик зарядка** | 1. Фонетик кунегүне укый | 1. Укучылар укытучы артыннан кабатлый. | Коммуникатив, регулятив |
| 1. *Фонетик зарядка*<br>**Укытучы.** Хәзер исә фонетик зарядка ясап алабыз.<br>– [ә], [ә], [ә].<br>Дәфтәр, мәктәп, әкият.<br>– [ү], [ү], [ү].<br>Күрү, ишетү, белү.<br>**Укытучы.** Афәрин, укучылар! | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **II. Уку мәсьәләсен кую** | Сораулар бирә. Проблемалы ситуация тудыра. Юнәлеш бирә. | Сорауларга җавап бирәләр. Проблемалы сорауларга җавап табалар. Дәреснең темасын ачыклыйлар. | Танып белү, регулятив, коммуникатив |

**Укытучы.** Укучылар, игътибар белән тактага карагыз әле. Анда җөмләләр язылган. Хәзер дәфтәрләрне ачабыз, бүгенге числоны язабыз һәм пөхтә, матур итеп җөмләләрне күчерәбез.
*1. Минем китабым чиста.*
*2. Аның җавабы дөрес.*
*3. Синең хатаң юк.*
**Укытучы.** Укучылар, җөмләләрне игътибар белән укыгыз әле. Хәзер әлеге җөмләләрдән исемнәрне табыйк. Бу исемнәр нәрсәсе беләндер бик үзенчәлекле? Башта исемнәрнең тамырын табып карыйк. Төркемнәрдә фикер алышыгыз. *(Укучылар сүзнең тамырын табалар.)* Дөрес, укучылар. Ә калган кушымчалар нәрсәне белдерә икән? *(Укучылар җавапны табалар һәм төркемнәрдә бер-берсенә җавапларын әйтәләр.)*
**Укытучы.** Сез җавапларыгыз белән уртаклашкан вакытта, күбегездән дөрес җаваплар ишеттем. Настя, җавабыңны әйтеп кара әле. *(Җавап тыңлана.)*
**Укытучы.** Дөрес, укучылар. Тартым кушымчалары. Ә алар нинди сүзләргә ялганган? *(Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар. Укытучы бер укучыдан сорый.)*
**Укытучы.** Димәк, укучылар бүгенге дәресебезнең темасын ачыклыйбыз. Нинди тема өйрәнәчәкбез бүген? *(Җаваплар тыңлана.)*
**Укытучы.** Әйе, укучылар, бүгенге дәрестә исемнәрнең тартым белән төрләнеше темасын кабатларбыз, белемнәребезне ныгытырбыз. *(Теманы укытучы тактага яза.)*
**Укытучы.** Укучылар, фонетик зарядка ясаган вакытта, шулай ук әлеге җөмләләрне укыганда, без нинди тематикага караган сүзләрне кулландык? *(Укучылар фикер алышалар, бер укучы әйтә.)* Дөрес укучылар, бүгенге дәрестә, «Мәктәп» темасына караган лексиканы кулланып, исемнәрнең тартым белән төрләнешен кабатларбыз.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **III. Яңа белемнәрне формалаштыру** | Сораулар бирә. Проблемалы ситуация тудыра. Рус, инглиз, татар телләрендә исемнәрнең тартым белән төрләнешен аерырга ярдәм итә. Укучылар эшчәнлегенә юнәлеш бирә. | Сорауларга җавап бирәләр. Проблемалы сорауларны чишәләр. Модель төзиләр. | Танып белү, регулятив, коммуникатив |

**Укытучы.** Укучылар экранга игътибар белән карыйк әле.
**Укытучы.** Игътибар итегез әле, укучылар, рус һәм инглиз телләрендә исемнәр тартым белән ничек төрләнә икән.

| Рус теле | Инглиз теле | Татар теле |
|---|---|---|
| Моя книга<br>Твоя книга<br>Его (ее) книга | My book<br>Your book<br>His (her) book | |

*(Укучылар экранда бирелгән чагыштыруны карыйлар. Төркемнәрдә фикер алышалар. Бер-ике укучының җавабы тыңлана.)*
**Укытучы.** Дөрес, укучылар. Безнең төп максат – татар телендә исемнәрнең тартым белән ничек төрләнгәнен белү. Алдагы слайдка карыйбыз. Татар телендә исемнәр тартым белән ничек төрләнә?

| Рус теле | Инглиз теле | Татар теле |
|---|---|---|
| Моя книга<br>Твоя книга<br>Его (ее) книга | My book<br>Your book<br>His (her) book | Минем китабым<br>Синең китабың<br>Аның китабы |

*(Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар. Җаваплар тыңлана.)*
**Укытучы.** Укучылар, нинди аермалыклар һәм охшашлыклар бар? Нинди кушымчалар ярдәмендә ясала? *(Җаваплар тыңлана.)*

**Укытучы.** Алдагы слайдны караганчы, дәреслекнең 5 битен ачыгыз әле. 2 нче күнегүне карыйбыз. Дана, беренче баганадагы сүзләрне укы әле. Элина икенче баганадагы сүзләрне укыр.
**Укытучы.** Хәзер экраннарга карыйбыз. Сез монда нинди үзенчәлек күрәсез? Исемнәрне тартым белән төрләндергәндә, нинди кушымчалар ялгана?

| Зат | | |
|---|---|---|
| 1 зат<br>2 зат<br>3 зат | Карандаш-ым, дәфтәр-ем<br>Карандаш-ың, дәфтәр-ең<br>Карандаш-ы, дәфтәр-е | Хата-м, җилкә-м<br>Хата-ң, җилкә-ң<br>Хата-сы, җилкә-се |

*(Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар. Җаваплар тыңлана.)*
**Укытучы.** Укучылар, кушымчаларның ялгануы нәрсәгә бәйле?
**Укучы.** Әгәр дә сүзнең тамыры сузык авазга бетсә, *-ым / -ем, -ың / -ең, -ы / -е* кушымчалары, әгәр дә тартыкка бетсә, *-м, -ң, -сы / -се* кушымчалары ялгана.
**Укучы.** Әгәр дә сүз калын икән, калын кушымчалар, нечкә булса, нечкә кушымчалар ялгана.
**Укытучы.** Афәрин, укучылар.

**Модельләштерү.** *(Кагыйдә дәфтәргә языла. Укытучы тактада яза.)*

**Исемнәрнең тартым белән төрләнеше**

*1 зат* → *(т) -ым / -ем*; → *(с)-м*

*2 зат* → *(т) -ың / -ең*; → *(с) -ң*

*3 зат* → *(т) -ы / -е*; → *(с) -сы / -се*

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Ял вакыты** | Укучыларга сүзләр әйтә. Сораулар бирә. | Сорауларга җавап бирәләр | Коммуникатив |

**Укытучы.** Укучылар, хәзер урыннарыбыздан торабыз да урындыкларны этеп куябыз. Сыйныф бүлмәсенең һәр почмагына сүзләр язылган плакат эленгән: *мәктәп, укытучы, көндәлек, сыйныф.* Кайсы сүзне сайласагыз, шунда басыгыз әле. *(Укучылар үзләре сайлаган сүз янына басалар.)*
**Укытучы.** Укучылар, тартым кушымчасын ялгап, әлеге сүзләр белән җөмлә төзегез әле. *(Укучылар төркемнәрдә фикер алышылар, һәр төркемнән бер укучының җавабы тыңлана.)*
**1 нче укучы.** Минем мәктәбем матур.
**2 нче укучы.** Минем укытучым иң яхшы.
**3 нче укучы.** Минем көндәлегем чиста.
**4 нче укучы.** Безнең сыйныф якты.
**Укытучы.** Афәрин, булдырдыгыз. Бик матур җаваплар бирдегез. Хәзер урыннарыгызга утырыгыз.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **IV. Диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү** | Исемнәрнең тартым белән төрләнешен кулланып диалог төзү өчен күнегүне тәкъдим итә. 6 нчы бит 6 нчы күнегү. | Диалог төзиләр (парларда эшлиләр).<br>Бер-берсен бәялиләр. | Шәхескә кагылышлы, коммуникатив, регулятив. |

**Укытучы.** Укучылар, сорауларыгыз булмаса, алга таба дәвам итәбез. Дәреслекләрегезнең 6 нчы битен ачыгыз әле. Елизар, күнегүнең биремен укы. Димәк, укучылар, парларда диалог төзибез. Төшеп калган репликаларны өстибез.
*(Укучылар төркемнәрдә парлашып диалог төзиләр. Укытучы берничә укучыдан сорый.)*

| | | | |
|---|---|---|---|
| **V. Лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү** | Экранда бирелгән сүзләргә кушымчалар куеп язуны оештыра. | Күнегүләрне эшлиләр, лексик берәмлекләрне бирелгән ситуацияләрдән чыгып кулланалар, төркемнәрдә эшлиләр. | Шәхескә кагылышлы, коммуникатив, регулятив. |

<table>
<tr><td colspan="4">Укытучы. Хәзер биремнәр эшләүгә күчик. Экранда сүзләр бирелгән. Аларга тиешле кушымчаларны өстәп, ни өчен әлеге кушымчалар язылуын аңлатырга.<br>Минем сумка..<br>Синең сумка…<br>Аның сумка…<br>(Укучылар дәфтәрләрдә күнегүне эшлиләр. Эш тәмамланганнан соң, төркемнәрдә тикшерәләр. Бер-ике укучының җавабы тыңлана.)<br>Укытучы. Афәрин, укучылар.</td></tr>
<tr><td>VI. Монологик сөйләмне камилләштерү</td><td>Төркемнәрдә эш. Укытучы карточкаларда текст тарата.</td><td>Карточкаларда тиешле кушымчаларны куеп язалар. Берничә укучы язган текстны укый.</td><td>Шәхескә кагылышлы, танып-белү, коммуникатив, регулятив.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Укытучы. Хәзер текст белән эшлибез. Сезнең өстәлләрдә карточкалар ята. Җөмләрне укыйбыз. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп язабыз.<br>1. Минем дәфтәр… бар. 2. Минем төсле карандашлар… бар. 3. Синең альбом… бар. 4. Синең китаб… бар.<br>5. Аның плеер… бар. 6. Аның көндәлег… бар.<br>(Укучылар җөмләләрне укыйлар, кушымчаларны куеп язалар. Бу вакытта С.Сәйдәшев вальсы яңгырый, аның фоторәсеме элена. Җаваплар белән төркемнәрдә уртаклашалар. Эш тәмамланганнан сон, бер-ике укучының җавабы тыңлана.)<br>Укытучы. Афәрин, укучылар! Бик яхшы эшләдегез.</td></tr>
<tr><td>VII. Рефлексия</td><td>Дәрес, дәрестә туган авырлыклар турында сорый, дәрескә нәтиҗә ясый, укучыларның эшенә бәя бирә.<br>Өй эшен аңлата.</td><td>Үз фикерләрен әйтәләр, өй эшен язып алалар, сораулар бирәләр.</td><td>Регулятив, танып-белү,</td></tr>
<tr><td colspan="4">Укытучы. Бүгенге дәресебезгә нәтиҗә ясыйк. Без нәрсә өйрәндек?<br>Укучы. Без бүгенге дәрестә исемнәрнең тартым белән төрләнеше турындагы теманы кабатладык.<br>Укытучы. Бүгенге дәрестә нинди биремнәр эшләдек?<br>Укучы. Тартым кушымчаларын кабатладык, җөмләләр төзедек. Рус, инглиз, татар телендә исемнәрнең тартым белән төрләнешен белдек. Сүзләрне кушымчалар куеп яздык, текст белән эшләдек.<br>Укытучы. Димәк, нинди тартым кушымчалары ялгана?<br>Укучы. -ым / -ем /-м, -ың / -ең /-ң, -ы / -е, -сы / -се кушымчалары ялгана.<br>Укытучы. Кушымчарның ялгану үзенчәлеге нәрсәдә?<br>(Укучыларның җаваплары тыңлана.)<br>Укытучы. Афәрин, укучылар!<br>Дәресне йомгаклау.<br>1. Укытучы. Укучылар, өй эше бирү.<br>Көндәлекләрне ачабыз, өй эшен язабыз.<br>1. «Минем мәктәбем» темасына рәсем ясарга һәм сөйләргә өйрәнеп килергә.<br>2. Исемнәрнең тартым белән төрләнешен кулланып, 6 җөмлә язарга.<br>3. 6 нчы биттәге 5 нче күнегүне язмача эшләргә.<br>(Укучылар теләгән өй эшен башкаралар.)<br>2. Бәяләү.<br>(Укучыларның өстәлләрендә кәгазь битләре була. Алар үзләренә билге куялар. Түгәрәкләр ясыйлар. Яшел – «5»ле, сары – «4»ле, кызыл – «3»ле.)<br>Укытучы. Бүгенге дәресебезне уңышлы гына тәмамладык. Актив катнашканыгыз өчен рәхмәт. Алдагы дәресләр дә нәтиҗәле үтсен! Сау булыгыз, укучылар, сәламәт булыгыз!</td></tr>
</table>



07

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕАТР ПЕДАГОГИКАСЫН КУЛЛАНУ

*(Мастер-класс)*



**Гөлнара СМИРНОВА,**

Менделеевск шәһәрендәге 1 нче гомуми белем бирү мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар телен чит тел буларак өйрәнүдә иң авыр, укучылар өчен вакыт-вакыт кызыксыз тоелган мәсьәлә – истә калдыру проблемасына тукталырбыз. Хәзерге вакытта федераль дәүләт белем бирү стандартлары бездән һәм укучылардан эзләнү-тикшеренү, проект эшчәнлеге таләп итә. Билгеле, һәр предметның бала мөстәкыйль рәвештә, эзләнү-тикшеренү, проект эшчәнлеге нәтиҗәсендә ирешә алмаган өлкәсе бар. Гадәттә, ул алдагы эшчәнлек өчен нигез булып тора. Математикада бу, мәсәлән, тапкырлау таблицасы булса, тарих фәнендә – даталар, рус телендә кагыйдәләр кулланыла.

Мондый нигез – укучы яттан белергә тиешле база татар телендә дә бар. Күзалдына китереп карагыз әле: рус телле бала татар теле белән беренче тапкыр очраша. Аңа бик күп сүзне истә калдырырга кирәк. Татар теленең фонетикасы, минимум-сүзлек, грамматикасы – рус телле бала өчен кара урман. Фонетика һәм грамматикага аерым тукталырга телим, чөнки укучыларым миңа гадәттә ике төрле сорау бирәләр. Беренче сорау түбәндәгечә яңгырый:

– *Апа, безгә татар теленең авазларын камил итеп әйтү ни өчен кирәк соң? Камил итеп әйтмәсәк тә аңлашыла бит.*

Бер яктан алар хаклы. Рус баласы татар дустыннан «[Дарес ничәдә] башлана?»– дип сораса да, аны дусты аңлаячак, ике арада коммуникация башкарылачак.

Икенче сорау: *Ни өчен шулкадәр күп фигыльләр өйрәнәбез?*

Үз эшемдә мин шушы сорауларга җавап бирергә ярдәм итә торган, истә калдыру һәм башка бик күп проблемаларны чишәргә булыша торган алымнарга мөрәҗәгать итәм. Бу – театр педагогикасы алымнары.

Ул алымнарны уен рәвешендә кулланам. Мәсәлән, минем кулда шар. Анда – биремнәр. Кем шарны тота, шул *алма* сүзен карточкада бирелгән эмоция белән әйтергә, ә башкалар аның нинди эмоциясен белергә тиеш була.

*Шаккатату*

*Кәефсез*

*Елый-елый*

*Көлеп*

– Коллегалар, үзегезнең актерлык сыйфатларыгызны бик яхшы яктан күрсәттегез, шуңа күрә сезне ярдәмчеләрем булырга чакырам.

– Татар телендә рус телендә булмаган авазлар бар (тактада [а°], [ө], [җ] авазлары язылган).

Фокус группага:

– Әйдәгез, тактада язылган авазларны әйтеп карыйбыз.

Фокус группа: [а°], [ө], [җ].

– Бу авазларның әйтелешен укучыларда ничек ныгытырга икән?

– Әйдәгез, санамышны укып карыйк, кулларны әзерлибез.

Бер алма, ике алма,

Өч алма, дүрт алма,

Биш алма, алты алма,

Җиде алма, сигез алма,

Тугыз алма, ун алма –

Кызыл алма.

– Алга таба укып күрсәтәм: мин җыям, син җыясың, ул җыя. Без көләбез, сез көләсез, алар көләләр.

Күргәнегезчә, мин жестлар кулландым. Бу очракта куллар белән эшләү зат алмашлыкларын истә калдырырга да ярдәм итә. Хәзер бергәләп эшләп карыйбыз.

Игьтибар итегез: беренче биремдә [а] авазы ныгытылса, икенчесендә [җ], [ө] авзлары ныгытылды.

– Авазларның әйтелешен тагын да ныгыту өчен, укучыларны парларда эшләтәбез. Мондый ситуация тудырабыз: беренче парны чакырам, сез алда кабатланган биремнәр белән эшлисез. Күз алдыгызга китергез: сез күптән хыялланган машинагызны сатып алдыгыз, сездә бик зур шатлык. Беренчегез – алмалар турындагы санамышны, икенчегез «Мин җыям» биремен бик шатлыклы эмоцияләр белән бер-берегезгә җиткерегез. Сезнең арада аралашу барырга тиеш.

Икенче парны чакырам: Сезгә башка хәл: хезмәт хакыгызны 1 айга тоткарладылар. Сездә нинди эмоция туар? Шушы ук биремнәр аркылы эмоцияләрне бер-берегезгә җиткерергә тиешсез. Исегездә тотыгыз: татар авазларын ачык, төгәл итеп әйтүгә ирешергә кирәк.

Әлеге алымны мин **фонетик этюд** дип атадым. Авазларны кабатлау укучыларга кызык түгел. Әгәр без укучыларга мондый эмоциональ биремнәр тәкъдим итәбез икән, ул елмаю, көлү белән башкарыла. Психология законнары буенча, авазларның әйтелеше дә истә ныграк берегеп кала.

Истә калдыру өчен, тагын бер кызык алым турында сөйләп китәр идем. Ул **ритмик истә калдыру** дип атала. Без шул ук текст белән эшләрбез. Бу очракта миңа ярдәм итүегез, бер ритмда кул чабуыгыз сорала.

Рэп:

1 нче куплет:

Бер алма, ике алма,

Өч алма, дүрт алма,

Биш алма, алты алма,

Җиде алма, сигез алма,

Тугыз алма, ун алма –

Кызыл алма.

Кушымта шикелле: *мин җыям, син җыясың, ул җыя. Без көләбез, сез көләсез, алар көләләр.* Эшләп карыйк әле.

– Рәхмәт, ә хәзер, әйдәгез, музыка белән.

*(Яңадан җырлана.)*

Әлбәттә, рэпны татар җыр культурасы өчен чит күренеш дип атарга була. Әмма мин нәкъ шушы жанрны укучыларны яңа, яшьләр субкультурасына якын булуы өчен сайламыйм. Минем өчен бу очракта мөһиме шул: рэп укыган вакытта бала үзенең вокал сәләтләре өчен читенсенми, сүзләрне, авазларны кычкырып, ачык итеп әйтә. Рэп белән эшләгәндә исә, бер яктан, музыкаль фон, ритм бар, шул ук вакытта беркем дә үзен кыен хәлдә дип хис итми, оялмый.

Укучылар биргән икенче сорауны хәтерлисезме? «Ә ни өчен без шул кадәр күп фигыльләр өйрәнәбез?» – дип сорады алар. Бу яктан мин өйрәнелә торган фигыльләрнең актив, ягъни аралашуда даими кулланылуларына игътибар итәм, шулай ук татар телендә фигыльләрнең гадәттә күп мәгънәле булуы хакында сөйлим. Моны раслау өчен **«тәкъдим ителә торган шартлар»** алымын кулланам. Мәсәлән, бүгенге дәрестә без җыю фигыленә мөрәҗәгать иткән идек. Аны нинди шартларда кулланып була, бергәләп тикшерик әле.

– Коллегаларым, тагы парларда эшлибез. Сезнең алда сюжетлы картина. Сезнең бурычыгыз – *җыя* фигылен кулланып диалог төзү һәм сәхнәләшерү.

1 нче картина – баланың бүлмәсе тузган.

– Нинди диалог корырга була?

2 картина – балалар бакчада уңыш җыялар.

– Бу рәсемгә карап нәрсә диярсез?

**«Тәкъдим ителә торган шартлар»** алымын татар телен чит тел буларак өйрәнүдә еш кулланырга була. Билгеле булганча, без бу дәресләрдә еш кына диалогка чыгуны күздә тотабыз, чөнки диалог – аралашуның төп чарасы. Әмма даими кулланыла торган алым буларак, ул балаларны ялыктыра ала. Укучыда кызыксыну көчәйсен өчен, диалогны менә мондый ситуацияләр, рәсемнәр, тавыш, костюм, декорация элементлары белән тулыландырырга мөмкин. Шул вакытта диалогыбыз тормышчан, тере булачак.

Минем уйлавымча, театр педагогикасы алымнары төрле предметларны укытканда да нәтиҗәле кулланыла ала. Бу алымнарны һич кенә дә ял итү, күңел ачу дип кабул итәргә ярамый. Театр педагогикасына нигезләнгән дәресләр – иҗат педагогикасы, импровизация, иҗади фикер йөртү дәресләре.

22 ел татар телен укыту дәверендә шуңа инандым: һәр дәреснең нигезен иҗат тәшкил иткәндә генә, ул бала күңелендә озакка, хәтта, ышанасы килә, гомергә истә калачак. Сүземне шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Укып кына, ятлап кына телгә өйрәтеп булмый,

Җансыз, кансыз, соры сүздән күңелдә шатлык тумый.

Сүз уйнасын, уянсын дисәгез,

Сез аны яңа шартлар белән бизәгез.

Төрле шартларда сүз төрлечә уйный,

Иҗатның көче зур – инкарь итеп булмый.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!




# АНА ТЕЛЕБЕЗНЕ ӨЙРӘНҮДӘ «ШИГЪРИ ӘЛИФБА»



**Резилә МИНҺАҖЕВА,**

Яр Чаллы педагогия көллиятенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Балаларга башлап ни укырга һәм ничек укырга дигән сорау күпләрне кызыксындыра. Билгеле, балачакның башлангыч чорында беренче урында уен торганлыктан, сабыйда китапка карата кызыксыну күзәтелми диярлек.

Баланың китапка карашы, мөнәсәбәте 3 – 5 яшьтә формалаша башлый. Әгәр ул өлкәннәрнең кызыксынып китап укыганнарын күзәтеп үссә, үзеннән-үзе кулына китап алачак. Күп очракта сабыйны китап белән таныштыруны өлкәннәр башкара.

Мәктәпкәчә чорда китапның бала тормышында роле дә арта төшә: китап уен, сөйләм, театраль, хезмәт шөгыльләренә нигез булып тора. Китап-уенчык, китап-театр, китап-буягыч, китап-әлифба һ.б. балада кызыксыну уята торган предметлы мотивка әйләнә. Мәктәпкәчә яшьтәге баланы әнә шул төсле сурәтле беренче китаплары сихри әдәбият дөньясына алып керә. Китап сабыйларга башлап дөнья сурәтен ача, аның образларын танып белергә, анда ориентлашырга өйрәтә, белемгә омтылыш тәрбияли, мәктәпкә әзерли.

Шунысы куанычлы: Татарстан китап нәшриятында соңгы елларда балалар өчен бик күп кызыклы китаплар дөнья күрде. Безнең игътибарны шагыйрь Рифат Сәлах тарафыннан төзелгән, мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына адресланган «Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч»[1] китабы җәлеп итте.

Әлифбада татар теленең һәр 39 хәрефенә мисал итеп, кызыклы табышмак-

[1] Сәлах Р. Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч / [төз. Р.Сәлах]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 40 б.

лар урнаштырылган. Шигъри табышмакларның 24 се автор-төзүче Р.Сәлах тарафыннан иҗат ителсә, калган 15 ен шагыйрьләр Йолдыз, Г.Гыйльманов, Л.Шәех, Газинур, Мөҗәһит, И.Ногманов, Ф.Гыйләҗев, Ф.Җамалетдинова язган. *М* хәрефен танытучы Мөгезборын турындагы табышмак Ш.Галиев иҗатыннан алынган.

Китап балаларны нигездә хайваннар дөньясы белән таныштыра. Үсемлек дөньясыннан да бер табышмак тәкъдим ителгән ул, Ылыс турында (авторы Л.Шәех).

Әлеге китапның үзенчәлеге шунда: аны башлангыч сыйныфтагы төп «Әлифба» белән янәшә дә, аңа кушымта буларак та, аерым буягыч итеп тә, табышмаклар китабы, сәнгатьле уку өчен текст буларак та, «Әйләнә-тирә мохит» предметы буенча караш-белемнәрне үстерү һәм киңәйтү максатыннан да уңышлы кулланып була.

Универсаль эчтәлекле бу әлифба үзенең төсле хәрефләре, матур рәсемнәре белән балаларда хәрефләр танып, башлап уку теләген уята. Хәрефләрне отып, иҗекләп укырга өйрәнгәч, әлеге гамәлләрне йөгерек һәм сәнгатьле итеп уку белән ныгытып куярга киңәш ителә. Укуга мотивацияне төрле һәм кызыклы биремнәр аша тудырып була: яхшы, дөрес, йөгерек, сәнгатьле яисә салмак, сузып, кычкырып, барысы ишетерлек итеп укырга һ.б.

Әлифбада татар хәрефләре санынча урнаштырылган, һәр табышмак та үзенә күрә кыска, афористик характерда. Алар – балаларның танып белү активлыгын үстерү чарасы. Бар табышмакның да эчтәлегенә сорау яисә бирем салынган, текстында шул предмет, аның сыйфат үзенчәлеге турында мәгълүмат бирелгән. Табышмакның шигъри формада булуы балалалар өчен аерата отышлы. Ул танып белү процессын җиңеләйтә, бәйләнешле сөйләм һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерә.

Табышмакка җавап табу – акыл көчен сынау һәм камилләштерү өчен менә дигән шөгыль. Ул балаларда акыл активлыгын, тиз уйлау, тапкырлык, зирәклек, логик фикер йөртү кебек сыйфатларны үстерә. Гадәттә, табышмак асылына төшенү, төрле предметлар арасында охшашлыкны раслау яисә инкарь итүгә корылган. Бала предметара бәйләнеш, әйләнә-тирә мохит күренешләренең үзенчәлеген төсмерләргә, танып белергә, ул эчтәлеккә яшеренгән предмет турында фикер йөртергә өйрәнә, анализ, гомумиләштерә белү күнекмәләре ала. Дөрес җавап баланың күңелен күтәрә, белем алуга этәргеч ролен үти.

Шигъри әлифбада тасвирланган хайваннарның исемнәре чагыштыру алымы ярдәмендә ачыклана. Мисал өчен, *Жираф* сүзе түбәндәге чагыштыру артына яшеренгән:

Муены бик озын аның,

Яфрак ашый үрелеп.

Бераз капланга охшаган,

Бераз дөя дә кебек.[2]

Табышмак биреме Җир крокодилы Варанны үз семьялыгыннан булган алып гәүдәле динозавр һәм нәни кәлтә еланы белән чагыштыра, яшәү урыны турында мәгълүмат та биреп уза:

Динозаврдан кечерәк,

Кәлтә кебек сөйрәлә.

Җир крокодилы исемле

Ул Индонезиядә.[3]

Гомумән, хайваннар турындагы табышмаклардан бала хайванның размеры, төсе, холкы-фигыле, яшәү урыны, рәвеше турында кызыклы информация ала. Әйтик, Гиппопотамны шагыйрә Йолдыз болай тасвирлый:

Ит ашамый бу хайван,

Үлән генә ярата.

Тамагын туйдыруга,

Ләмгә күмелеп ята.[4]

Поши турындагы табышмактан аның яшәү урыны, мөгезенең тармакланган булуыннан тыш, юл кагыйдәләре белгесендә сурәтләнүен белеп була. Г.Морат табышмагында ул хакта болай искәртә:

Урманда гомер итә ул,

Мөгезе тармак-тармак.

Үзе юл күрсәткеченнән

Безгә дә тора карап.[5]

Әлеге шигъри әлифбада һәр әйберкүренешне үрнәк буенча төсле буяулар белән буяу мөмкинлеге балаларда рәсем ясау сәләтен үстерә, сәнгатиэстетик зәвык формалаштыра. Әлифбаның рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире һәр тереклек иясенең рәсемен шигъри табышмакның эчтәлегеннән чыгып, балалар өчен яраклаштырып, буяу өчен гадиләштереп, истә калырлык итеп сурәтләгәннәр.

Йомгаклап, шуны әйтик: балаларда уку культурасы тудыруда, әдәбият дөньясына карата кызыксыну уятуда үзенчәлекле күпер ролен үти торган «Шигъри әлифба» – һәр өйдә, балалар бакчасында, башлангыч мәктәптә булдырылырга тиешле китап. Аның туган телебезне хөрмәт иткән, ана телендә фикерле белгән һәм яхшы аралашкан милләт зыялылары үстерүгә хезмәт итәчәгенә ихлас ышанып калабыз.

---

[2] Сәлах Р. Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч / [төз. Р.Сәлах]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 9.

[3] Сәлах Р. Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч / [төз. Р.Сәлах]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 4.

[4] Сәлах Р. Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч / [төз. Р.Сәлах]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 5.

[5] Сәлах Р. Шигъри әлифба: балалар өчен табышмаклар, буягыч / [төз. Р.Сәлах]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 21.



09

# -ЧЫ / -ЧЕ – СҮЗ ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР

*(III сыйныфның рус төркемендә татар теле дәресе)*



**Хәния ЗАРИПОВА,**

Казандагы 47 нче мәктәпнең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес тибы:** грамматик күнекмәләр формалаштыру.

**Максатлар:**

*белем бирү максаты:* -чы/-че сүз ясагыч кушымчалары, һөнәр исемнәрен белдерә торган сүзләр белән таныштыру; аларны сөйләмдә кулланырга күнектерү.

*үстерү максаты:* укучыларның төрле ситуацияләр һәм биремнәр аша фикер эшчәнлекләрен, уйлау сәләтен үстерү.

*тәрбия бирү максаты:* төрле һөнәр ияләренең хезмәтенә ихтирам, үзара аралашу һәм ярдәмчел булу күнекмәләрен тәрбияләү.

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре:**

**Шәхси нәтиҗәләр:** укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*регулятив:* укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү; укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

*коммуникатив:* башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү, әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; парларда эшли белү;

*танып белү:* укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.

**Җиһазлау:** ноутбук, проектор, рәсемнәр, таратма материал.

**Материал:** дәреслек, 16 – 17 нче битләр.

**Методлар:** проблемалы, аңлатмалы-иллюстратив, өлешчә-эзләнү.

**Эш формалары, алымнары:** укытучы сүзе, дәреслек белән эшләү, аудирование, фронталь / группада / парларда эш.

**Технология:** коммуникатив технология нигезендә, Сингапур структурасын куллану.

**Кулланылган Сингапур структуралары:**

а) ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН

б) РЕЛЛИ РОБИН

в) МИКС-ФРИЗ-ГРУП (ял вакытында)

г) КОНЭР

д) КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД

е) ИНСАЙД-АУТСАЙД СЁКЛ (рефлексия)

**Дәреснең барышы**

**I. Оештыру моменты**

1. ХАЙ ФАЙВ структурасы ярдәмендә укучыларның дәрескә игътибарын туплау.

– Исәнмесез, укучылар!

– Исәнмесез!

– Хәерле көн!

– Хәлләрегез ничек?

– Бик яхшы!

– Дәресебезне башлыйбыз. Бүгенге дәресебезне без сезнең белән төрле структуралар кулланып алып барырбыз.

**II. Актуальләштерү**

1. Фонетик зарядка.

А) Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].

*Төзүче, китапханә, китә, көн, тәмле, кыска, дәрес, көз, җылы, елга, коела.*

Б) Прослушайте и скажите данные слова во множественном числе.

*Елга, балык, кояш, бакча, көн, укытучы, урам, агач, үлән, кош, сүз*.

2. ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН *структурасы (Встать – сесть)*.

– Укучылар, мин сезгә җөмләләр әйтәм, риза булсагыз – басасыз, риза булмасагыз – утырасыз.

1) Мин – укытучы.

2) Мин Казанда яшим.

3) Бүген көн эссе.

4) Мин укучы түгел.

5) Мин 43 нче мәктәптә укыйм.

6) Татарстанның башкаласы – Мәскәү.

7) Безнең сыйныфта малайлар күбрәк.

8) Елның дүрт фасылы бар.

**III. Уку мәсьәләсен кую**

Теманы ачыклау. Яңа төшенчәләр формалаштыру.

Дәреснең темасы әйтелә: «Исем ясагыч кушымчалар. Словообразовательные окончания».

**Укытучы.** Мин мәктәптә кем?

– Укытучы.

– Ә сез мәктәптә кем?

– Укучы.

– От какого слова?

– *Уку – учеба.*

– Как называется эта часть слова?

– Основа.

– Что такое основа слова?

– Часть слова без окончания.

– Окончание татарча ничек була?

– Кушымча.

– *Укытучы, укучы*. Бу сүзләрдә нинди кушымча бар?

– *-чы.*

– Получите новые слова от слов *тәрбия, эш, китапханә.*

1 укучы тактага чыгып яза: *тәрбияче, эшче, китапханәче.*

– Значит, с помощью каких окончаний можно образовывать новые имена существительные?

– С помощью окончаний *-чы / -че.*

3. 16 нчы бит, 2 нче күнегү.

– Сүзләрдән профессия (һөнәр) исемнәре ясагыз, тәрҗемә итегез.

*балыкчы – рыбак*

*тимерче – кузнец*

*эшче – рабочий*

*китапханәче – библиотекарь*

*нефтьче – нефтяник*

*(Дөрес җаваплар интерактив тактада күрсәтелә.)*

РЕЛЛИ РОБИН. *Укучылар бер-берсенең җавапларын тикшерәләр.*

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту**

– Значит, как образовываются новые имена существительные?

– Путем присоединения аффиксов *-чы / -че* к основе слова.

– Поэтому они называется словообразовательными окончаниями.

1. Ә хәзер уйлагыз, кем турында сүз бара?

а) Ул мәктәптә эшли. Балалар укыта. *(Укытучы. Әйе, экранда укытучы рәсеме чыга.)*

б) Ул хастаханәдә эшли. Анда кешеләрне дәвалый.

в) Ул кибеттә эшли. Төрле әйберләр сата.

г) Ул безгә матур йортлар сала.

д) Ул ашханәдә эшли. Безгә бик тәмле ашлар, боткалар һәм башка ризыклар пешерә.

е) Ул безгә төрле киемнәр тегә.

2. Кем кайда эшли? Сез килешәсезме?

• Табиб укыта.

• Бакчачы пешерә.

• Биюче бии.

• Тегүче сата.

• Сатучы төзи.

• Укытучы тегә.

• Пешекче дәвалый

• Төзүче утырта.

3. Укучылар җөмләләрне төзәтәләр. *(Мәсәлән: Юк, төзүче төзи. Әйе, биюче бии.)*

**V. Ял минуты.** МИКС-ФРИЗ-ГРУП структурасы.

*Музыка яңгырый. Музыка туктагач, сорауга җавап булган санга берләшеп басалар. Шул рәвешле 4 биремне дә үтиләр.*

1. Бүген дәрестә ничә сүз ясагыч кушымча белдегез?

2. *Җырчы* сүзендә ничә хәреф бар?

3. *Төзүче* сүзендә ничә саф татар хәрефе бар?

4. *Укытучы* сүзендә ничә *у* хәрефе бар?

**VI. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү**

1. Аудирование. Шигырьдән һөнәр исемнәрен табу.

Укытучы Хәләф Гардановның «Безнең урам» шигырен сәнгатьле итеп укый, ә укучылар игътибар белән тыңлый.

**Бирем.** Шигырьдә *-чы / -че* кушымчасы белән ничә һөнәр исеме бар?

**Безнең урам**

Безнең урам – зур урам,

Мин шул урамда торам.

Тирә-якта күршеләр,

Бар да уңган кешеләр.

Сара апа – сатучы,

Бану апа – бакчачы,

Тәүфыйкъ абый – тимерче,

Тимербикә – тегүче.

Кадыйр абый – командир,

Бакый абый – бригадир,

Шакир – шофер,

Мансур – монтер.

КОНЭРС.

– Укучылар, бер санны гына яздык. Сыйныфның дүрт җирендә – 4, 5, 6, 8 саннары язылган почмаклар. Кем шигырьдә ничә һөнәр исеме бар дип уйлый, шул почмакка баса. Үзенә пар эзли. Бер-берегезгә ни өчен шушы почмакны сайлавыгызны аңлатыгыз. Кемнең буе кыскарак, беренче шул укучы аңлата. *(Укытучы вакыт билгели.)*

– Укучылар, кайсы пар җавап бирергә әзер?

2. «Дөрес җавап табабыз» уены

А. Кайсы сүз артык?

а) мәктәп, б)дәрес, в) **төзүче.**

Б. Кем ашханәдә эшли?

а) **пешекче**, б) бакчачы, в) укытучы

В. Ул китаплар яза.

а) эшче, б) **язучы,** в) очучы

Г. Нефть..?

а) -чы, б) **-че**, в) -чэ

Д. Кайсы сүз һөнәр түгел?

а) сатучы, б) урманчы, в) **кайчы**

**VII. Яңа белемнәрне ныгыту**

1. Уйлап карагыз. Кем нишли?

Китапханәче … бирә.

Укытучы … укыта.

Тегүче … тегә.

Төзүче … төзи.

Сатучы … сата.

Пешекче … пешерә.

*(Экранда төрле рәсемнәр дә күрсәтелә.)*

Мәсәлән: Китапханәче китап бирә.

2. «Ул кем?» уены. КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД.

– Укучылар, өстәлдә уртада биремнәр ята. Карагыз әле, нәрсәләр язылган? Үзегезгә пар табасыз. Җөмләгезне укыйсыз. Иптәшегез сезгә җөмләгә туры килгән һөнәр исемен әйтә. Җавабы дөрес булмаса, сез аңа булышасыз. Дөрес җавап ишеткәч, иптәшегезне мактыйсыз һәм аның җөмләсен тыңлыйсыз. Җавап бирәсез. Аннан соң биремнәрегез белән алышасыз. Комплиментлар әйткәч, үзегезгә икенче, өченче пар эзлисез. Шул рәвешле күбрәк һөнәр исемен истә калдырырга кирәк. Сезгә өч минут вакыт бирелә.

1) Ул мәктәптә укыта. *(Укытучы)*

2) Ул кибеттә ашамлыклар сата. *(Сатучы)*

3) Ул фабрикада  күлмәкләр тегә. *(Тегүче)*

4) Ул шәһәрдә йортлар төзи. *(Төзүче)*

5) Ул заводта эшли. *(Эшче)*

6) Ул сәхнәдә бии. *(Биюче)*

7) Ул күлдә балык тота. *(Балыкчы)*

8) Ул сәхнәдә бик матур җырлый. *(Җырчы)*

9) Ул ашханәдә тәмле ашлар пешерә. *(Пешекче)*

10) Ул урманны саклый. *(Урманчы)*

**VIII. Рефлексия**

ИНСАЙД-АУТСАЙД СЁКЛ структурасы ярдәмендә үзләренең партнерлары белән дәрес турында фикер алышалар.

1. Сделай столько шагов сколько букв в слове *писатель* на татарском языке. Повернулись друг другу обменялись мнениями о уроке.

2. Укытучы рус телендә әзер сораулар тәкъдим итә ала.

**Үрнәк.**

– Ты сегодня какие профессии узнал?

– Тебе какая профессия нравиться?

– Почему?

– Понравился ли тебе урок?

– Что понравилось больше всего?

– Что нового ты узнал на уроке?

3. Берничә парның диалогын тыңлау, бәяләү.

**IX. Йомгаклау**

**Укытучы.** Сез, үскәч, кем булырсыз? Уйлагыз. Бер-берегездән сорагыз. Мәсәлән:

– Рената, син кем буласың?

– Мин табиб булам.

– Ул нишли?

– Ул кешеләрне дәвалый.

**Укытучы.** Укучылар, нинди генә һөнәр сайласагыз да, эшегезне яхшы итеп, җиренә җиткереп башкарырга кирәк. Һәр хезмәт кешесе хөрмәткә лаек.

**X. Өй эше бирү**

*(Һәр укучы, үз мөмкинлекләреннән чыгып, өй эшен сайлый.)*

1. «Әти-әниемнең һөнәре» дигән темага хикәя язып килергә.

2. «Сиңа нинди һөнәр ошый?» дигән темага диалог төзергә.

3. Дәреслекнең 16 нчы битендәге 5 нче бирем.

**Укытучы.** Бүгенге дәрестә һөнәрләр, һөнәр исемнәренең ясалышы турында сөйләштек. Дәрестә бик яхшы эшләдегез. *(Билгеләр куела.)* Дәрес тәмам. Сау булыгыз!



# «ӘБИСЕ БЕЛӘН ОНЫК» ӘСӘРЕНДӘ БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ФИГЫЛЬЛӘРЕН КҮЗӘТҮ

*(Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә корылып төзелгән туган тел дәресенең технологик картасы, IV сыйныф)*



**Резеда ИСМӘГЫЙЛОВА,**

Түбән Кама мәгариф идарәсе методисты



**Эльза БӘДГЫЕВА,**

Түбән Кама шәһәренең аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 31 нче урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәреснең предмет нәтиҗәсе:** «Әбисе белән онык» әсәрендә билгесез әткән заман фигыльләрен күзәтү, аларны сөйләмдә куллану.

**Дәреснең метапредмет нәтиҗәләре:** алдан алган белемнәрне төрле ситуатив күнегүләрдә куллана белү; үзбәя куя белү; төркемнәрдә киңәшләшеп эшли белү, парларда бер-берсен тикшерә белү, укылган текстта ориентлашу, ишетеп аңлау.

**Дәреснең шәхси нәтиҗәсе:** олыларны хөрмәт итү, әби-бабайларга булышырга теләк тудыру.


**Төп төшенчәләр:** билгесез үткән заман фигыльләре.

**Укыту-методик комплекс:** ноутбук, проектор, экран, дәреслек: Хәйдәрова Р.З. Татар теле һәм уку китабы: Рус телендә белем бирүче дүртъеллык башл.мәкт. 4 нче с-фы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен): Ике кисәктә / Р.З.Хәйдәрова. – Казан: Мәгариф, 2015. – 123 б., укучыларның сүзлек дәфтәрләре; http://balarf.ru/ сайтында урнаштырылган «Әбисе белән онык» әсәренә презентация.

## Дәрес барышы

| Дәреснең дидактик этаплары | | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Шәхси нәтиҗә | Метапредмет нәтиҗәсе Танып белү, коммуникатив, регулятив (универсаль уку гамәлләрен формалаштыру) | Предмет нәтиҗәсе |
| **I. Мотивлаштыру-ориентлашу этабы** | 1. Уңай халәт тудыру | Исәнләшү, хәлләр сорашу, уңышлар теләү | Исәнләшәләр, хәлләр сорашалар | Дәрескә карата уңай мөнәсәбәт | Дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту. | Авазларны дөрес әйтеп сөйләшү, синонимнар куллану |
| | 2. Белемнәрне тигезләү | *– ган* кушымчасын күрсәтә һәм түбәндәге таблица тәртибендә мәгълүмат җыя<br>**1. Кушымчалар яз**<br>**2. Мисаллар китер**<br>**3. Сораулар бир**<br>**4. Җөмлә төзе**<br>**5. Аңлатма бир** | Телдән җавап бирәләр, һәрберсен парларда кабатлап чыгалар:<br>*1. –ган / -гән, -кан / -кән*<br>*2. утырган, сөйләгән, кайткан, киткән*<br>*3. Нишләгән?*<br>*4. Әби кибеттә эшләгән.*<br>*5. В прошедшем времени, если своими глазами не видели (яки билгесез үткән заман, неопр. прош. вр.)* | | Синтез-анализ алымнарын кулланып эш итә белү. | Билгесез үткән заман фигыльләре турында сөйли белү |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 3. Үзбәя | – Барыбыз бик яхшы җавап бирдек, билге куегыз. | Дәрескә беренче уңай билге куела  число: 14.04<br>укучы: П.Саша<br>сыйныф: 4 а<br>бирем \| билге<br>нәтиҗә | Дәрескә уңай мөнәсәбәт | Үзбәя куя белү | |
| | 4. Уку максатын кую | Билгесез үткән заман фигыльләрен без нинди әсәрләрдә очраттык?<br>Бүген тагын бер кечкенә әсәр белән танышабыз. Ни өчен дип уйлыйсыз? | – Тарихи әсәрләрдә, әкиятләрдә.<br>– «Карга боткасы» хикәясендә.<br>– Укыйбыз һәм билгесез үткән заман фигыльләрен күзәтәбез | Татар телен өйрәнүгә кызыксыну | Максат куя белү. Аңлап эш итү. | |
| **II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы** | Бирем 1 | *Аудирование.* http://balarf.ru сайтында урнаштырылган «Әби белән онык» хикәясен тыңлата http://balarf.ru/ipad/library.html?id=85.<br>Алдан ике сорау бирә:<br>1. Хикәядә кем бар?<br>2. Ул нишли? | Көтелгән җавап:<br>*Хикәядә әби һәм аның оныгы бар. Башта кыз кечкенә булган. Әби барлык эшләрне үзе эшләгән. Аннары кыз үскән, барлык эшләрне үзе эшләгән.* | | Ишетеп аңлау.<br>Алдан өйрәнелгән объектларны яңа объектлар белән чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү. | |
| | Үзбәя 1 | Кемнең җаваплары безнең җаваплар белән туры килде «5» ле куя аласыз. Кемнеке туры килмәде билгесез каласыз. | Критерийларга таянып үз эшләрен бәялиләр | | Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү; | |
| | Бирем 2 | 1. Бу хикәядәге фигыльләрне күзәтеп карыйк, алар нинди заманда?<br><br>Ахырдан барлык фигыльләрне экранда ачып күрсәтә, шул ук фигыльләр язылган карточкаларны төркемнәргә тарата.<br>– Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә тәрҗемә итегез. Аңламаган сүзләрне бергә тәрҗемә итәрбез.<br>Бер-ике баладан лексиканы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерә. Парларда бер-берсен тикшерергә куша. | Берәр җөмлә тыңлыйлар, фигыльләрне чылбыр тәртибендә әйтеп баралар: *яшәгән, булган, булган, йоклаган, эшләгән, пешергән, җыештырган, юган, теккән, картайган, менеп яткан, үсеп җиткән, пешергән, җыештырган, юган, теккән.*<br>Төркемнәрдә тәрҗемә итәләр, тәрҗемәне язып баралар, тәрҗемә итә алмаган сүзләрне бергә укытучы ярдәме белән тәрҗемә итеп карыйлар<br><br>Парларда бер-берсен тикшерәләр | | Индуктив, дедуктив фикерли белү.<br>Ихтыяр көче, максатчанлык, гаделлек, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.<br><br>Төркемдә киңәшләшеп эшли белү<br><br>Парларда бер-берсен тикшерә белү, коммуникациягә керә белү. | Ишетеп фигыльләрне аңлау<br><br>Лексиканы үзләштерү |
| | Үзбәя 2 | Үзбәя куярга куша<br>«5» ле – сүзләрнең тәрҗемәсен белсә;<br>«4» ле – бер-икесендә ялгышса;<br>«3» ле – өч-биш хата ясаса | Критерийларга таянып үз эшләрен бәялиләр, билгене карточкага куялар. | | Билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. | |
| | Нәтиҗә 2 | – Бу фигыльләр нинди заманда? | – Бу фигыльләр билгесез үткән заманда. | | | Билгесез үткән заманда килгән фигыльләрне белү |
| | Бирем 3 | – Бу хикәя дәреслектә бар. Текстны уку. Әйдәгез текстны укып чыгыйк. Татар авазларын дөрес әйтеп укыйсыз микән. | Чылбыр тәртибендә укыйлар. | | Иптәшеңнең укуын тыңлый белү | Татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп уку |
| | Үзбәя 3 | Билге куегыз.<br>Хатасыз укуга – «5»ле,<br>1 хаталы укуга – «4»,<br>2 хаталы укуга – «3».<br>– Катя, син ничәле куйдың һәм ни өчен?<br>– Артём, син ничәле куйдың һәм ни өчен? | Критерийларга таянып үз эшләрен бәялиләр, ни өчен шундый билге алганнарын аңлаталар.<br>– Мин «5»ле куйдым, чөнки хатасыз укыдым.<br>– Мин «4» ле куйдым, чөнки бер хата ясадым (бер хатам бар, хаталы укыдым). | Кеше эшенә анализ ясау | Билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. | |
| | | Текстта ориентлашу.<br> | Һәр төркем рәсемгә туры килгән җөмләне табып укый<br>1 нче төркем:<br>*Кызчык йоклаган да йоклаган.*<br>Өстәмә бирем: Кыз ни өчен йоклаган, әллә ул ялкаумы?<br>*– Кыз ялкау түгел, ул кечкенә, шуңа йоклаган.* | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бирем 4 | <br><br> | 2 нче төркем:<br>*Әби икмәк пешергән.*<br>Өстәмә бирем: «ипи» сүзен синоним белән алыштырып укыгыз.<br>*Әби икмәк пешергән.*<br><br>3нче төркем:<br>*Әби теккән.*<br>Өстәмә бирем: Әбигә характеристика бирегез – ул нинди?<br>*– Әби тырыш, эшчән, игътибарлы.*<br><br>4 нче төркем:<br>*Кыз әбигә икмәк пешергән.*<br>Өстәмә бирем: «мич башына яткан» гыйбарәсен ничек аңлыйсыз?<br>*Легла на печку.*<br>*Кызга характеристика бирәләр* | | Укылган текстта ориентлашу.<br>Төркемдә киңәшләшеп эшли белү | Текстта ориентлаша белү. Укыганны аңлау, бирелгән сүзләрне синонимнар белән алыштыру. |
| | Үзбәя 4 | Билгене төркемгә куйдыра | Төркем алган билгене үз карточкага куя | | | |
| | Бирем 5 | Текст эчтәлеге буенча эш.<br>Һәр укучыга бер җөмлә бирелә:<br>*Ул әбигә булышкан.*<br>*Үзе карт, үзе тырыш.*<br>*Ул картайгач мич башына яткан.*<br>*Ул кызга савыт-саба юган.*<br>*Ул яшь булмаган, ә күп эшләгән.*<br>*Ул тәмле икмәк пешергән.*<br>*Ул кызга икмәк пешергән.*<br>*Ул зур ускәч кием-салым теккән.*<br>*Малай әбисенә булышкан.*<br>*Кыз ялкау булган.*<br>*Ул балык тоткан.*<br>*Әбинең 2 оныгы булган.* | Булмә почмакларында беркетелгән үз җөмләләренә туры килгән ӘБИ, КЫЗЧЫК, ТЕКСТТА ЮК язулары янына басалар.<br><br>3 укучыны дөрес басу-басмавын бергә тикшерәләр, шул 3 укучы һәр төркемнекен тикшерә, икеләнгән очракта җөмлә уртага салып анализлана. | | Бер-берсен тикшерә белү | Лексик-грамматик минимумны үзләштерү |
| | Үзбәя 5 | Дөрес почмакка басучыга – «5»ле, хатаны танып төзәтеп басучыга –«4»ле,<br>сыйныфташы булышса – «3»ле. | Критерийларга таянып үз эшләрен бәялиләр, билгене карточкага куялар. | Дөрес бәяләү | Үзбәя куя белү. | |
| | Бирем 6 | 1. Ситуатив күнегүләр.<br>– Г.Тукай прожил всего 26 лет.<br>– Муса Джалиль писал стихи.<br>– Папа Кирилла купил машину.<br>– Мама Ромы уехала в Казань.<br>– Бабушка Артёма вчера сварила суп. | – Г.Тукай 26 ел гына яшәгән.<br>– Муса Җәлил шигырьләр язган.<br>– Кириллның әтисе машина алган.<br>Романың әнисе Казанга киткән.<br>– Артёмның әбисе кичә аш пешергән. | Татар телендә аралашуга омтылыш | Алдан өйрәнелгән лексик-грамматик формаларны сөйләмдә куллану. | Билгесез үткән заман фигыльләрен төрле ситуацияләрдә куллану |
| **III. Рефлексия.** | 1. Рефлексив синтез-анализ | Без бүген нинди кушымчалар турында сөйләштек?<br><br>**1. Кушымчалар яз**<br>**2. Мисаллар китер**<br>**3. Сораулар бир**<br>**4. Җөмлә төзе**<br>**5. Аңлатма бир** | Таблицага карап билгесез үткән заман фигыльләре турында мәгълүмат туплыйлар. Көтелгән нәтиҗә:<br>*1. -ган / -гән, -кан / -кән*<br>*2. Утырган, сөйләгән, кайткан, ...*<br>*3. Нишләгән?*<br>*4. Әби кибеттә эшләгән.*<br>*5. Для прошедшего времени, если своими глазами не видели (неопр. прош. время яки билгесез үткән заман)* | | Синтез-анализ алымнарын кулланып эш итә белү.<br>Белешмә төзи белү. | Темага караган белемнәрен берләштерү һәм ныгыту |
| | 2. Дәрескә үзбәя | Дәрескә үзбәя<br>Дәрестә үзләренә куйган барлык билгеләрен күздә тотып дәрестә эш сыйфатын бәя бирергә куша. | Билге куялар.  | Объектив үзбәя куя белү | Алдан әйтелгән критерийларга таянып үзбәя куя белү.<br>Укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү | |
| | 3. Өй эше | 1. Әсәрдән барлык фигыльләрне бер баганага язып алырга.<br>2. Тәрҗемә язарга.<br>3. Язуларга таянып әсәр эчтәлеген сөйләргә. | Көндәлеккә язалар. | Татар телендә сөйләшергә омтылыш | Үрнәк буенча, чагыштыру, синтез-анализ алымнарын кулланып эш итә белү. | Өйрәнгән конструкцияләрне куллана белү. |



# САННАРНЫҢ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*(VI сыйныфта дәрестән тыш чара)*



**Гүзәл ШӘРӘФИЕВА,**

Казандагы 8 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы



**Әлфия МӨКМИНОВА,**

Казандагы 8 нче гимназиянең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** сан сүз төркеменең татар халык авыз иҗатында кулланылышын тану күнекмәсен формалаштыру.

**Бурычлар:** квест-уен кагыйдәләрен ачу; татар халык авыз иҗатында саннарның төрлечә чагылышын табу; эзләнүнең нәтиҗәсен билгеләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*предмет:* халык акылы, тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу, сөйләмдә мәкальләр кулланырга өйрәнү, саннарны танып, таба белү;

*шәхескә кагылышлы:* җавап биргәндә үз-үзеңә ышаныч, төрле ситуацияләрдән чыга белү, күзаллау.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

*регулятив универсаль уку гамәлләре:* эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү, укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү, эш сыйфатына бәя бирә белү;

*танып белү универсаль уку гамәлләре:* укучыларның һәм укытучының уртак эше буенча нәтиҗәләр ясау; укытучы сорауларына җавап бирү өчен тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау;

*коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* парларда һәм төркемнәрдә эшли белү, башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау, иптәшеңнең җавабы белән килешү, бергә эшләү процессында сыйныфташлар белән уртак фикергә килергә кирәклеген аңлау һәм алар белән хезмәттәшлек итү, татар телендә әкияттән өзекне сәхнәләштерү.

**Предметара бәйләнеш:** татар әдәбияты, рәсем, җыр.

**Эшчәнлек технологиясе:** проблемалы укыту, коммуникатив, иҗади үсеш, уен технологияләре.

**Эшчәнлек формасы:** квест-уен.

**Юнәлеше:** гомуминтеллектуаль.

**Җиһазлау:** компьютер, карточкалар, уен үткәрү өчен кирәк булган предметлар.

**Чараның төзелеше**

I. Уңай психологик халәт, күтәренке кәеф булдыру.

II. Квест-уен турында мәгълүматны искә төшерү, эшчәнлеккә күрсәтмә бирү, кагыйдәләр белән таныштыру.

III. Уенның этапларын уйнау.

IV. Төп сүзне белү.

V. Нәтиҗәгә килү, бердәмлеккә ирешү.

*Уенда 6 тукталыш 6 биремне үз эченә ала. Һәр биремгә әйләнә-тирәдә җавап-ярдәмлек күзгә ташлана. Уен дәвамында бу таләп саклана. Һәр бирем максатка ирешү, бурычларны ачу, ирешеләсе нәтиҗәнең дәрәҗәсен күздә тотып төзелде.*

**Дәрестән тыш эшчәнлек барышы**

**I. Оештыру өлеше**

– Хәерле көн, балалар! Сезне күрүемә шатмын! Яхшы кәеф, матур теләкләр белән чарабызны башлыйбыз. Укучылар, сезнең квест уйнаганыгыз бармы? *(Укучыларның җавабы тыңлана.)*

**II.** – Нинди квестлар беләсез? *(Укучыларның җавабы.)*

– Тарихи, математик квестлар күргәнегез бармы?

– Әйдәгез, бүген татар квестын уйныйк. Нәрсә соң ул квест, балалар?

– Квест – инглиз теленнән «эзләү» дип тәрҗемә ителә.

– Димәк, бу уенда һәрвакыт нәрсәнедер эзләргә кирәк булган бирем яки сорау бирелә. Шуларны үтәп кенә алга барырга һәм финишка җитәргә була.

Һәр уенның кагыйдәләре була. Әйдәгез, карап китик әле.

1. Тәртип бозмаска, иптәшләрең белән бергә килешеп эшләргә.
2. Тирә-якны игътибар белән күзәтегез.
3. Кирәкле шифрларны эзләгез.
4. Башваткычларны, табышмакларны чишегез.
5. Ярдәмлекләрдән дөрес файдаланыгыз.

– Балалар, кагыйдәләр аңлашылдымы? *(Укучыларның җавабы тыңлана.)*

– Әйдәгез, капитан сайлыйк. *(Бер бала капитан була.)* Ә мин гел сезнең янәшәгездә булырмын, ярдәм итәрмен.

– Капитанга юллама (маршрутный лист) бирәм. Юлламада 6 бирем. Ахырда хәрефләрдән җыелган сүз килеп чыгарга тиеш. Ул хәрефләрне капитан язып бара. Кабинет буйлап йөрергә ярый.

**III. Квест.**

**1 нче тукталыш.**

– Биремне укыгыз. *(Балалар юлламадан укыйлар.)* Табышмакның җавабын белегез:

*Кабат-кабат бер кошта 365 канат.*

*Мин торам аны санап,*

*Көн дә кими бер канат.*

*Ишеккә* ***Календарь*** *беркетелгән. Календарьга ике конверт яшерелгән. Эчендә пазллар (пазлларны җыйгач, йөзек һәм өчпочмак рәсемнәре чыга).*

– Бу рәсемнәр белән нишлибез, балалар? Бәлки, берәр сер бардыр монда, уйлап карагыз әле, берәр төрле сан яшерен-

мәдеме икән. *(Укучыларның җавабы тыңлана. 103 санын табалар.)*

– Артын карагыз әле, нәрсә яшеренде икән? *(Артын әйләндереп карыйлар, анда **К** хәрефе.)*

– Капитан, юлламага языгыз. Мин тактага беркетәм.

**2 нче тукталыш.**

– Балалар, икенче бирем белән танышыгыз әле. Юлламада язылган.

*Акыллы кеше мәкальсез сөйләмәс.*

– Бу нинди сүзләр икән, балалар? Без моны ничек аңлыйбыз? *(Мәкальләрне белергә кирәк, аларны кулланып сөйләшергә кирәк.)*

– Бу биремне эшләргә кабинетта берәр ярдәмлек юкмы? *(Китап)*

– Әйдәгез, биремен карыйк. *(Эченнән конверт чыга.)*

– Капитан, биремне укыгыз әле.

***Бирем.*** *Тиешле саннарны сайлап, мәкальләрне язып бетерегез. (Төркемнәрдә башкарыла.)*

1) ... *уйла, ... эшлә.*

а) ике, бер

б) өч, бер

в) бер, ике

2) *Сереңне ... кешегә дә сөйләмә, киңәшеңне ... кешегә кыл.*

а) мең, бер

б) бер, мең

в) бер, ике

3) *Агач аеры үссә дә, тамыры ...*

а) өч

б) җиде

в) бер

– Мәкальләрне укыгыз әле, балалар. Җавапларыгызда нинди сан кабатлана? *(1)*

– Кайда икән 1 саны? Нинди хәреф табарбыз икән? **(ы)**

– Капитан, юлламага языгыз. Мин тактага беркетәм.

**3 нче тукталыш.**

– Капитан, юлламадан 3 нче биремне укыгыз. Нәрсә язылды икән?

**Бирем.** Мультфильмны игътибар белән карагыз. Утырабыз.

– Балалар, тутый кош нинди сан әйтергә тиеш булды икән? *(38)*

– Урыныгыздан тормыйча гына, күз белән эзләгез әле, кайда икән ул?

*(Өстәлдә вазага 38 беркетелгән. Ваза эчендә **Д** хәрефе.)*

– Капитан, юлламага языгыз. Мин тактага беркетәм.

**4 нче тукталыш.**

– Капитан, биремне укыгыз.

**Бирем.** Ребусны чишегез.

– Ә кайда икән соң ул ребус? *(Ребус: 5ЕК)*

– Нинди сүз килеп чыкты, балалар? *(Бишек)*

– Кабинетта бишек бармы икән? Эзләп карагыз әле.

– Менә бишек. Бу бишектә берәр сер юкмы? *(**Н** хәрефе)*

– Капитан, юлламага языгыз. Мин тактага беркетәм.

**5 нче тукталыш.**

– Капитан, алдагы биремне укыгыз.

**Бирем.** Әкият героеннан ярдәм сорагыз.

Мин тиен маскасын киям.

**Балалар.** Тиен, син безгә ярдәм итә алмассыңмы икән? Хәреф кайда икән?

**Тиен.** Бик ярдәм итәр идем дә, минем кире әкияткә кайтасым килә. Кайтарсагыз ярдәм итәм. Кирәкле хәрефне бирәм.

**Балалар.** Ә кайтарыр өчен нәрсә эшләргә кирәк соң?

**Тиен.** Миңа кызларны табарга иде. Кызларның әниләре авырый, аңа ярдәм кирәк.

– Беренче кыз кем була?

– Икенче кыз?

– Өченче кыз?

**Тиен** *(беренче кыз янына килеп).* Синең әниең авырый, аның янына барырга кирәк.

**Беренче кыз.** мин бара алмыйм, ләгәннәр чистартам.

**Тиен.** Алайса, син гомереӊ буе шушы ләгәннәреңнән аерылма! *(Кулына бака рәсеме тоттыра.)*

**Тиен** *(икенче кыз янына килеп).* Синең әниең авырый, аның янына барырга кирәк.

**Икенче кыз.** Һай, барыр идем дә, киндер сугам шул!

**Тиен.** Алайса, гомер буе син киндер сугып кына тор! *(Кулына үрмәкүч рәсеме тоттыра.)*

*Тиен Өченче кыз янына килүгә кыз торып йөгерә.*

**Тиен.** И бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине яратырлар, синең яхшылыгыңны онытмаслар.

– Балалар, бу нинди әкияттән, аңладыгызмы? Исегезгә төштеме? *(«Өч кыз»)*

– Әйе, татар халык әкияте «Өч кыз».

– Рәхмәт, сез миңа ярдәм иттегез. Мин сезгә А хәрефен бирәм. Капитан, юллямага язып куегыз.

**6 нчы тукталыш.**

**Бирем.** Җилпәзә-веерны табыгыз.

– Укучылар, җилпәзә гади генә түгел, серле, сихри. Әлеге җилпәзәдә язылган табышмакларның җавапларын языгыз. Күмәкләшеп эшләгез.

*Өч кат тун кигән, кем салдыра, шул елый. (Суган)*

*Әйтермен – миннән китәр, тыңламасаң, синнән китәр. (Сүз)*

*Исе юк, төсе юк, аннан башка тормыш юк. (Су)*

*Аяксыз, кулсыз рәсем ясый.(Суык)*

*Үзе шома, күбеккә күмә,*

*Хуш исле, я кем белә? (Сабын)*

*Бит-кулларны корыта, чисталыкны ярата. (Сөлге)*

– Укучылар, җавапларда берәр тәңгәллек-охшашлык күзәтмәдегезме? *(Җаваплар **С** хәрефенә башлана.)*

– Димәк, нинди хәреф килеп чыкты? *(С)*

– Капитан, язып куегыз. Мин тактага беркетәм.

**IV.** – Тактада һәм юлламада нинди сүз килеп чыкты?

| К | Ы | Д | Н | А | С |
|---|---|---|---|---|---|

– Капитан, хәрефләрне дөресләп куегыз әле.

– Димәк, сандык сүзе килеп чыкты.

– Балалар, сандык ачылмый бит. Нишләргә?

– Һәрбер квест ахырында хәзинә табалар. Бәлки сандык сүзендә берәр хикмәт бардыр? *(САН сүзе килеп чыга.)*

– Әйе, балалар, без квест дәвамында сан сүз төркемен кабатладык.

– Балалар, сандык ачылды бит. Эчендә нәрсә икән? *(Чәкчәк. «Чәкчәк» җыры яңгырый.)*

**V. Йомгаклау**

– Укучылар, квестның бөтен этапларын, кагыйдәләрен яхшы үттегез, бердәм булдыгыз, шуңа күрә дә нәтиҗәгә килеп җитә алдыгыз. Үзегезнең югары дәрәҗәдәге белемнәрегезне күрсәттегез, шуңа күрә дә татар халкының татлы ризыгын – чәкчәк алып килдем. Чәкчәк өемендә бөтен бөртек бергә, бердәм. Аның кебек татлы сүзле, бергә, бердәм булыгыз, балалар! Чәкчәкне капитанга бирәм. Соңыннан бергәләп чәй эчәрсез. Сау булыгыз!



12

# СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

*(VI сыйныф, татар төркеме)*



**Гөлия ВАГЫЙЗОВА,**

Яр Чаллы шәһәрендәге
41 нче урта мәктәпнең югары
квалификация категорияле татар
теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**

– сыйфат һәм аның дәрәҗәләрен хәтердә яңарту, аларга хас закончалыкларны тирәнәйтү, аларны аерырга өйрәнү;

– логик фикер йөртүне үстерү; сыйфатларны сөйләмдә активлаштыру, тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;

– укучыларда аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру; туган як табигатенең матурлыгын күрә белү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Предмет нәтиҗәләр:** сыйфат дәрәҗәләрен дөрес билгеләү, аера һәм сөйләм берәмлекләрен куллана белү; сүзнең эстетик вазифасын, сурәтләү көчен аңлау.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*шәхси универсаль уку гамәлләре:*

– туган телгә, табигатькә карата ихтирамлы мөнәсәбәт;

– алган белемнәрне куллана белү;

– уку эшчәнлегендә уңышка ирешүнең сәбәпләрен аңлау (тәртипле, игътибарлы, җаваплы булу, үз көчеңә ышану, активлык);

*регулятив универсаль уку гамәлләре:*

– мөстәкыйль рәвештә дәреснең темасын, максатын формалаштыру;

– проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару;

– үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү;

– үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, иптәшләреңнең җавабын бәяләү;

– кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту, аларга ияреп, гамәлләр кылу;

– үзбелем системасында ориентлаша белү, үзбәя;

– эшләнгән эшнең сыйфатын билгеләү;

***коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

– башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау, фикер алышуда катнашу;

– сыйныфташлар белән уртак фикергә килергә кирәклеген аңлау, ярдәмләшү, киңәш бирү, хезмәттәшлек күрсәтү;

– төркемдә уку эшчәнлеген оештыра белү;

– башка кешеләр белән аралашу барышында сөйләм чараларын сайлап ала һәм куллана белү (парлы диалог, кече төркемдә һ.б.);

– төрле фикерләрне кабул итү, чагыштыру, нәтиҗә ясау;

– үз фикереңне төгәл итеп әйтү;

***танып белү универсаль уку гамәлләре:***

– уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;

– төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;

– фикерләүдә логик чылбыр төзү;

– сөйләмдә өйрәнелгән материалны дөрес итеп куллана белү;

– ике яки берничә предметның, күренешнең гомуми билгесен табу, аларның охшашлыгын аңлату;

– аерым билгеләре буенча предмет һәм күренешләрне берләштерү, чагыштыру, классификацияләү, факт һәм күренешләрне гомумиләштерү;

– предмет һәм күренешләр арасындагы логик бәйләнешне билгели белү, аларны билге, схемалар аша күрсәтү;

– табигатькә үз мөнәсәбәтеңне белдерү;

– телне әдәбият, рәсем, музыка сәнгате, әйләнә-тирә дөнья фәннәре белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны таный белү;

– үз карашыңны дәлилләү.

**Төп төшенчәләр:** сыйфат, сыйфат дәрәҗәләре.

**Методлар һәм алымнар:** Сингапур структуралары: МЭНЕДЖ МЭТ (өстәлдәге табличкалар), ФРЕЙЕР МОДЕЛЕ, МИКС ПЭА ШЭА, РЕЛЛИ РОБИН (2 укучы арасындагы кыска җаваплар), ТАЙМД-ПЭА-ШЭА (озын җаваплар), ТИМБИЛДИНГ – 4 кешедән торган команда төзү өчен, ФО БОКС СИНЕКТЕКС РЕВЬЮ структурасы теманы төрле символлар аша аңларга ярдәм итә.

*Методлар:* өлешчә эзләнү-тикшеренү (эвристик), мөстәкыйль эш, аңлату, сөйләм, индуктив һәм дедуктив методлар.

*Алымнар:* аңлату, әңгәмә, проблемалы сорау кую, күчереп язу, күнегү, дәреслек белән эш, аңлатмалар бирү, чагыштыру, иҗади биремнәр башкару, хаталарны төзәтү.

*Укучыларның эшчәнлек төрләре:* төркемдә, парлы, шәхси, фронталь.

## Предметара бәйләнеш

Әдәбият, табигать белеме, музыка, рәсем сәнгате, әйләнә-тирә дөнья фәннәре.

## Чыганаклар

Дәреслек, такта, интерактив такта, презентация, видеоролик, перфокарталар, төрле дәрәҗәдәге сыйфатлар белән сүзләр, ФРЕЙЕР структурасы өчен А4 битләре, МИКС структурасы өчен музыка.

## Дәреснең технологик картасы

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру** | Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру. МЭНЕДЖ МЭТ *(өстәлдәге табличкалар)* | Исәнләшү. Дәрескә әзер икәнлекләрен күрсәтү | *Коммуникатив:* сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.<br>*Регулятив:* уку эшчәнлегенә үзен оештыра белү.<br>*Шәхси:* исәнләшү әдәбен белү |
| **II. Белемнәрне актуальләштерү. Уку мәсьәләсен кую** | 1.– Укучылар, барыгыз да такта янына килегезче, менә бу видеоязманы карыйк әле. Исегездә калдырыгыз: нәрсәләр бар, билгеләре нинди? *(Видеоролик күрсәтелә.)*<br>1 минут караганнан соң, туктатыла һәм рәсем өстендә, интерактив тактада, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, күренештәге билгеләр языла.<br>Әңгәмә:<br>– Ниләр күрдегез?<br>*– Балыклар, сулык...*<br>– Аларның билгеләре нинди?<br>*– Балыклар: кызыл, сары... Диңгез: тирән, чиста....*<br>– Бу сүзләргә сорау куеп карагыз әле.<br>*– Нинди?*<br>*(Укучыларга утырырга тәкъдим ителә.)*<br>– *Нинди?* соравына кайсы сүз төркеме җавап бирә? Ул нәрсәне белдерә?<br>*– Сыйфат*<br>2. ФРЕЙЕР структурасы ярдәмендә сыйфатны искә төшерү | *Көтелгән җавап: Нинди? кайсы?* сорауларына җавап бирәләр, әлеге сүзләр – сыйфатлар. Төсне, форманы, тәмне, характерны һ.б. белдерәләр<br><br>Укучылар сыйфатны искә төшерәләр, мәҗбүри һәм мәҗбүри булмаган характеристикаларны саныйлар, туры килмәгән мисалларны уйлап әйтәләр | *Танып белү:* төп билгеләрне аерып ала белү.<br>*Регулятив:* үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә һәм яза белү.<br><br>*Коммуникатив:* бер-берсенең җавабын тыңлау, сөйләшү әдәбен саклау<br>*Шәхси:* укучының башкаларны кабул итүе, аңлавы, фикерләрен җиткерә алуы.<br><br>*Коммуникатив:* мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасын күрсәтү |
| **III. Дәрескә максат кую. Дәрес темасын ачыклау** | Каршыгыздагы сүзләрне 4 төркемгә аерыгыз<br><br>– Димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди булыр? Безнең максатыбыз нинди? | Укучылар сүзләрне 4 төркемгә аералар һәм нинди билгеләренә карап бүлгәннәрен аңлаталар.<br>*1. Алсу, күксел, әчкелтем.*<br>*2. Түгәрәк, усал, тозлы, кышкы.*<br>*3. Сап-сары, иң акыллы, матурның матуры*<br>*4. Салкынрак, кыскарак, олырак*<br>Без бүген сыйфат дәрәҗәләрен кулланырга, аерырга өйрәнербез | *Регулятив:* үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **IV. Яңа белемнәрне үзләштерү** | – Дәфтәрләрдә бүгенге числоны, сыйныф эше, темaны языгыз.<br>1. Бирелгән сүзләрне 4 баганага аерып языгыз. ***1 нче слайд***<br>– Ә хәзер кагыйдәне чыгарып карыйк. 1 нче төркемгә – кимлек дәрәҗәсе, 2 нче төркемгә – артыклык дәрәҗәсе, 3 нче төркемгә чагыштыру һәм гади дәрәҗәләренә кагыйдәне чыгарып карарга. Дөреслеге тикшерелә.<br>2. Дәрәҗәләрне «балык» схемасы белән аңлату (тактада). ФО БОКС СИНЕКТЕКС РЕВЬЮ<br>– Балыклар һәм сыйфат дәрәҗәләре арасында нинди уртаклык бар?Дәрес ахырында мин бу сорауны сезгә кабатлармын. Хәзер елның кайсы фасылы? Ә балыклар кышын нишли икән? | Укучылар кагыйдәне чыгаралар<br><br>Проблемалы ситуацияне уйлау, нәтиҗәгә әзерлек. 1 укучыдан укыту<br><br>Төркемнәр китаптан дөреслеген тикшерә. (47 нче бит) Бәялиләр | *Регулятив:* үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү<br><br>*Танып белү:* төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>*Предмет нәтиҗәләре:* сыйфат дәрәҗәләрен дөрес билгеләү, аера белү.<br>*Танып белү:* уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү<br>*Комунникатив:* төрле фикерләрне кабул итү, чагыштыру, нәтиҗә ясау |
| **V. Белемнәрне ныгыту** | 1. Укытучы интерактив тактага *сарырак* сыйфатын яза. 1 укучы тактага чыга һәм дәрәҗәсен билгели, ясалышын күрсәтә.<br>*(3 – 4 укучы чыга.)*<br><br>Укытучы *яшел* сүзен яза һәм кимлек дәрәҗәсенә куярга куша – *яшькелт* – 48 нче биттәге кагыйдәне уку.<br>2. Дәреслек белән эш. 48 нче биттәге кагыйдә белән танышабыз. 100 нче күнегүне чылбырлап эшлибез.<br>3. МИКС ПЭА ШЭА. Татарча көй куела, балалар бии. Музыка туктагач, укытучы 2 санын әйтә. РЕЛЛИ РОБИН *(2 укучы арасындагы кыска җаваплар.)*<br>**Бирем:** 1 минут эчендә кимлек дәрәҗәсенең ясалуын иптәшеңә аңлат. Кем биегрәк, шул башлый. *(1 пар – интерактив тактада, кара тактада – 2 пар, калганнар, кабинет буенча таралып, аңлату эшләрендә катнашалар.)*<br>1 минут узгач, интерактив тактада эшләүчеләрдән сорарга.<br>– Ә хәзер алышындык, икенче кеше артыклык дәрәҗәсенең ясалышын аңлата. | 1 укучы тактага чыга һәм дәрәҗәсен билгели, ясалышын күрсәтә. Эш шул тәртиптә дәвам итә: тактага чыккан укучы да сыйфат яза һәм тактага 1 укучыны чакыра, ул сыйфатның дәрәҗәсен, ясалышын билгели. 4–5 укучы тактага чыга.<br>1 укучы кагыйдәне укый. Күнегү эшләнә. *(Калган укучылар дәфтәрдә эшлиләр.)*<br><br>Эш телдән башкарыла<br><br>Укучылар бии, 2 санын ишетүгә, парларда калалар. Укучылар парларда эшлиләр.<br>*(1 пар – интерактив тактада, калганнар такта янында һәм урыннарда эшлиләр.)*<br><br>Шулай ук эш парларда дәвам иттерелә | *Коммуникатив:* ишетә һәм тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру, фикерләү сәләтен үстерү<br>*Предмет нәтиҗәләре:* сыйфат дәрәҗәләрен дөрес билгеләү, аера белү.<br>*Танып белү:* үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>*Шәхси:* үз уңышларының-уңышсызлыкларының сәбәпләре турында фикер йөртү<br>*Шәхси:* алган белемнәрне куллану; уку эшчәнлегендә уңышка ирешүнең сәбәпләрен аңлау, дисциплиналы булу, игътибарлы, җаваплы булу, үз көчеңә ышану, активлык.<br>*Регулятив:* кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br><br>*Предмет нәтиҗәләре:* сыйфат дәрәҗәләрен дөрес билгеләү, аера белү.<br>*Коммуникатив:* ишетә һәм тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру, фикерләү сәләтен үстерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Музыка кабат куела. 4 саны әйтелә. Яңа төркемнәр барлыкка килә. *Тимбилдинг – 4 кешедән торган команда* | Укучылар дүртәрләп урыннарга утыралар. Урыннарда бер-берсен сәламлиләр | *Коммуникатив:*<br>– башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау, фикер алышуда катнашу;<br>– хезмәттәшлек күрсәтү;<br>– төрле фикерләрне кабул итү, чагыштыру, нәтиҗә ясау;<br>– үз фикереңне төгәл итеп әйтү |
| **VI. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү** | 1. Перфокарталар белән эш.<br>I.<br>1. *Аксыл* – к.д.<br>2. *Коңгырт* – к.д.<br>3. *Түгәрәк* – ч.д.<br>4. *Алсу* – г.д.<br>5. *Ямь-яшел* – а.д.<br>II.<br>1. *Сап-салкын* – к.д.<br>2. *Зифа* – г.д.<br>3. *Карасу* – г.д.<br>4. *Зуррак* – ч.д.<br>5. *Кып-кызыл* – г.д.<br>III.<br>1. *Чибәр* – к.д.<br>2. *Саргылт* – г.д.<br>3. *Иң биек* – а.д.<br>4. *Тәмлерәк* – к.д.<br>5. *Күгелҗем* – г.д.<br><br>***2 – 3 нче слайдлар***<br>2. Төркемнәрдә эш. ТАЙМД-ПЭА-ШЭА (озын җаваплар), «Кыш» темасына, кайсы төркем төрле дәрәҗәдәге сыйфатларны кулланып, күбрәк җөмләләр яза.<br><br>3. «Кар атышып» уйнау.<br>– Укучылар, хәзер елның нинди фасылы?<br>– Ә шулай да балыклар кышын нишлиләр микән?<br>– Ә сез кышны яратасызмы? Ни өчен?<br>– Әйдәгез, кар атышып уйныйбыз. Аның өчен микска чыгарга кирәк. МИКС ПЭА ШЭА.<br>(*Балалар бию хәрәкәтләре ясыйлар.)* | Индивидуаль (мөстәкыйль) эш. Эшләрне алышып тикшерәләр<br><br>Бәяләү критерийлары:<br>хатасыз, төзәтүсез эш – «5»ле;<br>1 – 2 хата – «4»ле;<br>3–4 хата – «3»ле;<br>5 һәм аннан артык хата –«2»ле;<br><br>Төркемнәрдә эшлиләр<br><br>– Без көчле бураннары, ямьле бәйрәмнәре булган кышны сагынып көтәбез. Кышкы уеннарны яратабыз | *Танып белү:* үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>*Регулятив:*<br>– биремнәрне үтәү, дөреслеген тикшерү;<br>– эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;<br>– үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;<br>– кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту, аларга ияреп, гамәлләр кылу;<br>– үз белем системасында ориентлаша белү;<br>– эшләнгән эшнең сыйфатын билгеләү.<br>*Предмет нәтиҗәләре:* сыйфат дәрәҗәләрен дөрес куллана белү; сүзнең эстетик вазифасын, сурәтләү көчен аңлау.<br>*Шәхси:*<br>– алган белемнәрне куллану;<br>– уку эшчәнлегендә уңышка ирешүнең сәбәпләрен аңлау, дисциплиналы булу, игътибарлы, җаваплы булу, үз көчеңә ышану, активлык.<br>***Метапредмет:***<br>*Регулятив:*<br>– үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү;<br>– үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, иптәшләреңнең җавабын бәяләү;<br>– кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту, аларга ияреп, гамәлләр кылу;<br>– үз белем системасында ориентлаша белү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *Укытучы: 6 укучыларны ике төркемгә бүләргә кирәк. Кара-каршы басалар. Бирем аңлатыла: кемгә кар йомарламы эләгә, шул укучы, сыйфат дәрәҗәләрен кулланып, кыш турында җөмлә әйтә, кар йомарламын икенче командага ыргыта, сыйфат дәрәҗәсен куллану мәҗбүри. Кайсы команда озак көттерә, шул җиңелә.* | *Укучылар ике төркемгә бүленә. Уен тәртибен тыңлыйлар. Уйныйлар. Җиңүче команда билгеләнелә* | – эшләнгән эшнең сыйфатын билгеләү.<br>*Танып белү:*<br>– уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;<br>– фикерләүдә логик чылбыр төзү;<br>– сөйләмдә өйрәнелгән материалны дөрес итеп куллана белү;<br>– телне әдәбият, рәсем, музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны таный белү;<br>– үз карашыңны дәлилләү.<br>*Коммуникатив:*<br>– башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау, фикер алышуда катнашу;<br>– сыйныфташлар белән уртак фикергә килергә кирәклеген аңлау, хезмәттәшлек күрсәтү;<br>– төрле фикерләрне кабул итү, чагыштыру, нәтиҗә ясау;<br>– үз фикереңне төгәл итеп әйтү;<br>– күмәк эш вакытында уртак фикергә килү, ярдәмләшү, киңәш бирү. |
| **VII. Рефлексия** | 1. Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау, өйрәнелгән материалны анализлау.<br>2. **«Балык» схемасы буенча нәтиҗә ясала.** Ни өчен сыйфат дәрәҗәләрен мин сезгә балык белән аңлаттым? Ни өчен без аларны сөйләмдә кулланабыз?<br>***4–6 нчы слайдлар***<br>ФО БОКС СИНТЕКС РЕВЬЮ<br>1. Үзбәя.<br>Аңладым \| Аңламадым \| Билге<br>2. ***7 нче слайд***<br>Өйгә эш (сайлап алу мөмкинлеге белән):<br>– 102 нче күнегү, 49 нчы бит;<br>– 102 нче күнегүдә бирелгән төсләр белән рәсем ясарга.<br>Һәм бер сорау калды: балыклар кышын нишлиләр?<br>*Сылтамалар бирелә:*<br>1. https://tt.wikipedia.org<br>2. Биология. В.Б. Захаров, Н.И. Сонин | *Көтелгән җавап:*<br>Балыклар сулыкларны бизәгән кебек, сыйфат дәрәҗәләре дә безнең сөйләмне матурлыйлар, төгәллек бирәләр.<br><br>Үзбәяне язалар<br><br>*(Укучылар дәрестән проблемалы сорау белән китәләр.)* | *Шәхси:* үз уңышларының (уңышсызлыкларының) сәбәпләре турында фикер йөртү<br>*Регулятив:*<br>– үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү;<br>– үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, иптәшләренең җавабын бәяләү;<br>– кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту, аларга ияреп, гамәлләр кылу;<br>– үз белем системасында ориентлаша белү, үзбәя;<br>– эшләнгән эшнең сыйфатын билгеләү. |

13




# БОЕРЫК ФИГЫЛЬ

## *(Татар мәктәпләренең VI сыйныфында татар теле дәресе)*



**Гөлфия ХӘЙРЕТДИНОВА,**

Казандагы 16 нчы татар-инглиз гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**

– укучыларның фигыль турындагы белемнәрен ныгыту, системага салу, фикер йөртү сәләтен үстерү;

– боерык фигыль турында гомуми төшенчә бирү; боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, мәгънә төсмерләре, боерык фигыльне куллану үзенчәлеген төшендерү;

– мөстәкыйльлек тәрбияләү, укучыларда яхшылык эшләү, шәфкатьле булу, бер-береңә ярдәмләшү башка шундый сыйфатларны булдыру.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

***предмет нәтиҗәләре:*** боерык фигыльне тану, язу, сөйләмдә урынын билгеләү һәм куллану;

***регулятив УУГ:*** үз эшеңнең максатын билгеләү, үз эшеңне бәяләү, кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп эшләү;

***танып белү УУГ:*** куелган проблеманы ача белү, фикерләүдә логик чылбыр төзү;

***коммуникатив УУГ:*** үз фикереңне формалаштыра һәм исбатлый белү

***шәхескә кагылышлы УУГ:*** яхшылык эшләү, шәфкатьле булу, бер-береңә ярдәмләшү башка шундый сыйфатларны булдыру.

**Дәрес тибы:** яңа материал аңалату.

**Укыту методлары:** аңлату, әңгәмә, демонстрация, модельләштерү.

**Дәрес формасы:** төркемнәрдә эш.

**Җиһазлау:** мультимедиа презентация, яхшылык турында видео, тест.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру моменты**

**1. Уңай психологик халәт тудыру.**

– Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек? Бер-беребезгә елмаю бүләк итик. Дәресебезне башлыйбыз. Бүген без сезнең белән фигыль турында алган белемнәребезне ныгытып тирәнәйтербез. Әгәр дә дәрес ахырына куйган максатыбызга ирешсәк, димәк, без бик нәтиҗәле эшләгәнбез була.

**II. Актуальләштерү**

– Без алдагы дәресләрдә алган белемнәребезне кабатлап үтик әле.

Фигыльләрне кабатлау.

**1 нче бирем. Төркемнәрдә, постер белән эш.** *(1 мин +1 мин)*

Өч төрле фламастер алына. Һәр төркем үз төсе белән сорауларга җавапларын яза. Постерлар һәр төркемдә дә йөреп чыга. Җаваплар тикшерелә.

*Слайд*

| № | Раслау | әйе | юк |
|---|---|---|---|
| 1 | Фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз дигән төркемнәргә бүленәләр | | |
| 2 | Барлык фигыльләр өчен дә барлык-юклык категориясе хас | | |
| 3 | Фигыльләрнең 3 заманы бар | | |
| 4 | Барлык фигыль төркемчәләре дә заман белән төрләнә | | |
| 5 | Фигыль төркемчәләре җидәү | | |
| 6 | Фигыль юнәлешләре бишәү | | |
| 7 | Фигыльләрне барлык юнәлеш формаларына да куеп була | | |
| 8 | Затланышлы фигыльләр өчәү | | |
| 9 | Затланышсыз фигыльләр дүртәү | | |
| 10 | Җөмләдә фигыль һәрвакыт хәбәр булып килә | | |

**2 нче бирем.** *(3 мин)*

*Слайд*

Кайсы төркемчәдән булуына карап, фигыльләрне дөрес итеп перфокартага урнаштырыгыз.

1) эшли, 2) укы, 3) килсә (күрә), 4) белгән (кеше), 5) таныгач (күрешә), 6) язу, 7) укырга, 8) сөйләде, 9) тукта, 10) эзләсә (таба), 11) укучы (бала), 12) уйлап (яз), 13) бару, 14) елмаерга.

| Фигыль төркемчәләре | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хикәя | о | | | | | | | *о* | | | | | | |
| Боерык | | *о* | | | | | | | *о* | | | | | |
| Шарт | | | *о* | | | | | | | *о* | | | | |
| Сыйфат фигыль | | | | *о* | | | | | | | *о* | | | |
| Хәл фигыль | | | | | *о* | | | | | | | *о* | | |
| Исем фигыль | | | | | | *о* | | | | | | | *о* | |
| Инфинитив | | | | | | | *о* | | | | | | | *о* |

**III Яңа теманы аңлату**

1. Яхшылык эшләү турында видео фильм карау

**Укытучы.** Ничек уйлыйсыз бу тортны егет ни өчен бирде? Бу видео нәрсә турында? *(Яхшылык эшләү турында.)* Соңгы арада нинди яхшылык эшләдегез?

Слайдта *Яхшылык **эшлә** дә суга **сал мәкале күрсәтелә.***

**Укытучы.** Бу әйтемне ничек аңлыйсыз? Без караган видеога таянып аңлатыгыз. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләр нинди сорауга җавап бирә? *(Нишлә?)* Бирелгән фигыльләр эшне нинди мәгънә төсмере белән белдерә? *(Киңәш итү, боеру, эш кушу.)* Димәк, без бүген нинди уку максаты өстендә эшлибез? *(Боерык фигыль турында сөйләшәчәкбез.)*

*Слайд*

**3 нче бирем.** Шигырьдән боерык фигыльләрне табу, грамматик категорияләрен аңлату. *(Телдән башкарыла.)*

**Укытучы.** Бу шигырь нәрсә эшләргә өнди? Ни өчен кешеләргә яхшылык, игелек эшәү мөһим?

**1 нче төркем**

**Кыл** яхшылык кешеләргә –

Кеше булыйм дисәң.

Авыр булыр, өсләреңә

Гөнаһ туны кисәң.

**Аера бел** ак-караны,

Начар юлда **йөрмә.**

Яхшы белән явызлыкны

Берүк **бутый күрмә.**

**2 нче төркем**

**Шатландыр** син, ярдәм кылып,

Ялгыз әбиләрне,

«Үскәнем» дип, «матурым» дип

**Юат** нәниләрне.

Кеше булып яшим дисәң,

**Бул** син кешелекле.

Бәхетле көн итим дисәң,

**Бул** син игелекле

**Укытучы.** Кара хәрефләр белән язылган сүзләр нинди фигыльләр? *(Кыл, бел, йөрмә, бутый күрмә, шатландыр, юат, бул – боерык фигыльләр.)*

– Алар нинди мәгънә белдерә?

*Йөрмә* нинди формада килгән? *(Юклыкта)*

*Шатландыр* нинди юнәлештә клгән? *(Йөкләтү)*

Нәтиҗә чыгару. Боерык фигыль эш кушуны, боеруны белдерә, зат-сан, юнәлеш белән төрләнә, барлыкта яки юклыкта килә. Төрле мәгънә төсмерләре белдерә.

*Слайд*

Зат-сан белән төрләнешен карагыз

| | Берлектә | Күплектә |
|---|---|---|
| **II зат** | бар, кил | барыгыз, килегез |
| **III зат** | бар+сын, кил+сен | бар+сыннар, кил+сеннәр |

Боерык фигыльнең зат-сан кушымчалары

| | Берлектә | Күплектә |
|---|---|---|
| **II зат** | - | -(ы)гыз // -(е)гез |
| **III зат** | -сын// -сен | сыннар// -сеннәр |

**5 нче бирем. Төркемнәрдә эш. Бирелгән схема буенча модельләштерү**

*Слайд*

1 нче төркем II зат боерык фигыль моделен төзи. 1 укучы аңлата.

*(II зат күплек саны -гыз / -гез, -ыгыз / -егез кушымчасы ала: яз-ыгыз, кил-егез, укы-гыз, сөйлә-гез. II зат күплек сандагы боерык фигыль олылап, хөрмәтләп мөрәҗәгать иткәндә дә кулланыла: узы-гыз, апа, утырыгыз!)*

2 нче төркем III зат боерык фигыль моделен төзи. 1 укучы аңлата. *(Боеруның III затка караганын белдерә, ул берлектә -сын / -сен, күплектә -сыннар / -сеннәр кушымчасы ала: кил-сен, кил-сеннәр, укы-сын, укы-сыннар, утыр-сын, утыр-сыннар.)*

**Нәтиҗә ясау.**

Боерык фигыльләр II, III затларда кулланыла, көчле боеру интонациясе белән һәм көчле басым белән әйтелә.

Кагыйдә. Боерык фигыльдә басым

– II затта – беренче иҗеккә: укы,туктагыз, ишет, барыгыз әле.

– III затта – соңгы иҗеккә: уйнасын, алсыннар.

– Юклык формасында *-ма/-мә* кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә: *белмә, әйтмәгез, сизмәсен*.

**6 нчы бирем. Төркемнәрдә эш. Кластер төзү.**

**Укытучы.** Безгә кластер төзергә кирәк. *Кластер* сүзе бәйләм, тәлгәш дигәнне аңлата. Төркемнәрдә кояш рәсеме, ләкин аның нурлары юк. Кешеләр күңелен җылыту өчен, аңа яхшы эшләргә өндәүләр язып, нурлар өстәргә кирәк. Җөмләләрдә боерык фигыль формаларын кулланырга тиеш булабыз. Аннан соң тактага зур кояшның нурларын куярбыз.

*(Бер укучы үз төркеменең фикерен аңлата.)*

**7 нче Бирем.** Боерык фигыльгә морфологик анализ ясарга. Бер җөмләдә боерык фигыльне үрнәктәгечә тикшерегез.

*Туган телеңне, милләтеңне сакла!*

*Сакла – боерык фигыль, затланышлы, төп юнәлештә, барлыкта, II зат берлек санда, җөмләдә хәбәр булып килгән, ясалма сүз.*

**IV. Белемнәрне тигезләүгә тест**

1. Боерык фигыль

а) затланышлы        ә) затланышсыз

2. Җөмләдән фигыльне табыгыз. Ул нинди фигыль?

*Һич күләгә төшермә син җаныңдагы*

*Туган илең, Туган җирең яктысына.*

а) хәл фигыль ә) хикәя фигыль б) боерык фигыль

3. Боерык фигыль

а) заман белән төрләнә

ә) заман белән төрләнми.

4. *Ә син курыкма, батыр бул!* Бу җөмләдә боерык фигыль нинди мәгънә төсмере белдерә?

а) эш кушу, боеруны ә) киңәш бирүне б) үтенүне

5. Бирелгән сүзләрдә басым кайсы иҗеккә төшә: *уйнасын, алсыннар*

а) соңгы иҗеккә        ә) беренче иҗеккә

Экрандагы дөрес җавапларны күзәтеп, укучылар бер-берсенең җавапларын тикшереп билге куя.

Дөрес җаваплар.

1. а     2. б     3. ә     4. ә     5. а

Тестларны алмашып тикшерү, бәяләү.

**V. Рефлексия, бәяләү**

1. – Бүген дәрестә нинди темага сөйләштек? *(Яхшылык, игелек эшләү турында.)* Тагын кайсы фигыль төркемчәсе белән таныштык? Нинди уку максаты өстендә эшләдек? Ә командада ничек эшләдек? Нинди нәтиҗәгә килдек?

**Үзбәя кую.** Тактада – агач рәсеме. Кем барын да аңладым, белдем, иптәшемә аңлата алам ди, исемен язып, кызыл алмалар ябыштыра; кем эле аңлап җиткермәгән, яшел алмалар ябыштыра.

**2. Өй эше.**

1. *Уйла, сөйлә* фигыльләрен зат-сан белән төрләндерегез.

2. Әдәбият дәреслегеннән боерык фигыль кергән 5 җөмлә язып алыгыз.

3. «Яхшылык нәрсә ул?» дигән темага кыска гына инша яз.

14



# СИНОНИМ ҺӘМ АНТОНИМ СҮЗЛӘР. *МИНИАТЮР СОЧИНЕНИЕ*



**Гөлүсә ҖӘЛӘЛИЕВА,**

Арча районы Сеҗе төп мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы



**Равилә НӘГЫЙМОВА,**

Арча районының Г.Камал исемендәге Сикертән төп мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** синоним һәм антоним төшенчәсен актуальләштерү, доминанта сүзнең вазифасын искә төшерү, даими антонимнарны контекстуаль антонимнардан аера белү, синоним һәм антонимнарның сөйләмдәге әһәмиятен билгеләү күнекмәсен камилләштерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Предмет буенча:** синоним һәм антоним сүзләр төшенчәсен актуальләштерү.

**Шәхескә кагылышлы:** Туган як табигате белән кызыксыну уяту, сөйләмне камилләштерүгә омтылу.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*танып белү УУГ:* кирәкле информацияне эзләп табу, уй-фикерне язма һәм әйтмә формада аңлап һәм ирекле оештыру;

*коммуникатив УУГ:* аралашу максатына һәм шартларына туры китереп, үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;

*регулятив УУГ:* кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу.

**Җиһазлау:** презентация, карточкалар.

### Дәрес барышы

**I. Мотивлаштыру-ориентлашу**

1. А) Уңай психологик халәт тудыру;

– Укучылар, һәммәгезгә дә яхшы кәеф телим, ә яхшы кәеф барыбызның да күңелен күтәрсен. Сезгә дәрестә уңышлар китерсен. ***(1 – 2 нче слайд)***

Ә) Белемнәрне актуальләштерү. Факультативка яки ватсапка җибәрелгән эшләрне анализлау, типик хаталарны төзәтү.

Узган дәрестә өйрәнгән материалны искә төшерү өчен сорауларга җаваплар табу.

– Әйдәгез әле, бераз кагыйдәләрне дә искә төшереп алыйк. ***(3 нче слайд)***

- Лексикология бүлеге нәрсәне өйрәнә?
- Грек теленнән лексикология сүзе ничек тәрҗемә ителә?
- Һәрбер сүз нинди дә мәгънә белдерә?

**Үзбәя.**

2. Уку мәсьәләсе кую ситуациясе.

Дәфтәрләргә бүгенге числоны язабыз. Мәкальләрне укып, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә игътибар итәргә, мәгънәләрен аңлатырга. ***(4 нче слайд)***

1) ***Олыларны*** *хөрмәт ит,* ***кечеләргә*** *шәфкать ит.*

2) *Көзге көн бала кебек: әле* ***елый****, әле* ***көлә****.*


3) ***Ак*** *булмаса да,* ***пакь*** *булсын.*

4) ***Акыл*** *азмый,* ***белем*** *тузмый.*


| Биремнәр, сораулар | Көтелгән җаваплар |
|---|---|
| – 1 һәм 2 нче мәкальдә бирелгән сүзләр мәгънәләре ягыннан нинди сүзләр? | – Капма-каршы мәгънәле |
| – Димәк, алар нинди сүзләр? | – Антонимнар |
| – 3 һәм 4 нче мәкальдә бирелгән сүзләр мәгънәләре ягыннан нинди сүзләр? | – Охшаш мәгънәле ягъни мәгънәләре белән бер-берсенә бик якын торган сүзләр |
| – Димәк, алар нинди сүзләр? | – Синонимнар |
| – Димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди була? | Антоним һәм синоним сүзләр |
| Укытучы гомумиләштерә | |

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

1. Яңа материалны ныграк күзаллау өчен, теоретик материал белән танышырга. ***(5 нче слайд)***




***(6 нчы слайд)***




2. Беренче ныгыту. Мәкаль өстендә эш. ***(7 нче слайд)***

1) Ялкау кеше – ярты кеше, уңган кеше – алтын кеше.

2) Тәртипле, әдәпле булсаң гына сине яраталар.

*Ялкау – уңган* – антонимнар. *Тәртипле, әдәпле* – синонимнар.

Белемнәрне бәяләү.

3. Икенче ныгыту. Синонимнар өстендә эш. ***(8 нче слайд)***

– Әйдәгез, укучылар, бу биремне һәр укучы мөстәкыйль эшли. Сезгә сүзләр бирелгән, аларны синонимнары белән парлап язарга.

*Сүзләр: шатлык, яхшы, матур, йөз, бәя, салкын, кечкенә, ялгыш, чибәр, куаныч, хак, әйбәт, суык, бит, хата, бәләкәй, нечкә, олы, сандугач, сылу, ашамлык, ант, ансат, колын, нәзек, дәү, былбыл, зифа, ризык, вәгъдә, җиңел, тай.*

– Эшегезне тәмамлаган булсагыз, әйдәгез, тикшерик. *(Укучылар чиратлашып җавап бирәләр.)*

– Яхшы, ни өчен сез сүзләрнең шушы парын сайладыгыз? *(Болар – охшаш мәгънәле сүзләр, ягъни синонимнар.)*

4. Мөстәкыйль эш.

– Ягез, балалар, яшәү, үлү сүзләренә якын мәгънәле сүзләр уйлап карыйк.

*(2 – 3 минут мөстәкыйль эшлиләр, аннары нәтиҗә ясала.)*

*Яшәү* – тору, гомер итү, гомер сөрү, гомер кичерү, тереклек итү, көн итү, тереклек кылу, көн күрү, көн кичерү, көн үткәрү, дөнья көтү, дөнья куу, дөнья кичерү.

*Үлү* – бетү, китү, сүнү, кату, дөмегү, тончыгу, каплану, өзелү, вафат булу, һәлак булу, гүргә керү, дөньядан китү (үтү, күчү, югалу), дөнья кую, арадан (бездән) китү, теге дөньяга китү, ахирәткә күчү, күз йому, җан бирү.

– Без мәгънәләре буенча бер-берсенә якын сүзләр төркемен яздык. Бу төркем синонимик оя яки синонимик рәт дип атала.

– Бу сүзләр арасында кайсы сүзне еш кулланабыз? *(Яшәү, улү)*

– Иң еш кулланыла торган сүз доминанта сүз дип атала.

5. Текст өстендә эш. ***(10 нчы слайд)***

Һәр җир карланган,

Сулар бозланган,

Уйный җил-буран,

Бу кайчак, туган? *(Г.Тукай)*

Тирә-якта көмеш төстә,

Нинди матур табигать!

Агачларга бәсләр кунган,

Искиткеч бу әкият! *(Л.Гиматдинова)*

– Димәк, синонимнардан парлы сүзләр дә ясалырга мөмкин. Мәсәлән, *әйләнә-тирә, җил-давыл, кар-буран, кимхур, хатын-кыз, ару-талу, әүвәл-баштан, дус-иш, гореф-гадәт, кадер-хөрмәт, рәхим-шәфкать, ордым-бәрдем, көчкуәт, очсыз-кырыйсыз, ипле-җайлы, исәпсез-хисапсыз, тормыш-көнкүреш, елмаю-көлү, орден-медаль.* ***(11 нче слайд)***

Өстәмә мәгълүмат: рус, инглиз, швед, француз, казах, башкорт, үзбәк телләренең синонимнар байлыгы тупланып, сүзлекләр чыгарылган. Аларда бер мәгънәне аңлаткан сүзләр төркеме – синонимик рәтләр яки оялар бирелгән. ***(12 нче слайд)***

Моны белү кызыклы:

инглиз телендә – 4500

швед телендә – 1380

немец телендә – 25000

казах телендә – 1448

рус телендә – 8000

татар телендә 6000нән артык оя теркәлгән.

6. – Антонимнарны даими антонимнарга һәм контекстуаль антонимнарга бүлеп йөртәләр. Даими антонимнар контексттан тыш та антоним буларак кабул ителәләр, аларның капма-каршы мәгънәле сүзләр икәнен бу телдә сөйләшүче һәр кеше җиңел тоя. Контекстуаль антонимнар билгеле бер ситуациядә, контекстта гына антоним булып киләләр, аерым кулланганда, антонимик мөнәсәбәтләр юкка чыга:

***Ак*** *йөзләрем* ***сары*** *булды,*

*Гел сине уйлап кына. (Җыр)*

***Көчлелегең*** *белән горурланма,*

***Кешелегең*** *белән горурлан! (М. Җәлил)* ***(13 нче слайд)***

7. Бирем. Югарыда бирелгән белешмәгә таянып, даими һәм контекстуаль антонимнарны билгеләгез. ***(14 нче слайд)***

1. Югарыга карап үрнәк ал,

Түбәнгә карап гыйбрәт ал. *(Мәкаль)*

2. Безнең халык ачы булса булды,

Дошманына төче булмады. *(М.Әгъләмов)*

3. Тик ни файда, көчең филдәй булып,

Эшең булса чыпчык тезеннән. *(М.Җәлил)*

4. Кош – канат белән, кеше – дуслык белән. *(Мәкаль)*

5. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде. *(Г.Кутуй)*

*Көтелгән җавап:* югарыга – түбәнгә (даими), үрнәк – гыйбрәт (конт.), ачы – төче (даими), филдәй – чыпчык тезеннән (конт.), канат белән – дуслык белән (конт.), энҗе чәчәкләре – әреме (конт.).

**V. Рефлексия. Бәяләү**

1. Бүгенге дәрестә нәрсә белдегез?
2. Нәрсә белергә теләр идегез?
3. Нинди кыенлыкларга очрадык?
4. Дәрескә гомуми бәя кую.

**VI. Өй эше *(15 нче слайд)***

1. Синоним, антоним сүзләр кулланып, «Туган ягым табигате» темасына миниатюр инша язарга.
2. Синоним, антоним сүзләр кергән мәкальләр табып язарга.
3. Кагыйдәләрне өйрәнергә.



15

# «КЕШЕНЕҢ ГОМЕРЕ БЕР ГЕНӘ, ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘРГӘ АШЫГЫЙК!»

*(VII – IX сыйныфларда бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе)*



**Чулпан МАТКУЛОВА,**

Казандагы 57 нче рус-татар урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле укытучысы

**Максат:** «яхшылык» төшенчәсенең мәгънәсен аңлату; балаларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү, нәтиҗә ясарга өйрәтү, иҗади фикерләүне тирәнәйтү; укучыларда әхлак сыйфатларын (яхшылык, кешелеклелек, шәфкатьлелек) тәрбияләү.

**Җиһазлау:** мәкальләр язылган плакат, кояш рәсеме, анкета, слайдлар

### Дәрес барышы

**Укытучы.** Хәерле көн! Исәнмесез! Бу сүзләрне әйткәндә, без чын күңелебездән яхшылык, шатлык, сәламәтлек, тынычлык телибез!

Ф.Яруллинның шигъри юллары дәресебезнең шигаре булыр:

*Ходайның һәр бирмеш көнендә*

*Бер матур як белән ачылыйк.*

*Кешенең гомере бер генә,*

*Яхшылык эшләргә ашыгыйк!*

**Укытучы.** Укучылар, бүгенге сөйләшүебез нәрсә турында булачак? Ни өчен Ф.Яруллинның шушы шигырь юлларын китердем? Нинди максатлар куярбыз?

**Укытучы.** *Яхшылык* сүзе нинди тамырдан ясалган? *(Яхшы.)*

Сүзнең тамыры нинди сүз төркеме? *(Сыйфат.)*

*Яхшы* сүзенең мәгънәсен әйтегез. Кластерны тулыландырыгыз. Яхшы кеше нинди була? Дәфтәрләргә язабыз.

**Укучылар.** Яхшы кеше, юмарт, намуслы, игелекле, изгелекле, миһербанлы, саф йөрәкле, ихлас эчкерсез, яхшы күңелле, акыл белән эш итә.

Сүзлек өстендә эш. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең 3 томында (1981 ел) *яхшы* сүзенең 9 мәгънәсе бирелә. Кешегә карата китерелгән мәгънәләренә тукталабыз.

*Яхшы.* 1. уңай сыйфатлары, уңай яклары булган;

2. уңышлы, файдалы;

3. намуслы, мәрхәмәтле, кешелекле, тәрбияле;

4. якын мөнәсәбәт, белешлек-танышлык турында «дус» мәгънәсендә;

5. абруйлы, яманаты чыкмаган.

**Укытучы.** *Яхшы* сүзенә *-лык* кушымчасы кушкач, нинди сүз барлыкка килә? *(Ясалма сүз.)*

*Яхшылык* сүзе нинди сүз төркеменә карый? *(Исем.)*

Нәрсә ул яхшылык? *(Яхшы кешегә хас сыйфатлар.)*

*Яхшылык* сүзенең синонимнарын әйтегез һәм дәфтәрләрегезгә языгыз.

**Укучылар.** Мәрхәмәтлелек. Ярдәмчеллек. Кешелеклелек. Шәфкатьлелек. Ихтирамлылык. Игелеклелек. *(Тикшерәбез.)*

Яхшылык турында цитаталар, хәдисләр, гыйбрәтле хикәяләр, канатлы сүзләр, мәкальләр бик күп. Өй эшенә яхшылык турында төрле халыкларның мәкальләрен карап килергә кушкан идем. Тактаның бер канатында – мәкальнең башы, ә икенчесендә ахыры

китерелә. Кушып укыгыз. Төркемнәрдә эшлибез. Кайсы төркем тизрәк башкара, тикшерик.

**Укучылар.** Яхшылык эшлә дә, суга сал. *(Татар халык мәкале.)*

Атаңа ничек булсаң, балаңнан шуны көтәрсең. *(Татар халык мәкале)*

Алтын янында бакыр да сарылана, яхшы кеше янында начар кеше дә яхшыра. *(Монгол халык мәкале)*

Песине өч ел ашатсаң, яхшылыгыңны онытмас. *(Япон халык мәкале)*

Яхшылык эшләү беркайчан да соң түгел. *(Француз халык мәкале)*

Яхшылыкны киңәшмичә эшлиләр. *(Гарәп халык мәкале)*

Яхшылык эшлә һәм кем өчен икәнен сорама. *(Колумбия халык мәкале)*

**Укытучы.** Мәкальләрдән нинди фикергә киләбез? Төркемнәрдә киңәшеп фикер алышабыз. Кайсы төркем әйтә? Кайсыгыз тулыландыра?

**Укучылар.** Сез үзегез нинди яхшылыклар эшлисез, изгелекләр кыласыз? Парлап эшлибез. Чыннан да шулаймы икән? Әйдәгез, тикшереп алабыз.

Анкета «Сез яхшы кешеме?»

1. Сезнең артык акчагыз бар. Сез барлык акчагызны да дусларыгызга бүләккә тотар идегезме?
2. Иптәшегез сезгә үзенең авырлыклары турында сөйли. Хәленең авыр икәнен белсәгез дә, бу сезне кызыксындырмавы турында әйтәсез?
3. Дустыгыз шахмат яки башка уенны начар уйный. Сез аны шатландырыр өчен җиңелерсезме?
4. Сез кешеләрнең кәефен күтәрү өчен җылы сүзләрне еш әйтәсезме?
5. Сез усал шаяртуларны яратасызмы?
6. Сез ачу саклаучан кешеме?
7. Сезне кызыксындырмаган мәсьәләләрне дә сабырлык белән тыңлый алырсызмы икән?
8. Үзегезнең мөмкинлекләрегезне практикагызда куллана аласызмы?
9. Җиңелә башлагач, сез уенны ташлап китәсезме?
10. Әгәр сез үз хокукларыгызның дөреслегенә ышанасыз икән, башка кешеләрнең фикерләрен тыңлаудан баш тартасызмы?
11. Сез кешеләрнең теләк-үтенечен теләп башкарасызмы?
12. Тирә-юньдәгеләрнең күңелләрен күтәрү өчен шаярта аласызмы?

**Укытучы.** Хәзер нәтиҗәләрне карыйк.

Әгәр 1, 3, 4, 7, 11 сорауларында «әйе» дисәгез, берәр балл. Әгәр 2, 5, 6, 8, 9, 10, 12 сорауларында «юк» диелсә, шулай ук берә балл. Барлык балларны кушыгыз.

Әгәр сезнең баллар саны 8 дән артык булса, сез счык йөзле, ачык күңелле. Тирә-юньдәгеләргә ошыйсыз, кешеләр белән аралаша беләсез. Сезнең дусларыгыз күп. Ләкин сак булыгыз: барлык кешеләр белән дә яхшы мөнәсәбәтләргә кермәгез.

Әгәр сезнең баллар саны 4 тән 8 гә кадәр булса, сездәге яхшылык очраклы гына. Барлык кеше белән дә яхшы мөнәсәбәттә түгелсез. Кемдер өчен бик яхшы була аласыз, ә кемдер өчен – юк. Бик начар түгел-түгелен. Әмма сезгә барлык кешеләргә дә тигез мөнәсәбәттә булу өчен тырышырга кирәк.

Әгәр сезнең баллар саны 4 тән ким булса, хәтта якыннарыгызга да сезнең белән аралашу авыр. Әгәр яхшы булсагыз, сезнең дусларыгыз да күп булыр. Белегез: дуслык яхшы мөнәсәбәтләрдә генә була ала.

Бу анкетадан үзегез турында нәтиҗәләр чыгаргансыздыр дип уйлыйм.

**Укытучы.** Әлбәттә, кеше үзе генә яшәми. Аның янәшәсендә һәрвакыт кешеләр. Адәм баласына хаталар да җибәрергә туры килә. Ул шулай дөньяны аңларга, нинди кешеләр барлыгын аерырырга өйрәнә: яхшы – усал; шәфкатьле – шәфкатьсез; гафу итә белүче – гафу итә белмәүче; ярдәмгә кулын сузучы – ярдәм итмәүче һ.б. Ни өчен кешеләр икегә бүленәләр соң? Менә шушы сорауга Һиндстан халкының бер гыйбрәтле хикәясендә әлеге тема яктыртыла. Тыңлап үтик.

Көннәрдән бер көнне зирәк һиндлы кабилә башлыгына кечкенә оныгы сорау бирә:

– Ни өчен начар кешеләр була?

– Начар кешеләр юк, улым! Һәр кешенең җаны икегә бүленгән: яктыга һәм караңгыга. Җаныбызның якты ягы кешене мәхәббәткә, яхшылыкка, ярдәмчеллеккә, тынычлыкка, сабырлыкка, өметкә, эчкерсезлеккә чакыра. Ә караңгы як саранлыкка, хыянәткә, усаллыкка, эгоизмга, көнчелеккә, ялганчылыкка өнди. Ике бүренең көрәшүе кебек. Күз алдыңа китер: бер бүре ак, ә икенчесе кара. Аңлыйсыңмы?

**Укытучы.** Авторның идеясе нәрсәдә? Ул нәрсә әйтергә тели? Яхшылык темасы бөтен халыкта да актуаль. Әлеге тема Коръәни Кәримнең 17 нче «Бәни Исраил» сурәсенең 7 нче аятендә әйтелә: «Әгәр яхшылыклар кылсагыз, үзегез өчен яхшылык кылган буласыз, вә әгәр явызлыклар кылсагыз, янә үзегез өчен явызлык кылган буласыз». Укучылар, иҗади эш башкарабыз. Яхшылык темасын чагылдырып, алда тикшерелгән, анализланган фикерләрне дә туплап, мини-сочинение языгыз.

*Берничә укучының иҗади эше тыңланыла.*

**Укытучы.** Һәр кешенең яхшылыкка үз юлы салынган. Ул тумыштан да, нәселдән-нәселгә дә бирелми. Көн саен яхшылык эшләргә, изгелекләр кылырга, кешеләрнең яхшы булуларын күрә белергә, ә иң яхшысы үзеңне шул кеше урынына куярга кирәк. Бар кеше изгелек кылса, яктырыр иде дөнья. Дөнья яктырсын өчен, нәрсәләр эшлик, укучылар? *(Кояшның нурларына языла, тактага эленә.)*

– кешеләргә булышырга;

– көчсез кешеләрне якларга;

– дустың белән бүлешергә;

– көнләшмәскә;

– кешеләрнең хаталарын гафу итәргә;

– кешеләргә игътибарлы, шәфкатьле булырга;

– табигатькә, хайваннарга карата мәрхәмәтле булырга;

– һәр көн изге эшләр башкарырга;

– кылган эшләрең белән мактанып йөрмәскә;

– мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга;

– кешелекле булырга.

*(Кояш нурлар белән тулыландырыла.)*

Кояшның нурлары сүнмәсен, җылытып торсын дигән теләктә каласы килә. *(Кояштагы теләкләрне өләшәм.)*

Барысы да сезнең кулда!

«Кешенең гомере бер генә,

Яхшылык эшләргә ашыгыйк!»

Ходайның һәр бирмеш көнендә

Бер матур як белән ачылыйк.

Кешенең гомере бер генә,

Яхшылык эшләргә ашыгыйк!»

16



# СҮЗ УЛ – КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ

*(IX сыйныфта татар теле дәресендә «Сөйләм культурасына куелган таләпләр»не үткәч уздырылган мастер-класс)*



**Зөләйха ХАФИЗОВА,**

Казан шәһәре 11 нче татар гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес барышы**

**Укытучы.** Хәерле көн. Исәнмесез. Барыгызга да яхшы кәеф, иҗат итү, эзләнү шатлыгы, яңа табышлар телим. «Сөйләм культурасы» буенча алган белемнәрне гамәлдә кулланырбыз. Төркемнәргә бүленеп эшләрбез. Укучылар, бүгенге дәреснең максатларын әйтик әле.

Максатларыбыз:

– сөйләм культурасына куелган таләпләрне белүне ныгыту;

– матур, әдәпле итеп сөйләшә, аралаша белү күнекмәләрен үстерү;

– яхшы сүзнең тәрбия бирүдә тоткан урынын күрсәтү;

– үз сөйләмеңә таләпчән булу;

– аралашу, аңлашу, бер-береңә игътибарлы булу кебек сыйфатлар тәрбияләү.

**Укытучы.** Укучылар, хәзер мин сезгә «Диңгез бакасы һәм елан» хакында әкият сөйлим. Сез әкиятне тыңлагыз һәм сорауга җавап әзерләгез. Ни өчен бер үк ләйсән яңгыры бака авызында – энҗегә, елан авызында агуга әйләнә? *(Укучылар төркемнәрдә киңәшәләр, үз вариантларын әйтәләр.)*

– Чөнки баканың күңеле изгелектә.

– Ул кешеләргә яхшылык тели.

– Еланның күңеле явыз, нияте начарлыкта.

**Укытучы.** Сез аларның уй-ниятләрен каян белдегез?

– Әйткән сүзләреннән.

**Укытучы.** Нәтиҗә чыгарыгыз.

– Сөйләгән сүзгә карап, кешенең күңеле нинди икәнен белеп була.

– Рәхмәт, укучылар. Бүген без нәкъ шушы темага сөйләшербез, фикерләшербез. Дәресебезнең темасын әйтә аласызмы?

– «Сүз ул – күңел көзгесе» дип атала.

**Укытучы.** Әйтегезче, сөйләм культурасы дигән төшенчәне ничек аңлыйсыз?

– Ул – гомуми культураның бер өлеше һ.б.

**Укытучы.** Үзеңдә ничек итеп сөйләм культурасын тәрбияләргә була?

– Үз өстеңдә эшләп.

– Үз сөйләмеңә игътибарлы, таләпчән булып.

– Әдәби китаплар укып.

**Укытучы.** Сөйләм әдәбенә ирешү өчен, аңа куелган таләпләрне белергә кирәк. Сез беләсезме? *(Төркемнәрдә фикерләшәләр.)*

– Сөйләм төгәл булсын.

– Аңлаешлы һәм әйтергә теләгән фикер ачык булсын.

– Саф булсын.

– Җыйнак булсын.

– Аһәңле булсын.

**Укытучы.** Нәтиҗә ясагыз. Димәк, сөйләм культурасына ия булу өчен, биш төрле таләпне үтәргә кирәк. Моңа нинди юллар белән, ничек ирешергә икәнлеген бу дәрестә ачыкларга тиеш булабыз. Бу стендта – кыр чәчәкләренең сабагы. *(Тактага кыр чәчәге макеты эленә.)* Сөйләмгә куелган һәр таләпне төрле яссылыкта ача барырбыз. Кайсы таләпне дөрес ачып, аңлап калдыгыз, шуңа чәчкә беркетә барыгыз.

**Укытучы.** Сөйләм төгәл булсын өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш?

– Әдәби тел нормаларын яхшы үзләштерергә кирәк.

– Сүзләрне дөрес кулланырга.

– Кабатлануларны булдырмаска.

– Һәр сүзнең җөмләдәге урынын дөрес билгеләргә.

**Укытучы.** Телнең байлыгы, сөйләм осталыгы кайларда чагыла?

– Халык авыз иҗаты үрнәкләрендә: мәкаль-әйтемнәрдә, фразеологизмнарда, канатлы гыйбарәләрдә, табышмакларда.

**Укытучы.** Мисаллар китерегез әле.

– *Сүздән аркан ишү* – фразеология.

Укытучы. Мәгънәсен аңлатыгыз.

– Бер нәрсә хакында күп сүз куерту, күп сөйләү. Димәк, мондый кешедә сөйләм төгәллеге юк дип аңлыйм.

**Укытучы.** Ә сөйләме төгәл кешегә карата ни диләр?

– Сүзенең уставы килгән, диләр. Мәгънәсе – сөйләме устав кебек конкрет һәм төгәл.

**Укытучы.** Сөйләм төгәллеген нинди чәчкәгә охшатасыз? Сабагына беркетегез.

2) Сөйләм аңлаешлы булсын өчен ниләр эшләргә кирәк?

– Җөмлә төзек булырга тиеш, мәгънә буталуга юл калмаска тиеш.

– Бәйләүче чаралар кабатланмаска тиеш.

– Җөмлә туган тел үзенчәлеген искә алып төзелергә тиеш.

**Укытучы.** Экранда җөмлә бирелгән: *Мин китап артыннан кибеткә бардым.* Хатаны табыгыз, төзәтегез.

**Төркемнәрдә эш.**

1. *Сүзнең буасын җибәрү* гыйбарәсен ничек аңлыйсыз?

– Бертуктамый, аңлаешсыз сөйләү.

2. *Сүз очын югалту.* Мәгънәсе – сүзнең рәтен, тәртибен бутау.

Сөйләм аңлаешлы булуын нинди чәчкә белән билгелисез?

3) Сөйләм саф булсын.

**Укытучы.** Сөйләм сафлыгына ничек ирешергә?

– Сүз байлыгын дөрес кулланырга кирәк.

– Чит тел сүзләрен катнаштырмаска кирәк.

– Ымлык, кереш сүзләр өстәп сөйләшмәскә.

– Сөйләм сафлыгына карап, кешенең белем дәрәҗәсен, тәрбиясен белеп була.

**Укытучы.** Сөйләм сафлыгына караган нинди мәкаль, әйтемнәр беләсез?

– *Инсафлының теле саф* әйтемен ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә аңлатыгыз.

– Дөрес, саф итеп сөйләшү үзеннән-үзе килми. Бары тик сөйләмеңә игътибарлы булып, үз өстеңдә эшләп кенә ирешеп була. Тәрбияле, инсафлы кешенең сөйләме дә саф булыр.

– Сөйләм сафлыгын нинди чәчкә белән аңлатырсыз?

4) Сөйләм җыйнак булсын.

**Укытучы.** Сөйләм җыйнаклыгына ничек ирешергә?

– Бер үк мәгънәгә ия булган сүзләрне янәшә кулланмаска кирәк.

– Бер үк мәгънәле сүз һәм җөмләләрне кабатламаска кирәк.

**Укытучы.** Бу хакта халык авыз иҗатында ни диелә?

– Бауның – озын, сүзнең кыска булганы яхшы.

– Кыскалыкта – осталык.

– Аз сөйлә, күп эшлә.

– Ике уйла, бер сөйлә.

– Сөйләм җыйнаклыгын нинди чәчәк белән күрсәтерсез?

5) Сөйләм аһәңле булсын.

**Укытучы.** Ничек аңлатырсыз?

– Сөйләм матур яңгырашлы булырга тиеш.

– Моңа ничек ирешергә? Төркемнәрдә фикерләшегез.

– Җөмләдә бер үк авазларның кабатлануын булдырмаска.

– Күп иҗекле, озын сүзләрне сөйләмдә урынсыз кулланмаска.

– Авазлары бер үк булган сүзләрне янәшә куймаска.

– Укучылар, бу җөмләдә нинди хата киткән: *Тупас сүзләр күңелдә күңелсез юшкын калдыра. (Җөмлә экранда күрсәтелә.)*

– Сөйләмнең аһәңле булуын нинди чәчкә аша күрсәтерсез?

**Укытучы.** Рәхмәт, укучылар. Сез сөйләм культурасына куелган таләпләрне аңлатып бирдегез. Чәчәкләрдән бик матур букет килеп чыкты. Бәйләмебездә бер генә чәчәк булмаса да, аның яме югалыр иде. «Без чәчәкләрдән сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз» – дигән Ф.Әсгать. Бу, чыннан да, шулай бит. Сез дә сүзнең тәмен, ямен аңлап, урынлы кулланыгыз.

– Күренекле шәхесләрнең сүз хакындагы фикерләре белән танышып үтик.

*(Фикерләр экранда күрсәтелә.)*

1) Сүз – бөек нәрсә ул. Бөек, чөнки сүз белән кешеләрне берләштерергә, сүз белән аерырга да мөмкин, сүз белән сөелергә дә, сүз белән дошманлашырга да, сүз белән кешедә үзеңә нәфрәт уятырга да мөмкин. Кешеләрне бер-берсеннән читләштерә торган сүздән саклана күр! *(Л.Н.Толстой)*

**Укытучы.** Бу фикердән нинди нәтиҗә ясыйсыз?

2) Нинди генә сүзләр юк! Нәфисләре бар. Күңелсезләре. Мөлаемнары күп. Ачулылары. Хәтта мәкерлеләре йөри телдән телгә.

Ачык күңелле сүзләр бик ишле. Моңлылар да аз түгел. Күңелсезләр, купшылар, шатлар, ямьсезләр дә җитәрлек.

Кайсыберләре ялтырап тора. Гүя зөбәрҗәт. Икенчеләре дөм караңгы. Әйтерсең, мунча ташы.

Бер уйласаң, сүз җанлы кебек. Хәтта кеше кебек алар, Берсе ачык йөзле, берсе шыксыз чырайлы. Төрле төс ала сүз. *(Й.Гәрәй)*

**Укытучы.** Автор ни әйтергә теләгән?

– Һәр сүзне урынлы, дөрес куллана белү бик мөһим.

**Укытучы.** Сүз сөйләү – һөнәр, сөйли белмәгән үләр дигән халык мәкален ничек аңлыйсыз?

– Әдәпле, төпле итеп аралаша белү мөһим.

– Сүзләрнең ниндиләре була?

– Яхшылары да, яманнары да булла.

– Яхшы сүзне кемнәр әйтә?

– Укыган, белмле, әдәпле кешеләр әйтә.

– Бар очракта да яхшы сүз әйтеп буламы? Ачу килгәндә, хәтер калганда нишләргә?

– Акыллы кеше начар сүз кулланмас я дәшми калыр, кешегә каты бәрелмәс

**Укытучы.** Тормыштан мисаллар китереп, сәхнәләштереп күрсәтегез. Ике төркемгә бүленеп эшлибез.

**I күренеш. «Әни – кыз»**

**Кыз.** Хәерле кич, әнием, кайттыңмы? Мин сине сагынып көттем. Әйдә, ашарга утыр, кадерлем.

**Әни.** Рәхмәт, балам, күз нурым. Син минем бәхетем, акыллым, җимешем.

**II күренеш**

Трамвайга әби керә, сумкалары авыр. Бер кыз музыка тыңлап, утырып бара. Урын бирүен сорагач, тавышын күтәреп, кычкыра башлый:

– Надоели уже эти старики. Мин тоже мәктәптән кайтып барам. Совсем арыдым. Да, ладно, утыр, бабуля.

**Укытучы.** Беренче күренешкә исем сайлагыз.

– Җайлы сүз җан эретә.

**Укытучы.** Икенче күренешкә исем кушыгыз.

– Теле бозыкның күңеле бозык

– Беренче күренештәге кызның холкы нинди?

– Миһербанлы, шәфкатьле, әнисен хөрмәт итә;

– Сөйләме саф, аһәңле, күңелгә якын.

– Икенче күренештәге кызның холкы нинди?

– Әдәпсез, сөйләм культурасы түбән.

– Рус теле белән татар телен катнаштырып сөйли.

– Холкы тупас.

**Укытучы.** Сез аны ничек белдегез?

– Аның холкы сөйләменнән күренә, чөнки «сүз ул – күңел көзгесе».

Укучылар, сез бик тырышлар. Сүзләрнең тәмен, мәгънәсен тоя беләсез. Хәзер сүзләрдән мәрҗән тезәрбез.

**Иҗади эш.** «Шигъри тәлгәшләр»

**Укытучы.** «Сүз ул – күңел көзгесе. Сүзнең була төрлесе» – дигән шигырь юлларын дәвам итәргә. Төркемнәрдә эшлибез.

– Я була ул бик татлы,

Я була ул бик ачы.

Шуны яхшы аңлагыз,

Сез дә читтә камагыз.

Татлы сүз сөйләп, дусларның

Хөрмәтен сез яулагыз.

**Ныгыту.**

– Без бүген нәрсә турында сөйләштек?

– Сөйләм культурасы, сөйләмгә куелган таләпләр хакында.

– Аңа ия булу өчен нишләргә кирәк?

– Үз сөйләмеңә һәрчак игътибарлы булырга кирәк.

– Тупас, ямьсез сүзләр кулланмаска.

**Бирем.** Тупас, дорфа сүзләрне яралау сүзләре дип атыйк. Хәзер ике төркемгә бүленеп, «яралау» сүзләрен «дәвалау» сүзләренә әйләндерегез.

«Укытучы – укучы» рольле уены:

| **I төркем**<br>1. Такта янына чык! | **II төркем**<br>Минем яныма кил әле, сиңа якыннан карыйм әле. |
|---|---|
| 2. Дәресеңне әзерләмәгәнсең. | Киләсе дәрескә әзерләнеп килерсең дип ышанам. |
| 3. Синнән сорамыйлар. | Мин синнән бик акыллы сүзләр ишеттем |
| 4. Кысылма әле! | Тыңла әле, бер киңәшем бар. |

**Укытучы.** Рәхмәт, укучылар. Җырда да бит: «Бер сүз җитә яраларны дәваларга», – дип җырлыйлар. Сез яралау сүзләрен түгел, дәвалау сүзләрен кулланырсыз дип ышанам. Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен төзәтә диелә бит мәкальдә дә. Сез дә сүзләр белән дәвалаучы, күңелләрне ялгаучы сүзләр докторы булыгыз.

*(Экранда «Сорау» шигыре китерелә.)*

– Укучылар, экранга игътибар итегез әле.

Яхшы сүзне күңелең тели синең,

Начарлыктан күңелең көрсенә.

Ә син үзең андый яхшы сүзне

Әйтәсеңме башка кешегә?

**Укытучы.** Бүгенге яшьләрнең сөйләшү үзенчәлекләре сезгә ошыймы? Нинди җитешсезлекләр күрәсез?

– Дорфа, тупас сөйләшәләр.

– Ул нәрсәдә чагыла?

– Сөйләшергә иренүдә, әдәпле сөйләшә белмәүдә, сорауга җавап белән җавап бирүдә, тупаслыкта.

**Иҗади бирем.** Сөйләм культурасына ия булу өчен, үз-үзеңне тәрбияләү планы төзегез.

– Күп укырга, төпле белем алырга.

– Халык авыз иҗаты үрнәкләрен даими өйрәнергә.

– Акыл ияләренең сөйләм осталыкларын өйрәнергә,

– Үз сөйләмеңә тәнкыйть күзлегеннән карый белергә,

– Сүзлек запасыңны баетып торырга, һ.б.

**Укытучы.** Сез – журналистлар.

*1 нче төркем.* Сөйләм әдәбенә чакырып өндәмә языгыз.

– Кадерле дуслар! Күп укыгыз, төпле белем алыгыз.

– Халык авыз иҗатын даими өйрәнегез.

– Акыл ияләренең сөйләм осталыкларын өйрәнегез.

– Үз сөйләмегезгә тәнкыйть күзлегеннән карый белегез.

– Сүзлек байлыгын арттырып торыгыз! һ.б.

*2 нче төркем.* «Сүз ул – күңел көзгесе» дигән темага залга мөрәҗәгать итеп сөйләгез.

– Сүз ул – күңел көзгесе. Дусларым, һәр сүзегезне уйлап сөйләгез.

– Сүз белән саксыз эш итүдән сакланыгыз.

– Әйткән сүзләрегез, кылган гамәлләрегез гадел, саф булсын!

**Укытучы.** Аралашу әдәбенә ия булу өчен, нинди сүзләрне белү кирәк? Фикерләр тыңлана.

Шәхси бирем.


- Изге теләкләр.
- Рәхмәт әйтү, шатлану.
- Гафу үтенү.
- Мөрәҗәгать сүзләре.
- Кешенең исеменә кушып, якын итеп эндәшә торган сүзләр.
- Бер-береңә еш әйтелергә тиешле сүзләр.
- Гаиләдә туганнар арасында кулланыла торган сүзләр.

Шул сүзләрне кулланып, бер-берегез белән аралашыгыз.

1. Исәнме дустым, яшьтәшем, милләттәшем.
2. Хәлләрең ничек?
3. Мин сине бик сагындым, юксындым (кулларын җәеп).
4. Килүеңә мең рәхмәт.
5. Синең белән очрашуым күңелгә бик рәхәт.

**Укытучы.** Безгә аралашу шатлыгы биргән сөекле туган телебезне саклыйк.

17



# «ТАТАРСТАН – УРТАК ЙОРТЫБЫЗ»

*(ТАССРның – 100 еллыгы, Татарстан Республикасының 30 еллыгына багышланган бәйрәм сценарие)*

Фото https://iq.hse.ru/news/195000545.html сайтыннан



**Ләйлә ГАЙНУЛЛИНА,**

Казандагы Ф.Г.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең югары квалификация категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Дәрес барышы**

Алып баручыларның чыгышы.

*(Салих Сәйдәшев язган «Вальс» яңгырый, экранда презентация күрсәтелә.)*

**1 нче алып баручы.** Хәерле көн, кадерле дуслар, ватандашлар, хөрмәтле кунаклар!

**2 нче алып баручы.**

Идел ярларына нурлар сибеп,

Матур булып ата бездә таң.

Таң шикелле якты, күп милләтле

Туган илебез безнең Татарстан!

**1 нче алып баручы.**

Татарстан!

Бүгенем син минем, үткәнем син,

Киләчәккә барыр юлым син.

Аяк терәп басар җирем дә син,

Сусавымны басар суым да син!

**1 нче укучы.** Быел без Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгы һәм Татарстан Республикасының 30 еллыгын билгеләп үтәбез.

**2 нче укучы.** 1920 елның 27 маенда Советлар халык комитеты председателе В.И.Ленин ТАССР оешу турындагы декретка кул куя. 1990 елның 30 августында Югары Совет Татарстан Республикасы суверинетын игълан итә. Бу документ Татарстанга икътисадны үстерергә мөмкинлек бирә. Ә бай икътисад ул – яңа мәктәпләр, яңа балалар бакчалары, яңа йортлар дигән сүз.

**3 нче укучы.** Татарстан – җир асты байлыклары белән данлыклы. Ә иң зур байлыгыбыз – күпмилләтле уңган, талантлы халкыбыз: татарлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, марилар, мордвалар һәм башкалар. Бу халык бергә гасырлар буена дус-тату яши.

**4 нче укучы.** Төрле авыр чорларны, гыйбрәтле сугыш афәтен, ачлык-ялангачлыкны ил белән бергә җиңеп, Татарстан зур унышларга иреште. Рәсәйдә генә түгел, чит илләрдә дә Татарстанны беләләр һәм хөрмәт белән карыйлар.

**5 нче укучы.** В годы ВОВ труженики фронта и тыла нашей республики внесли достойный вклад в дело Победы над врагом. За подвиги, совершённые в годы войны, высокого звания Героя Советского Союза было удостоено 190 татарстанцев разных национальностей…

**6 нчы укучы.** В год празднования 75-летия Великой Победы каждый из нас вспомнил о своих дедах и прадедах, которые подарили Миру – мир. Многие написали письма родственникам-войнам, не вернувшимся из войны. В каждом сердце горит огонь Победы. Он вдохновляет и объединяет народы нашей республики и страны.

**7 нче укучы.** Безнең республикабыз халыклары арасында «дуслык моделе» урнашты. Аның нигезенә бергә яшәүче төрле милләт вәкилләренең гореф-гадәтләренә, йолаларына ихтирам салынган.

**8 нче укучы.**

Татарстанда тудык без,

Чуваш, татар, мари, рус,

Мордва, башкорт һәм удмурт,

Яшибез бергә, яшибез дус!

**9 нчы укучы.** Татарстанда гасырлардан килгән милләтара дуслык традицияләре саклана.

**10 нчы укучы.** Бүген Татарстанда 115 милләт халкы яши. Татарстан халыклары ассамблеясе 35 милли-мәдәни берләшмәне эченә ала.

**11 нче укучы.**

Дус яшибез жир йөзендә,

Дуслар кирәк һәрбер кешегә.

Дуслык булса яшәү дә күңелле,

Унай була һәрбер эшең дә.

**12 нче укучы.**

Сколько нас, народов Татарстана

И татарских и иных кровей,

Имена носящих непростые,

Дочерей твоих и сыновей…

**1 нче алып баручы.** Кадерле дуслар! Бәйрәм белән котлар өчен гарәп илләреннән килгән дусларыбызны каршы алыгыз!

*Гарәп Әмирлекләре гимны яңгырый. Балалар сәхнәгә тезелеп баса.*

Сәламләү. Хәерле көн, кадерле кунаклар! *(Гарәп телендә сәламләү.)*

*(Балалар кулында флаг, герб, милли ризык.)*

**1 нче кунак.**

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре җиде әмирлектән тора. Алар Гарәп ярымутравының Фарсы култыгының яры буйлап урнашканнар. Гарәп теле, яһүдләрнең иврит теле кебек үк, семит

төркеменә керә. Дөньядагы бөтен гарәпләрнең гомуми саны якынча 430 – 450 миллионга җитә. Аларның күпчелеге Ислам династиясенен тота, бераз христианнар да бар.

**2 нче кунак.** Гарәп биюе – бездән бүләк.

**13 нче укучы.** Һәр халыкның үз теле, үз гореф-гадәтләр, җырлары, биюләре бар. Телләр, мәдәниятләр төрле, максатыбыз – бер: ул республикабызны үсешкә илтү.. Соңгы катлаулы елларда без тагын да якынайдык, уртак Йортыбыз булган Татарстанда, бер түбә астына берләштек.

**14 нче укучы.**

Дөньяның нигезе – матурлык,

Имин булсын Ватан,

Чәчәк ата гөлбакчадай, –

Дуслык иле Татарстан!

**15 нче укучы.** Халкыбызның бай һәм данлы тарихы бар. Ул элек-электән дәүләтле халык булган. Аның мең еллык мәдәнияте, әдәбияте бар. Бабаларыбыз безгә «Бергәлектә көч!» дип васыятьәйтеп калдырган.

**16 нчы укучы.**

Одной семьёй, в одном порыве

Мы созидаем и творим,

В единстве душ и дружбе всех народов

Наш мир прекрасен и неповторим!

**17 нче укучы.** Без барыбыз да Татарстаныбызны яратабыз, җөмһүриятебез белән горурланабыз: «Без барыбыз да синең балаларың, Татарстан!» – дип әйтә алабыз. *(Хор белән әйтелә.)*

*(Татар биюе башкарыла.)*

**18 нче укучы.**

Свою историю, культуру,

Мы сохранили, сберегли,

Через столетья, лихолетья

Как клад заветный сберегли.

**19 нчы укучы.**

Татарстан мой, горжусь тобой,

Твоею славой, твоей судьбой.

Тобой – прекрасной Родиной моей,

Нигде на свете нет тебя милей!

**20 нче укучы.**

Син тәүгә кат баскан җирем

Кояшым, таңым минем.

Мин шат булып үскән җирем

Татарстаным – даным минем.

**21 нче укучы.**

Да можно ли край мой пером описать,

Иль кистью его на холсте набросать?

Найдется ли в мире художник такой,

Чтоб мог передать он в картине

Твою красоту, о Татарстан, мой родной.

**22 нчы укучы.**

Син саф хисем, якты язым

Ватаным, күркем минем

Син дөньда тиңсез бер ил,

Канатым – иркәм минем.

Син – Ватаным, бирдең нурың

Яшәвем өчен минем.

**23 нче укучы.**

Ты стал неузнаваем, Татарстан!

Ты стал счастливым краем, Татарстан!

Славься, Татарстан! Край золотой,

Славься народ, окрыленный мечтой!

**24 нче укучы.**

Мәңге яшә Татарстаным,

Күп милләтле, олуг халкым!

Мәңге яшәсен безнең ил!

Безнең Ватан – Татарстан!

**25 нче укучы.** Күпмилләтле Татарстан, дан сиңа, дан! Мәңге яшь кала Казан, чәчәк ат!

**1 нче алып баручы.**

Мой Татарстан, республика моя,

Пусть будут яркими твоей истории страницы,

Пусть будет дружной древняя земля,

Лети над миром сильной, вольной птицей!

*(Музыкаль фон куела.)*

**1 нче алып баручы.** Сау булыгыз, хөрмәтле кунаклар, дуслар! Сезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм уңышлар телибез!

**2 нче алып баручы.** Барыгызга да исәнлек-саулык, тыныч, имин көннәр телим, иҗади уңышлар сезгә, дуслар!

*(«Мин яратам сине, Татарстан!» җыры яңгырый.)*

18



# МӘДИНӘ МАЛИКОВА «ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ӘСӘРЕ

*(IX сыйныфның татар төркемендә татар әдәбияты)*

**Фотода:** Мәдинә Маликова. Фото https://zen.yandex.ru/media/id/5b8658c0a459c800a93117fa/-mdin-malikova-kazansuda-izrg-iaratam-5bc06ec6782b5d00aed4f566 сайтыннан



**Алсу ХӘМИДУЛЛИНА,**

Кайбыч районы Олы Кайбыч урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр үзләштерү дәресе.

**Дәреснең максатлары:**

*эчтәлек ягыннан:* Мәдинә Маликованың тормыш юлы, иҗаты буенча күзаллау булдыру, «Чәчкә балы» әсәре белән таныштыру;

*эшчәнлек ягыннан:* күзәтү аша текстны анализлау күнекмәләре формалаштыру, әсәрдә күтәрелгән тема, проблемаларны билгеләү, тел-стиль чараларына күзәтү ясау, дәреслек, сүзлек, терминнар, рәсемнәр белән эшләү алымнарын камилләштерү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

*Шәхси:* гаилә кыйммәтләре, әхлакый сыйфатлар формалашу, яхшылык аркылы яманлыкны җиңеп булуына инану, начар гадәтләрнең нәтиҗәләрен күрергә, аларга каршы торырлык ихтыяр көче булдыру, халык медицинасына кызыксыну уяну.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*регулятив УУГ:* дәрескә куелган максатны аңлау, үз нәтиҗәләреңне бәяли белү, укучылар уку мәсьәләсен чишү өчен кирәкле эшчәнлек алып бару мөмкинлеге алачак;

*танып белү УУГ:* дәреслек белән эшләү, укытучының сорауларына җавап бирү, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау;

*коммуникатив УУГ:* диалог алып баруга әзерлек, коллективта үз фикереңне җитәкчелегендә анализ ясау мөмкинлеге алачак, бирелгән мәсьәләләрне чишү юлларын табачак; җиткерә белү, укучы башка укучыларның фикерләрен тыңлау, аларга карата үз фикерен белдерә алу мөмкинлеген алачак, фикерен

телдән төгәл һәм дөрес итеп әйтү турында уйлаячак.

**Предмет нәтиҗәләре:** Мәдинә Маликова һәм аның «Чәчкә балы» әсәре турында белү, тел-сурәтләү чаралары турында искә төшерү, тикшерү биремнәрен үтәү.

**Кирәкле материаллар:** 9 нчы сыйныф татар әдәбияты дәреслеге (Х.Г.Фәрдиева, З.Н.Хәбибуллина, Л.К.Хисмәтова авторлыгында рус мәктәбендәге татар балалары өчен дәреслек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015 ел), Гомәр Саттар-Муллиле «Татар исемнәре ни сөйли», рәсемнәр, проектор, тикшерү карточкалары.

## Дәрес барышы

### I. Уку эшчәнлегенә мотивация тудыру

**Укытучы.** Хәерле көн, исәнмесез, укучылар! Бүгенге дәресебезне башлап җибәрәбез.




Әлеге рәсем турында нәрсә әйтә аласыз? Ул малай безгә нәрсә әйтергә тели? *(Рәсемдә китап укып утырган малайның гаҗәпләнүен күрәбез, мөгаен, үзе өчен бик гаҗәеп хәлләр ачкандыр. Безгә дә китап аша бик күп яңа ачышлар белеп булуын әйтергә тели.)*

**Укытучы.** Әйе, рәсем безгә шушы малай турында мәгълүмат бирде, без аның нинди хисләр кичерүен күрдек, шуннан чыгып фикер йөрттек. Китап укып бик күп кешеләр үзләре өчен яңа ачышлар ясыйлар, гаҗәпләнәләр. Ә сез гаҗәпләнерлек яңа ачышлар ясарга әзерме? *(Әйе, әзер.)*

**Укытучы.** Ә китаплар барлыкка килгәнче кешеләр яңа мәгълүматларны кайдан белгәннәр соң? *(Кешеләр әле язу барлыкка килгәнче үк, рәсемнәр аркылы мәгълүмат алмашканнар. Без бу турыда мәгарәләр эчендә табылган бик борынгы рәсемнәрдән чыгып әйтә алабыз.)*

### II. Актуальләштерү

**Укытучы.** Ә бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәгебезне рәсемнәр аша аңлап булырмы? Әйдәгез, экраннарга карыйк.




**Укытучы.** Әлеге рәсемнәр кемнең тормыш юлы һәм иҗаты белән бәйле икән һәм ничек? *(Бу рәсемнәрне язучы, драматург Мәдинә Маликова белән бәйләргә мөмкин. Ул Казан дәүләт педагогия институтының тарих филология фа-*

*культетын тәмамлый; «Чаян» журналында корректор булып эшли; «Азат хатын», хәзерге вакытта «Сөембикә» журналында башта – әдәби хезмәткәр, аннан җаваплы сәркатип вазифаларын башкара; 2017 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия була; 2020 елның 5 нче августында үзенең 85 яшьлек юбилеен бәйрәм итте; Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» исемле әсәре бар.)*

**III. Уку максатын кую**

**Укытучы.** Әйе, димәк, бүгенге дәрестә нинди әсәр белән танышырбыз? *(М.Маликованың «Чәчкә балы» әсәре белән.)*

**Укытучы.** Нинди максатлар куярбыз? *(Әсәрнең сюжетын белергә; Анда күтәрелгән проблемаларны билгеләргә, геройларның гамәлләрен бәяләргә, чагыштырырга; Әсәрнең теленә игътибар итәргә; Язучы әйтергә теләгән фикерне билгеләргә.)*

**Укытучы.** Әдәбият дәфтәрләренә бүгенге числоны, теманы язып куйыйк һәм алдыбызда яткан бәяләү кәгазьләренә күз салыйк. Анда үзегезнең исем, фамилияләрегезне язып куегыз һәм, һәр эш төрен үтәгәннән соң, үзегезнең эшләрегезне бәяләп барырга онытмагыз.

**IV. Эшләү проектын төзү**

**Укытучы.** Әсәрнең исеме аша әсәр турында нинди фикерләр туды. Ул нәрсә турында булачак? *(Чәчәк балы дигәч, балның файдасы турында булырга мөмкин; Әйе, бәлкининдидер авыру килеп чыккач, бал аларга шушы авыруны җиңәргә булышкандыр, чөнки балның 99 авырудан сихәте бар дигән гыйбарәне ишеткәнем бар.)*

**Укытучы.** Ә сез балны нинди авырулардан терелү өчен кулланасыз? *(Гадәттә, салкын тигәч, әнием мәтрүшкәләп бал белән кайнаган сөт эчерә.)*

**Укытучы.** Ә интернетта бу турыда нинди мәгълүматлар бар, тиз генә карап китик әле. *(Ашказаны-эчәк трактын нормальләштерә, аллергиягә, склерозга каршы көрәшә, тонусны күтәрә, ялкынсынуларны бетерә, матдәләр алмашын, тиренең тукллануын яхшырта, организмны ныгыта һ.б. Балның составында антибиотиклар күп, шуңа күрә ул антибактериаль чара да булып тора.)*

**V. Яңа материалны үзләштерү**

**Укытучы.** Ә хәзер, әсәрнең сюжетын белү өчен, 1 нче бүлек белән танышып китик.

**Укытучы.** Геройларның исемнәренә игътибар итик, Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли» китабыннан Гамил, Сәгъдия исемнәренең мәгънәләрен табыйк. Әсәр ахырында аларның исеме белән җисемнәре туры килүне карап китәрбез. *(Гамил (г.) – эшләүче, хезмәт иясе; эшчән, эшче; Сәгъдия (г.) – бәхетле; бәхет китерүче.)*

**Укытучы.** Әсәрнең башыннан ук нинди күренешләргә тап булабыз? Алар яхшы күренешме? *(Гамилгә һөҗүм итү, аның акчасын урлау, наркомания, эчкечелек, пычраклык, тәрбиясезлек – болар җәмгыятебезне, кешелекне җимерә торган бик начар күренешләр.)*

**Укытучы.** Шушы сыйфатларның барысын да кайсы геройда күрәбез? *(Макар Харитоновта.)*

**Укытучы.** Макар ни өчен ул үзен шулай тота? Әлеге сәбәпләрне билгеләргә һәм дәфтәрләргә язарга, соңыннан берберебезнеке белән тулыландырырга. *(Эчкече әти-әни үрнәге, тәрбия наз, җылы ризык, чиста кием, якты матур йорт күрми үсү, урам тәэсире, өлкәннәргә карата ихтирам булмау, сөйләме тупас, караклык, эчкечелек, наркомания белән тыгыз бәйлелек.)*



**Укытучы.** Макар ни өчен Гамилнең игътибарын җәлеп итә, ул аны кемгә охшата? *(Гамил аның тавышын да, үзен күргәч, кыяфәтен дә улы Газимга охшата, шуңа аны эзләп фатирларына килә, моннан 14 ел элек бала тудыру йортында баласын алмаштыруларын аңлый, Геннадийга да бу турыда әйтә һәм Макарны үзләренә алып кайта.)*

**Укытучы.** Алдагы бүлектә вакыйгалар

тиз алмашына, анда без Җәмил белән танышабыз. Ул кем, холкы-характеры нинди? *(Җәмил – Гамил белән Сәгъдия гаиләсендә үскән Харитоновлар улы, җирән чәчле, аксыл йөзле, йомшак күңелле, тырыш, эшчән үсмер. Үз әти-әнисе турында белгәч, аларда яшәп карый, ләкин андый тормышка күнекмәгән егет яңадан үзен үстергән йортка кайта.)*

**Укытучы.** Әсәрнең икенче бүлегендә чәчкә балының нинди авыруга шифа бирүен эзләп табабыз. *(Балның наркотиклардан коткаруы турында әйтелә, Җәмил кортлар караган вакытта, Макар аннан кәрәзле балны талап алып, сатмакчы, шул акчага наркотиклар алмакчы була. Җәмил аңа кәрәзле бал тулы рама белән башына суга, бал аның башыннан агып төшә, умарталар Макарны чагалар, бу аның наркотиклар кулланырга теләү хисен баса.)*

**Ял минуты.** Хәзер, бераз ял итү өчен, алдыбызда яткан кәгазьләргә рәсем ясыйбыз, тик аның ике шарты бар, беренчедән, ул предмет әсәр белән бәйле булырга тиеш, икенчедән, карандашны кәгазьдән аерырга ярамый



**Укытучы.** Ни өчен шушы рәсем икәнен аңлатып китәргә кирәк. *(Чәчәк, чөнки умарталар чәчәктән бал җыя; Машина, Гамилнең Ока машинасы була, Макар аңа утырып чыгып китәргә тели; Бал корты, чөнки Макарны алар чагалар; Ишек – Харитоновларга керә торган, аның йозагы, тышкы күренеше, кыңгыравы, бусагасы – барысы да бик начар хәлдә, димәк, аның артында яшәүчеләрнең дә хәле шәптән түгел.)*

**VI. Беренчел ныгыту этабы**

**Укытучы.** Төркемдә эш түбәндәгедән гыйбарәт. Бирелгән мәкаль һәм әйтемнәр арасыннан кайсын «артык» дип уйлыйсыз, шуны дәфтәргә язып куярга һәм ни өчен икәнен төркемнән бер кеше аңлатырга тиеш.

*Тапкан ана түгел, баккан ана.*

*Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый.*

*Алма агачыннан ерак төшмәс.*

*Тәрбиясез бала хайван булып үсәр.*

*Оясында ни күрсә, очканында шул булыр.*

**Җавап.** Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый мәкале әсәр эчтәлегенә туры килми, чөнки бүре баласы итеп Җәмилне карасак, ул эчкече әти-әнидән туган булса да, тәрбия яхшы булу сәбәпле, тәртипле, эшчән булып үсә, ә Макарны күз алдында тотсак, начар тәрбия алса да, әсәр ахырында, әти-әнисенең мәхәббәте, җылы мөнәсәбәте тәртипсез малайны да яхшы якка үзгәртер дип ышанасы килә.

**Укытучы.** Ә хәзер партадашларыбыз белән бергә әсәрдәге тел сурәтләү чараларына игътибар итәбез. Нинди чаралар кулланылган?

| Фразеологизмнар | Чагыштыру | Эпитет | Мәкаль |
|---|---|---|---|
| буш кул | йөрәк ярасы кебек | арык сынлы | батыр ярасыз йөрмәс |
| Татвыш күтәрү | тимер белән уеп куйгандай | озынча көлсу чырайлы | |
| кот керде | салкын суга сикергәндәй | аксыл йөзле | |
| күзгә ташлану | пәке кебек телү | җирән чәчле | |

**VII. Үзконтроль этабы**

**Укытучы.** Укучылар, әсәрнең эчтәлеге, геройлары, төп мәсьәләләрен карап чыктык. Әйдәгез, материалны ничек үзләштерүебез дәрәҗәсен тикшереп карыйк. Сорауларга җавапларны дәфтәрләргә язабыз һәм үзебезне тикшерәбез.

1. «Чәчкә балы» әсәрен жанр ягыннан нинди төргә кертергә мөмкин?
2. Кайсы геройның исеме эшчән, эшче мәгънәсенә туры килә?
3. Харитоновлар гаиләсендә ничә бала тәрбияләнә?
4. Сәгъдия үзенең балаларына ничек

эндәшә?

5. Макар-Мохтарны наркотиклардан чәчкә балы коткарамы, әллә башка төрле сәбәпләр дә ярдәм итәме?

**Көтелгән җаваплар:**

1. Повесть.

2. Гамил.

3. Ике.

4. Улым, балакаем, бәгырь кисәгем, бәбекәем.

5. Гаиләдәге бердәмлек, бер-береңне ярату, хөрмәт, ышаныч ярдәм итә.

**VIII. Ныгыту, күнекмәләр формалаштыру этабы.**

**Укытучы.** Укучылар, әсәрдәге вакыйгалар кайда бара? Алар арасында аерма бармы? *(Вакыйгалар ике гаиләдә бара, аермалар бик күп.)*

**Укытучы.** Әйдәгез, бергәләп чагыштырма таблица тутырыйк әле, аермалар күпме икән.

| Гамил һәм Сәгъдия гаиләсе | Геннадий һәм Эльза гаиләсе |
|---|---|
| Эш сөючән тату гаилә | Эчәргә яратучан гаилә |
| Балаларын яратып, матур тәрбия биреп үстерәләр | Геннадий улын «Іуңгыз баласы» дип атый, тәрбияне урам бирә |
| Машиналары бар, умарта асрыйлар | Фатирлары пычрак, җимерек җиһазлар, ашарга каткан коткан |
| Үз балаларына да, кеше баласына да җитәрлек мәхәббәтләре бар | Үз балаларын да карарга теләмиләр |
| Сәгъдия – бәхет китерүче дигән мәгънәне белдерә, балаларын, ирен бәхетле итә, Гамил – хезмәт сөюче мәгънәсен белдерә, тырыш, эш сөя, умарталар асрый | Геннадий (благородный) намуслы, вөҗданлы мәгънәсен белдерсә дә, әсәрдә ул күренми.<br>Эльза Аллаһны танучы мәгънәсен белдерсә дә, холкында чагылмый |

**Укытучы.** Укучылар, ни өчен Мәдинә Маликова шушы темага әсәр язарга алынды икән? *(Бүгенге җәмгыятьтә бу проблемалар бик актуаль, шәһәрдә генә түгел, авылларда да эчкечелек, тәрбиясезлек, шапшаклык хөкем сөрә. Автор безне мондый тормыштан сакларга тели, искәртеп куя.)*

**Укытучы.** Яшь буын ни өчен шундый юлга баса соң? *(Хәзерге матур җитешле тормыш, эш яратмау, җиңел генә акча эшләү хыялы кешеләрне шундый упкынга этәрә. Бала кечкенәдән хезмәтне яратып, дөрес тәрбия алып үсәргә тиеш.)*

**IX. Рефлексия этабы**

**Укытучы.** Укучылар. Әсәрнең исеме бик үзенчәлекле, әйдәгез аның буенча Акросүз (бирелгән сүзнең мәгънәсенә яшерелгән аңлатма бирү алымы, ассоциация, туры килүче сүзтезмәләр) төзеп, бүгенге дәресебезгә нәтиҗә ясыйк әле.

**Укучылар.**

Ч – чынбарлыкны күрсәтә

Ә – әдәплелеккә өйрәтә

Ч – чын күңелдән

К – катлаулы

Ә – әсәр

Б – бәхетле булырга өйрәтә

А – аңлашу

Л – лаеклы алмаш әзерли

Ы – ышаныч уята

**Укытучы.** Сез барыгыз да бик яхшы эшләдегез. Алдыгызда яткан бәяләү кәгазьләренә билгеләрегезне куегыз һәм түбәндәге җөмләләрне тәмамлагыз:

Бүгенге теманы мин яхшы аңладым, чөнки ... .

Барлык биремнәрне үтәдем, тик ... .

Бүгенге дәрестәге эшемнән канәгать, шуңа күрә ... .

Бүгенге дәрес кызыклы үтте, аеруча ... ошады.

**Өй эше бирү**

1. Макарның киләчәген ничек күз алдына китерәм. Мини-сочинение.

2. Әсәрнең эчтәлегенә туры килгән рәсем ясарга, яки табарга

3. Әсәрнең тулы вариантын укырга.